

Р.М.Галиева, Р.Л.Зәйни, М.Х.Фатыйхова

# Гаммәви мәгълүмат чараларында журналист тикшерүе үзенчәлекләре

Уку-укыту кулланмасы

# Гаммәви мәгълүмат чараларында журналист тикшерүе үзенчәлекләре

## Уку-укыту кулланмасы

УДК-070

Казан федераль университетының милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы утырышы карары белән басыла (2019 елның 19нчы апреле, протокол №8).

**Фәнни редакторы:**
**Гарифуллин В.З.,**
филология фәннәре докторы, профессор

Галиева Р.М., Зәйни Р.Л., Фатыйхова М.Х. Гаммәви мәгълүмат чараларында журналист тикшерүе үзенчәлекләре. Уку-укыту кулланмасы. – Казан, 2019. – 117 б.

© Галиева Р.М.
© Зайни Р.Л.
© Фатыхова М.Х.

## *ЭЧТӘЛЕК*


| | |
|---|---|
| БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. ЖУРНАЛИСТ ТИКШЕРҮЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ | 4 |
| 1. Журналист тикшерүенең тарихи үсеше | 4 |
| 2. Татар журналистикасында тикшерүләр үткәрү тәҗрибәсе | 10 |
| 3. Журналист тикшерүенең тискәре һәм уңай яклары | 12 |
| 4. Уңышлы журналист тикшерүе үткәрү шартлары | 15 |
| Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр | 19 |
| ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. ТЕЛЕВИДЕНИЕДӘ ЖУРНАЛИСТ ТИКШЕРҮЕН ӨЙРӘНҮ | 20 |
| 1. Телевидениедә журналист тикшеренүе тапшырулары: тарихи җирлек | 20 |
| 2. Телевидениедә журналист тикшеренүе жанрында иҗат итү үзенчәлекләре | 23 |
| 3. Журналист тикшеренүе жанрында әзерләнгән материалга анализ | 31 |
| Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр | 36 |
| ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК. ЖУРНАЛИСТ ТИКШЕРҮЕН АЛЫП БАРУ МЕТОДИКАСЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ | 37 |
| 1. Тикшерүгә әзерлек | 37 |
| 2. Журналист тикшерүен алып бару методикасы | 38 |
| 3. Журналист тикшерүенең төп этаплары (чыганаклар белән эш итү) | 44 |
| Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр | 51 |
| ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК. ЖУРНАЛИСТ ТИКШЕРҮЕНЕҢ ХОКУКЫЙ ҺӘМ ЭТИК НИГЕЗЛӘРЕ | 52 |
| 1. Журналист тикшерүен тормышка ашырганда кулланыла торган хокукый чыганаклар | 52 |
| 2. Журналистларның хокуклары һәм бурычлары | 54 |
| 3. Кеше хокуклары бозылган очраклар | 56 |
| 4. Журналист тикшерүе барышында очрарга мөмкин булган әхлакый чикләүләр | 60 |
| 5. Журналист язмаларында китәргә мөмкин булган хаталар | 64 |
| Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр | 66 |
| БИШЕНЧЕ БҮЛЕК. ЖУРНАЛИСТ ТИКШЕРҮЕ ЖАНРЫНДА ӘЗЕРЛӘНГӘН ЯЗМАЛАРГА АНАЛИЗ | 68 |
| 1. Хәзерге татар матбугатында тикшерүләр үткәрү тәҗрибәсе | 68 |
| 2. Газетада чыккан тикшерү язмаларына анализ ясау | 74 |
| 3. Тикшерү материалларында автор йөзе | 86 |
| Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр | 91 |
| АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК. ПРАКТИКУМ. МАТБУГАТТА БАСЫЛГАН ЯЗМАЛАР. УКУ ҺӘМ ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН | 93 |
| Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр | 111 |
| ЙОМГАК УРЫНЫНА | 113 |
| ТЕМАЛАРНЫ ҮЗЛӘШТЕРҮ БАРЫШЫНДА КУЛЛАНЫРГА МӨМКИН БУЛГАН ӘДӘБИЯТ | 115 |

# *БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. ЖУРНАЛИСТ ТИКШЕРҮЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ*

Журналист тикшеренүләренә караган материаллар газета битләрендә дә, телевидениедә дә зур урын алып тора. Җәмгыятьтә барган катлаулы процессларны ачуда әлеге өлкәнең өлеше бик зур. Журналист-тикшерүче эшчәнлеге катлаулы, чөнки ул юридик яктан бернинди нормалар белән дә ныгытылмаган тикшерү алып бара. Гади кешегә билгеле булмаган, гомумән, халыктан яшерелгән фактлар белән эш итә. Соңгы елларда журналист тикшеренүләренең активлашып китүенең сәбәпләре бар. Иң беренче чиратта бу безнең җәмгыятьтә барган вакыйгалар белән бәйләп аңлатыла. Журналист тикшерүенә корылган материаллар халык фикерен формалаштыруда катнаша, аның төрле-төрле күренешләргә карата социаль позициясен ачыклауга китерә. Әлеге язмалар халыкны хакыйкать барлыгына ышандыра, укучылар шуңа да мондый эчтәлектәге журналист әсәрләрен көтеп ала.

### *1. Журналист тикшерүенең тарихи үсеше*

«Тикшерү», «журналист тикшерүе» терминнары журналистика сүзлегенә, журналистика өлкәсенә соңгы елларда киң үтеп керде. Мәгълүм булганча, журналист тикшерүе нигезендә гадәттән тыш хәлләр ята. Алар җинаять эшләре, финанс махинацияләре, коррупция, трагедия һәм башка шундый күренешләр булырга мөмкин. Журналист тикшерүе үткән гасырның 1960 нчы еллар ахыры – 1970 нче еллар башында жанр буларак зур үсеш ала башлый. 1990 еллардан соң аеруча журналист тикшерүенә корылган материаллар саны арта. Бу чорда тикшерүләр җитештерү, социаль-көнкүреш өлкәсендәге кайбер кимчелекләргә, почта хезмәткәрләре, җәмәгать туклану өлкәсендәге җитешсезлекләр буенча үткәрелә. Әлеге тикшерүләрне журналистлар редакциягә килгән хатлар буенча да алып бара.

Журналист тикшерүләре үзенең тамырлары белән Октябрь революциясенә кадәр булган әдәбият һәм журналистикага барып тоташа. Күп кенә күренекле рус язучылары үз иҗатларында журналист тикшерүләренең традицияләренә, принципларына нигез салып, гаделлек, халык бәхете өчен көрәшүнең чын үрнәген күрсәтте. Рус язучылары А.С.Пушкинның «Пугачев тарихы»,

А.П.Чеховның «Сахалин утравы», Ф.М.Достоевскийның «Янгыннар», В.Г.Короленконың «Мултанча корбан бирү» һәм башка әсәрләре журналист тикшерүенең матур үрнәкләре булып санала. Россиядә журналист тикшерүенә нигез салучы итеп А.С.Пушкинны атыйлар, һәм аның «Пугачев тарихы» язмасы журналист тикшерүенә мисал булып тора. Пугачев восстаниесенең тарихын тикшереп, А.С.Пушкин Россия дәүләтен һәлакәткә китерүче сәбәпләрне ачып бирергә тырыша. Монда автор документаль фактларны җыю буенча бик зур эш алып бара. Чит ил язучыларының әсәрләре дә, документлар һәм шаһитларның күрсәтмәләре дә автор тарафыннан бер үк дәрәҗәдә өйрәнелә һәм аларга бәя бирелә. Үзенең язмасында автор Пугачев восстаниесенең тарихын теркәүче булып кына калмый, тарихи вакыйгаларны анализлый, аларга үзенең мөнәсәбәтен белдерә.

Журналист тикшерүнең матур үрнәге булып шулай ук Ф.М.Достоевскийның «Янгыннар» әсәре тора. Цензура рөхсәт итмәгәнгә, бу әсәр киң катлам укучыларга барып җитә алмый. Шуңа да карамастан, аның әсәре үз заманының мөһим проблемаларын күтәргән һәм тикшерү үткәргән әсәр булып тарихка кереп калган. Патшаның рәхимсез режимы хакимлек иткән чорда, цензураның көчәйгән чагында нәкъ менә аның журналист тикшерүләре алдынгы фикерле кешеләр өчен бик тә әһәмиятле булып чыга. Әсәр 1862 елда Петербургта чыгып торган янгыннарга багышланган. Ф.М.Достоевский, җәмгыятьтә килеп туган каршылыкларны анализлап, бу янгыннарның кемгә файдалы икәнен ачыкларга тырыша. Монда ул күбесенчә үзенең күзәтүләреннән чыгып яза. Шул ук вакытта газета, журналлар, хатлар да аның әсәрендә урын ала. Үзе сурәтләгән трагик хәлләрнең чын асылын ачып бирүче язма буларак, Достоевскийның әсәре журналист тикшерүнең бер үрнәге булып, тарихи әһәмияткә ия.

Язучы В.Г.Короленконың «Мултанча корбан бирү» әсәре дә журналист тикшерүенә керә. Әсәр бер төркем удмурт крестьяннарын кеше үтерүдә гаепләп хөкем итүне сурәтләүгә багышланган. 1892 елда Вятка губерниясе Иске Мултан авылы янында башсыз кеше мәете табыла. Полиция бу ритуалга корылган үтерү дип, бер төркем удмурт крестьяннарын кулга ала. Бер гаепсез крестьяннарны хөкем итәр өчен тикшерү органнары нәрсә генә

эшләми. Крестьяннарга хөкем карары чыгарыла, тик бу карар белән килешмәүчеләр В.Г.Короленкога мөрәҗәгать итәләр. Короленко суд утырышында катнашып, аның берякклы, законсыз алып барылганын аңлап ала. Шуннан соң бу җинаять эше буенча үзе материаллар тупларга, эзләнергә керешә. Ул авылга барып кешеләр белән очраша, фактларны өйрәнә, чагыштыра. Крестьяннарның гаепсез икәнлекләрен дәлилләүче фактларны тапкач, ул үзенең журналист тикшерүен «Русские ведомости» газетасында бастырып чыгара. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә җинаять эше судта яңадан карала һәм гаепсез кешеләр аклана. Короленконың ул вакытта газеталарда бу эш буенча бастырып чыгарган язмалары журналист тикшерүенең бер үрнәге булып тора.

Рус язучысы А.П.Чеховның Сахалин сөргене турындагы журналист тикшерүләре дә зур әһәмияткә ия. Әлеге утраудагы каторганы ул «Новое время» хәбәрчесе буларак тикшерә дә, каторгага сөрелгәннәр белән дә очраша, халык санын алу китаплары белән таныша. Үзенең күзәтүләрен ул медик буларак медицина хисаплары белән дә тулыландыра.

Россия журналистикасында журналист тикшерүе исемле жанрның билгеләмәсе барлыкка килгәнче ук яза башлыйлар. Җәмгыятькә кагылган проблемаларны яктыртып, язучылар корреспондеция, репортаж, очерк жанрын кулланып, журналист тикшерүенә охшаган язмалар бастырганнар. Мәсәлән, М.Е.Салтыков-Щедрин «Современник» һәм «Отечественные записки» редакцияләрендә катлаулы проблемаларны ачып яза. Шулай ук «История одного города» әсәрен алсак, анда безнең җәмгыткә дә кагыла торган моментлар күп, губернаторларның кара эшләре, алдашулары турында дөресен туп-туры бәреп яза язучы.

XIX гасырның ахыры – XX гасырның башында иҗат итүче күренекле журналистларның берсе В.А.Гиляровский шулай ук тикшерүче журналист буларак танылa. Журналист буларак ул гадәттән тыш хәлләр һәм җинаятьләр турында язган. Вакыйга урынына тиз арада барып җитеп, кирәкле мәгълүматларны туплауда аңа тиңнәр табылмаган. Кешеләр белән аралаша белү сәләте, оста психолог булу бу өлкәдә зур уңышларга ирешергә мөмкинлек биргән. 1882 елда Орехово-Зуево шәһәрендә бертуган Морозовлар фабрикасында булган янгын турындагы язмалары аны оста журналист-тикшерүче итеп таныта. Бу вакытта, эшчеләр яши

торган өч катлы тулай торак янып, 100 дән артык кеше һәлак була. Бу трагедиянең сәбәпләрен беркем дә ачарга теләми. Хакимият моның турында мәгълүматны таратуны катгый рәвештә тыя. Гиляровский очраклы рәвештә урамда полицейский белән танышып, аңа ышанычка кереп, үзенә кирәкле мәгълүматны ала. Полицейский тулай торакның махсус яндырылуы турында сөйли. Соңыннан Гиляровский газета битләрендә бу теманы күтәреп чыга.

Шулай итеп Россия журналистикасында журналист тикшерүләренә нигез салына. Совет чорында журналист тикшерүе аз күзәтелә, гомумән, юк дәрәҗәсендә була, тик шулай да 1990 елларда журналист Анатолий Рубиновның мөстәкыйль тикшеренүләр, шул исәптән махсус экспериментлар үткәреп иҗат ителгән һәм «Литературная газета»да басылып чыккан язмалары илдәге күп кенә мөһим проблемаларны хәл итүгә зур өлеш кертә. Хәтта ки ул Швециянең «Gravande journalistik» («Эзләнүчән журналистика») җыенында бәйсез журналист тикшерүенең методлары темасына караган доклад белән чыгыш ясауга ирешә. Гомумән, журналист тикшерүе жанрын үстерүгә Юлиан Семенов, Артем Боровик, Евгений Додолев, Дмитрий Лиханов, Юрий Щекочихин, Владимир Гиляровский аеруча зур өлеш керткән.

Журналист тикшерүе жанрының тарихы һәм практикасы турында Санкт-Петербургта эшләп килүче «Ажур» агентлыгы 2001 елда «Журналист тикшерүе» исемле китап чыгара. Китапның беренче бүлегендә авторлар әлеге жанрның классиклары турында язып китәләр. Алар арасында Марк Твен бар. Ул Ч.Уорнер белән бергә 1873 елда «The Gilded Age: A Tale of Today» («Алтын гасыр: Бүгенге көн әкияте») дигән китап яза. Бу китап Америка өчен зур йогынты ясый, чөнки китапның авторлары ул чорга кагылган барлык проблемаларны ача. Болар: әхлак проблемасы, сайлауларның гадел булмавы, финанс эшләрнең шикле килешүләре, җәмгыятьтәге кешеләрнең мал-мөлкәт туплау өчен төрле җинаять кылулары. Китап бик аз вакыт эчендә 40 меңлек тираж белән сатыла, бу кешеләргә җәмгыятьтәге катлаулы мәсьәләләрне яшермичә язу ошый дигән сүз. Ә тәнкыйтьчеләр, гомумән, Америка китапның авторларына үзгәртү юлына бастырганнары өчен бурычлы дип язалар.

Бөтен дөнья журналистика тарихына килсәк, журналист тикшерү жанрының классик мисалы итеп «уотергейт эше»н

саныйлар. Күп кеше өчен әлеге эш Америка президенты Никсонны импичмент куркынычы астында отставкага җибәрүне аңлата. Әмма аның асылында журналист тикшерүе ята. Моның турында хәтта 1976 нчы елда Алан Пакула «Вся президентская рать» исемле кино төшерә. Фильмның нигезенә атаклы Вутворт һәм Бертстан материаллары ята. Бу кыю журналистлар җыйган сенсацион мәгълүматлар «Вашингтон пост « газетасында чыга һәм халыкка әлеге эшнең нидән гыйбәрәт булуына күз ача.

1972 елның 17 июнендә Вашингтонның «Уортергейт» отелендә, илдә президент сайлау кампаниясе барганда, «Президент сайлау буенча Республика партиясе комитеты» кешеләре демократик партиянең штаб-фатирына яшерен рәвештә кереп, тыңлаучы приборлар куярга теләүләре һәм полиция тарафыннан тотылулары вакыйгасы тирәсендә яңгыраган эш. Президент бу эшкә катнашы булмавы турында белдереп, эшне тиз арада бетерергә тырышкан. Әгәр дә «The Washington Post» газетасының ике кыю журналисты Роберт Вудворт һәм Карл Бернстайн тикшерү эше башлап җибәрмәсәләр, бу шулай булыр иде дә. Тырышлыклары белән алар президентны фаш итеп, отставкага җибәрергә, илдә гаделлекне торгызырга булыштылар. Әлеге вакыйгадан соң Америкада журналист профессиясенә укырга керергә теләүчеләр артып, факультетлар да ачыла. Халыкка хезмәт итеп, дөреслекне урнаштырырга омтылучылар моны журналистика белән хәл итеп булуын раслыйлар. Шуннан журналист тикшерүе жанры да таралып китә һәм хәзерге вакытта актив үсеп, җәмгыятькә файда китерә.

Үзгәртеп кору чоры бу жанрда эшләргә теләгән журналистлар өчен зур мөмкинлекләр ачты. Алар җәмгыятьтә булган тискәре күренешләр турында язу мөмкинлегенә иреште. Акчага һәм властька кагылган журналист тикшеренүләре (күп очракта бу шулай), бу чорда журналистка зур күңелсезлекләр белән яный иде. Ун елга сузылган үзгәртеп кору чорында 200гә якын журналистның гомере өзелде. Аларның күбесенең үлеме һөнәри эшчәнлеккә караган, журналист тикшерүләре үткәрүгә бәйле иде.

Бүген дә бу өлкә журналистлардан зур кыюлык таләп итә, чөнки барлык журналистлар да үзләренең гомерен куркыныч астына куярга әзер түгел. Хәзер күп кенә матбугат чаралары бу өлкәдә актив эшчәнлек алып бара. Шул ук «Новая газета»,

«Московский комсомолец», «Совершенно секретно», «Ваш тайный советник» басмалары журналист тикшеренүләренә зур әһәмият бирә. Шулай ук татар телле басмалардан «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Шәһри Казан», «Безнең гәҗит», «Ирек мәйданы», «Акчарлак», «Сираҗи сүзе» кебек газета битләрендә дә журналист тикшерүенә соңгы елларда әһәмиятле зур урын бирелә. Телевидениедә дә махсус тикшерүләргә багышланган тапшырулар эшләп килә.

Журналистларның эше аудиториягә яңалыклар җиткерү генә түгел, газета-журнал битләрендә һәм телевидение аша гаделлек, бар кешенең дә закон каршында җаваплылыгы, кеше хокукларын саклау, алдау-йолдау һәм ришвәтчелеккә каршы көрәш икәнен журналистлар үзләренең хезмәтләре белән исбатлый.

Мәгълүм булганча, журналист тикшерүе нигезендә гадәттән тыш хәлләр ята. Алар җинаять эшләре, финанс махинацияләре, коррупция трагедия һәм башка шундый әйберләр булырга мөмкин. Журналистның максаты – хакыйкатьне ачу. Дөреслекне ачудан тыш, журналист тикшерүе материаллары белән аудитория игътибары да нык җәлеп ителә. Монысы да төп максатларның берсе. А.Тертычный «Расследовательская журналистика» китабында журналист тикшерүенең гомум максатларын түбәндәгечә билгели: халыкка кызыклы, әһәмиятле булган, әмма аңардан яшерелгән мәгълүматны ачу; көчлеләрнең властьтан кирәгеннән артык файдалануына каршы көрәшү; җәмгыять яхшы якка үзгәрсен өчен, законсызлык белән көрәшү. Тикшерү белән төзелгән аналитик язма – зур һәм файдалы эш. Беренчедән, ул яңалык, икенчедән, зур иҗтимагый әһәмияткә ия. Бу язма журналисттан шактый инициатива, көч һәм эшләү теләген тәләп итә. Чөнки ул бу язма белән җәмгыять ихтыяҗларын, дөреслекне һәм гаделлекне яклый, гомумән, җәмгыятькә хезмәт итә.

Журналист тикшерүен очерк, мәкалә, репортаж кебек үк аналитик жанрның бер төре итеп карарга мөмкин. Әмма аның үзенә генә хас алымнары да бар. «Тикшерү яшерен фактларны эзләп табуга нигезләнгән автор версиясен тәкъдим итә. Аның максаты – ситуацияне «ачу», «проблемага чыгу». Моның өчен журналист фактларны үзе таба. Ул детектив әсәр язган кебек гаепләрлек мөмкинлек булдыру өчен фактлар эзли. Мондый материалларда еш кына төрле кодекслар маддәләренә таянырга, хокук саклаучылар

белән киңәшеп эшләргә туры килә. Тикшерү методы белән язылган мәкаләләр соңгы вакытта «сары» матбугатта да очраштыргалый. Әмма анда еш кына басманың коммерция максатлары алга куелырга мөмкин. Күпчелек Европа илләре, Америка журналистларының озак еллар буена туплаган тәҗрибәсе, шулай ук Россиянең кайбер массакүләм мәгълүмат чараларының соңгы елларда шул юнәлешкә кереп китүе мондый журналистиканың сыйфат ягы түбәнлеген, журналистларга да таләпләр кимүен күрсәтә.

## *2. Татар журналистикасында тикшерүләр үткәрү тәҗрибәсе*

Татар журналистикасында исә тикшерүләр үткәрүе белән Мирхәт Хөснимәрдәнов танылa. Татар матбугатында журналист тикшерүен фәнни яктан беренче тапкыр өйрәнүче Васил Гарифуллин авторның тулы бер эшчәнлеген күзәтә. Менә нәрсәләр яза ул: «Сиксәненче еллар башында ул «Татарстан яшьләре» газетасында Рокыя әби Хәймурзинаның аянычлы язмышы турында язып чыккан иде. Әби гомер буе мех фабрикасында тир түгеп тә фатир ала алмаган, бер йортның чормасында яшәргә мәҗбүр. Әбинең дәүләт фатиры алырга тиешлеген нинди генә дәлилләр ярдәмендә исбатламый автор: Рокыя әбинең авыр сугыш елларында фронтка җылы киемнәр җитештерүдә эшләвен дә, аның бүген бер карачысы булмавын, чормада тормыш өчен бернинди уңайлыклар юклыгын һ.б. Мөстәкыйль рәвештә үз тикшерүен уздырып, дәлилләрен үзе күргән фактлар ярдәмендә генә түгел, төрле документлар белән дә беркетә. Бу документларны фабрика җитәкчелегенә илтеп тапшыра, даими кызыксынып тора. Мәсьәлә һаман хәл ителмәгәч, М.Хөснимәрдәнов яңадан бу темага әйләнеп кайта һәм 1987 елда шул ук газетада «Бер гомер – бер гозер» исемле язмасын бастыра. 1988 елда «Социалистик Татарстан» газетасында «Әби һаман чормада» дигән үткен язма белән чыга. Ләкин бу язмаларга җитәкче органнардан әбигә фатир бирә алмауларының сәбәпләрен аңлаткан формаль җаваплар килә тора. Чарасызлыктан нишләргә белмәгән журналист 1989 елда «Рәнҗи күрмә миңа, әбекәй» дигән язмасын бастырып чыгара. Монысында инде мантыйкый дәлилләр юк дәрәҗәсендә. Журналист аларны алдагы язмаларда җитәрлек китерде ич. Нәтиҗәсе генә булмады. Соңгы

язмасында исә Мирхәт ага укучының хисләренә тәэсир итә, бюрократларның җансызлыгына, битарафлыгына нәфрәтләнә, әбинең бүгенге хәлен укучыны тетрәндерерлек тел чаралары белән сурәтләп бирә. «Яңа фатир күрә алмыйча үлеп китсәң, миңа рәнҗи күрмә инде, әбекәй, – дип яза ул. – Миннән калмады. Кулдан килгәннең барысын да эшләдем...» Бу материал дөнья күргәннән соң, 78 яшьлек Рокыя әби фатирлы була. Журналист тикшерүе шулай итеп ахыр чиктә уңай нәтиҗәгә китерде».

Мондый мисалларны татар матбугатында күп китерергә мөмкин. Журналист һәм язучы Рафаэль Мостафинның Муса Җәлил эзләре буйлап Германиядә үткәргән күпсанлы эзләнүләрен, шулар нигезендә чыккан документаль әсәрләрен дә күпмедер дәрәҗәдә журналист тикшерүе кысаларына кертергә мөмкин булыр иде. Тарихчы Искәндәр Гыйләҗевның соңгы елларда «Идел-Урал» легионы буенча өйрәнүләре дә кызыклы.

Хәзерге журналистлардан әлеге жанрда актив иҗат итүчеләрдән «Татарстан яшьләре» газетасының элеккеге хезмәткәре, бүген «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Гөлнара Сабирова исемен атап үтәргә булыр иде. 2005 елда Татарстан журналистларының «Бәллүр каләм» бәйгесендә Г.Сабирова нәкъ менә «Журналист тикшерүе» номинациясендә җиңү яулады. Шәхси басмаларда халык мәнфәгатьләрен яклап, күп кенә социаль темаларны өйрәнүче Илфат Фәйзрахманов, Искәндәр Сиражи, Эльвира Фатыйхова, Айгөл Закирова, Фәнзилә Мостафина, Эльмира Флүн, дәүләт басмаларыннан Алсу Хәсәнова, Лилия Заһретдинова, Камил Сәгъдәтшин, Рәсимә Муллаянова, Римма Бикмөхәммәтова, Рәмис Латыйпов исемнәрен атап китеп булыр иде. Журналист тикшерүләре турында сүз алып барганда, аерым журналистларны атап китү белән беррәттән, басмаларның исемлеген дә читтә калдырып булмый. Әлбәттә, татар газеталарының күпчелегендә журналист тикшеренүенә караган язмалар бар. Шуларга мисал итеп «Безнең гәҗит», «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Ирек мәйданы», «Акчарлак» газеталарын әйтергә була. Соңгы елларда тикшерүгә корылган язмаларның саны бермә-бер артты. Татар матбугатын шартлы рәвештә ике яссылыкта – дәүләти һәм шәхси басмаларга бүлеп карасак, соңгысында тикшерү алымнарының күбрәк кулланылганы ачык күренә.

Алдагы бүлекләрдә берничә газетада чыккан журналист тикшеренүләрен, аерым журналист язмаларын анализлап үтәрбез. Шулар аша татар матбугатында журналист тикшерүе тәҗрибәсенә тукталырбыз.

### *3. Журналист тикшерүенең тискәре һәм уңай яклары*

Журналистикада иң катлаулы жанрларның берсе булып журналист тикшерүе тора. Ул тормышның әхлакый һәм хокукый якларын да яктыртучы жанр. Гаммәви мәгълүмат чаралары еш кына, үзләре дә сизмәстән, халык арасында тавыш чыгуга, бәхәс кузгалуга, фикер уянуга сәбәпче була. Шул рәвешле ул җәмгыять тормышына тәэсир ясый. Бигрәк тә үтереш, ришвәтчелек, терракт, суд эшләре, җинаятьчелек белән бәйле темалар яктыртылганда, укучы битараф калмый. Ул әлеге гаделсезлекнең очына чыгарга, аны булдырмаска омтыла. Халык газета битләрендә басылган яки эфирдан яңгыраган андый хәбәрләр турында озаклап гәп куерта. Димәк, журналистларның һәрбер адымы, авызыннан чыккан һәр сүзе җәмгыять тарафыннан игътибарга алына. Шулай булгач, журналист, тикшерү эшләрен алып барганда, аның турында язып, халыкка бәян иткәндә, дөрес булмаган мәгълүмат таратудан сакланырга тиеш. Җәмгыятьтәге начар күренешләрдән котылырга ярдәм итүче тәнкыйть язмаларында расланмаган дәлилсез фактлар, түбәнсетүче бәяләмәләр, гражданнарның намусына һәм дәрәҗәсенә зыян салучы фикерләр булырга тиеш түгел. Әлбәттә инде, журналист тикшерүенең үз үзенчәлекләре, нормалары, кагыйдәләре дә бар. Журналист тикшеру вакытында аерым методларга (күзәтү, интервью, документлар һ.б), принципларга, хокукый һәм әхлакый чикләүләргә таянып та эшли. Һәм ул үзенең эшчәнлеген бер кысада тотучы законнарны күз уңаенда тотарга тиеш. Журналист тикшерүе, күп очракта, җинаять эшләре, суд утырышлары белән бәйле була. Нәтиҗәдә, андый эшчәнлек барышында, гаммәви мәгълүмат чаралары белән хокук саклау органнары арасында хезмәттәшлек тә оеша. Иң мөһиме: закон һәм әхлакый нормалар кысаларын онытмау. Суд карары чыкканчы, кешене гаепле дип игълан итәргә ярамый. Аңарчы журналист ул кеше турында «гаепләнүче», «шикле», «тикшерү астында тотылучы» дип кенә әйтә ала, әмма «җинаятьче» дип атарга хокукы юк. Судта тикшерелә торган теләсә кайсы вакыйганы да җинаять дип атарга да ярамый.

Гомумән, ул гайбәт тарату, намус һәм дәрәҗәгә тап төшерүдән сакланырга тиеш. Журналист тикшерүе вакытында кире какмаслык дәлилләр китерелгән очракта да журналист гаепләнүчене җинаятьче дип атый алмый. Бары шул дәлилләр нигезендә аңа карата гаепләү белдерүе белән генә чыга ала. Димәк, газета битләрендә җинаятькә каршы көрәш темасына караган язмаларның авторлары игътибарлы булырга һәм юридик терминнарны дөрес, урынлы кулланырга тиеш.

Журналист тикшерүенең үзенчәлегенә тикшерү планын яки тикшерү этапларын да кертергә була. Тикшерү планы куелган сорауларга җавап алу һәм нәтиҗәгә ирешү өчен үтәргә кирәк булган баскычларны үз эченә ала. Моңа мәгълүмат туплау һәм эшкәртү, чыганаклар белән эшләү, текст язу керә. Мәгълүмат туплаганда, чыганакларның ачык һәм ябык булырга мөмкин икәнен онытмаска кирәк. Телефоннан сөйләшүләр, ярдәм сорап килгән хатлар, кемдер килеп, ниндидер тема тәкъдим иткән очраклар – бу ябык чыганак була. Шулай ук җинаять эше буенча тикшерү алып барылганда, суд карары чыгарылганчы ук тикшерү материаллары белән танышырга теләгән журналистны бары тик прокурор яки тикшерүче рөхсәте белән генә таныштыра алалар. Димәк, мәгълүматны эзләгәндә, чыганаклар белән эш иткәндә, журналист күпмедер дәрәҗәдә каршылыкларга да очрый.

Тикшерү эшен алып барганда, башка кешеләрдән килгән мәгълүматларны кат-кат карап чыгу бик мөһим. Журналист андый очракларда мөстәкыйльлеген югалта. Вакыйгаларга бәя биргәндә, теләсә-теләмәсә дә үз фикереннән бигрәк, мәгълүмат биргән кеше фикерен яктыртуны артыграк күрергә дә мөмкин. Чөнки башкача эшләү чыганакны югалтуга китерә ала. Болар нәтиҗәсендә журналистны хаклы рәвештә бер яклы гына фикерләүдә, мәгълүматның еш кына тикшерелмәгән булуында гаепли башлаячаклар. Андый күңелсез хәлләргә тарымас өчен иң кулае – бер үк темага мәгълүмат бирерлек берничә чыганак булдыру. Ә инде мәгълүматларның дөреслеген тикшерү өчен еш кына җитәкчеләр яки белгечләр белән очрашып сөйләшү, документлар белән танышу, гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан урыннарда булу таләп ителә.

Гаммәви мәгълүмат чараларында көн саен күпләп яңалык бирелеп барыла. Алар халыкны кызыксындырган һәрбер күренеш,

вакыйга, очрак, хәл хакында төгәл һәм тулы мәгълүмат белән даими рәвештә тәэмин итеп тора. Журналист тикшерүе материалларын халык аеруча да кызыксынып укый. Ул әлеге язмаларның оригинальлеге, фактларны анализлау, сурәтләү һәм автор фикерләре дә чагылыш табуы белән аңлатыладыр. Тикшерү материаллары нигезендә журналист җәмгыятькә дөреслекне, хакыйкатьне ачып бирә. Гаеплеләрне фаш итәргә, ә гаепсезләрне акларга ярдәм итә. Журналист урталыкны саклап, ике як фикерне дә кабул итеп, юридик законнарга һәм әхлакый нормаларга таянып тикшерү алып барып, аның нәтиҗәләрен халыкка җиткергән очракта гына тикшерү эше уңай бәяләнәчәк. Әмма әгәр журналист үз бурычлары турында онытып җибәрә икән, кешене кимсетү, исемен пычрату өстендә генә эшли һәм башкалар өстеннән үзбелдекле хөкем чыгарырга омтылган очракта, бу уңай нәтиҗәләргә китермәс. Журналист һәм аның материалларының геройлары арасында килеп чыга торган бәхәсләрнең күпчелеге соңгыларының намусына, хөрмәтле исеменә, дәрәҗәсенә, репутациясенә тиюгә, пычратуга бәйле сәбәпләр аркасында килеп чыга да инде. Мәсәлән, журналист үзенең тикшерү материалында дәлилләргә таянмыйча гына берәр кешенең ришвәт алуы хакында язып чыкты ди. Ә моны исбатлаучы фактлар юк. Әлеге кеше журналистны судка бирергә, аны җәзага тартырга да мөмкин. Чөнки кеше җәмгыятьтән башка яши алмый, шуңа ул җәмгыять вәкилләренең аның турында нәрсә уйлавы, нинди бәя бирүе аңа мөһим. Әлеге сәбәп аркасында һәркем дә үзенең җәмгыятьтәге хөрмәтле исемен саклар өчен тырыша, репутациясен югалтмый. Тәҗрибәле журналист үз әсәрендә фикерен, вакыйгага карата бәясен белдергән очракта та фактларга таянып эшли.

Журналист тикшерүенең план буенча эшләнүче һәм озак вакытка сузылучы тикшерү төре икәнен ачыкладык. Бу тикшерүнең предметы, гадәттә, җинаять, сәяси скандал һәм башка игътибарны җәлеп итәрдәй вакыйгалар яки матбугатта басылган язмалар. Журналист тикшерүе нигезендә җәмгыятькә хәбәр ителми торган мәгълүматны ачыклау ята. Әлеге мәгълүмат еш кына игътибарны җәлеп итә торган негатив характерда була. Шуңа күрә бу жанрда эшләүче журналистның эше детектив эшчәнлегенә тиң. Журналист-тикшерүче үз алдына һәрвакыт ике сорау куеп эшли: «ни өчен?» һәм «ничек?». 2000 нче елда Де Бург түбәндәге сүзләрне әйткән:

«Техник яктан чыгып әйткәндә, журналист-тикшерүченең эше полиция, адвокат, аудиторлар эшләгәнгә охшаш. Әмма ул закон тарафыннан күзәтелүгә генә түгел, ә фаш итүгә дә корылган».

Журналист тикшерүе журналистның инициативасы, идеясе һәм тырышлыгыннан башка барлыкка килә алмый. Ул югары хәбәри кыйммәткә ия һәм җәмгыять өчен мөһим материал. Тикшерү эше кеше фикере, документлар, мәгълүмат һәм шәхси күзәтү кебек күпләгән мәгълүмат чыганакларына нигезләнә. Еш кына өслеккә хакимият сер булып калдырырга теләгән мәгълүмат та калкып чыга. Джин Робертс (тикшерү буенча махсуслашкан Америкадагы иң популяр газеталарның берсе «The Philadelphia Inquirer»ның элеккеге редакторы) түбәндәге фикерне белдергән: «Журналист тикшерүе – сәясәтчене төшкән чалбарлы итеп күрү яки законны бозганын хәбәр итү түгел, ә бу катлаулы дөньяда ниләр булганын аңлату өчен укучыларга төптә яткан фактларны яхшылап ачыклау».

Бөтен журналист материалы да тикшерү мәкаләсе түгел. Ул ни дәрәҗәдә мөһим һәм кирәкле булса да, репортажмы ул, мөхбирнамәме яки башка жанрда иҗат ителгән язмамы – барысы да журналист тикшерүе була алмый. Иң мөһиме – журналистның үз хезмәтен яратып намус белән башкаруы.

### *4. Уңышлы журналист тикшерүе үткәрү шартлары*

Теләсә кайсы журналист тикшерү белән шөгыльләнә ала. Стив Вейнберг (Америкада иң популяр китапларның берсе «The Reporter’s Handbook: An Investigator’s Guide to Documents and Techniques» («Справочник репортера: Руководство для исследователей по документам и методам») китабының авторы) фикеренчә, моның өчен кызыксынучанлык сыйфаты, хаксызлык һәм әдәпсезлек, нигилизмга якын булган скептизмга каршы көрәшергә теләк булу кирәк.

Журналист-тикшерүченең төп кораллары:

1. Мәгълүмат чыганагы буларак кешеләр;
2. Төрле документлар һәм алар белән эшли белү;
3. Түземле һәм оста үткәрелгән интервью;
4. Югары әхлак һәм социаль җаваплылык хисе.

Репортерлар үз эшләрен оста башкарырга тиешләр. Бигрәк тә төгәллек һәм мантыйк мөһим. Чөнки тикшерү турындагы репортаж

чыккач, еш кына журналистның дошманнары барлыкка килә. Ә соңгылары, үз чиратында, журналист тарафыннан җибәрелгән кечкенә генә хатаны отып алып, бөтен тикшерү эшен чүпкә чыгарырга мөмкин.

Журналистларда җәмгыятькә хезмәт итәргә һәм дөреслек өчен көрәшергә зур теләк булу – тикшерү алып барырга кирәк булган иң мөһим мотивлар. Тикшерү журналистны берничә ягы белән кызыксындыра: яхшы репутация ясау, хезмәт урынында югарыга күтәрелү, матди яктан үсү мөмкинлеге. Ә ГМЧ өчен – бу җәмгыяви байлыкларны саклау репутациясе, үз укучыларының ышанычын яулап алу мөмкинлеге.

Журналист-тикшерүчегә танылган Америка журналисты Майкл Берлинның («New York Post» газетасында журналист тикшерүе жанрында иҗат иткән кеше) киңәшен истә тоту кирәк: «Бернинди урланган документлар булмасын. Мәгълүмат өчен бернинди түләү булмасын. Бернинди законсыз рәвештә шәхси территориягә бәреп керү (бу эше өчен журналист суд алдында җаваплылыкны үз өстенә алган очрактан кала). Һәм иң мөһиме: бернигә дә карамастан... мәгълүмат чыганагын башкаларга ачмагыз».

Һәркемнең дә мәгълүматны теләсә нинди законлы юл белән эзләү, алу, тапшыру, җитештерү һәм тарату хокукы бар икәнен беләбез. Журналистның да төп коралы булып мәгълүмат тора бит. Үз тырышлыгы белән табылганнарны журналист каләме ярдәмендә халыкка җиткерә. Моның өчен кайвакыт авыр һәм куркыныч юллар үтәргә туры килергә дә мөмкин.

Ел саен башка төбәкләрдәге кебек үк Россиядә дә шактый гына журналистлар, үз гомерләрен куркыныч астына куеп, ришвәтчелек, терракт, гаделсезлекләргә каршы тикшерү эшләре алып баралар. Статистик мәгълүматларга караганда, журналистларны үтерү Ельцин хакимият иткән чордан башланып китә. Бу «Россия журналистлары» дигән мәгълүматлар базасы буенча исәпләнгән. Журналистларның тикшерү үткәрүләре кемнәргәдер ошап бетми һәм шуңа да аларны үтерү очраклары еш була. Статистик мәгълүматлар буенча күбесе «кайнар нокта»ларда, коралланган конфликтлы зоналарда үләләр. Мондый зоналарда журналист үзенә күрә саклык чаралары да күрә белергә тиеш. Әйтик, журналист кулына корал алып катнашырга тиеш түгел.

Хәрби, тыныч булмаган җирләргә, тикшерү эше белән чыгып китәр алдыннан, журналист планын төзергә, маршрутын төгәл ачыкларга тиеш һәм редакция белән элемтәгә керү вакытларын да билгеләргә, аларга да моның турында хәбәр итәргә тиеш. Бара торган җирнең картасын булдыру да комачауламый, тик ул артык катлаулы булырга тиеш түгел. Кем булуына карамастан, кораллы кешеләр белән конфликтлы бәхәсләргә керү дә киңәш ителми.

Журналист тикшерүе белән шөгыльләнүче каләм иясе бик сак булырга тиеш. Тикшерү вакытында журналистның үзенә генә түгел, ә аның якын кешеләренә дә янарга мөмкиннәр. Әлеге янаулар, куркытулар берничә еллар дәвамында кабатланып килә ала. Кызганычка каршы, журналист тикшерүенең иң аяныч һәм тискәре нәтиҗәләре дә шул. Тикшерүче-журналистның эше, тыныч вакытта барса да, аңа гел корбан булу куркынычы яный. Шуңа күрә, журналист үзен ничек тә саклар, күңелсезлекләргә очрамас өчен, билгеле бер кагыйдәләрне үтәргә тиеш. Куркыныч янауны киметү нисбәтеннән журналист саклык принципларын белергә тиеш. Аларга түбәндәгеләр керә:

1) Беркайчан да журналистка тикшерү эшенә берүзенә генә алынырга ярамый;

2) Тикшерүдә катнашучылар арасында конфликт тудырудан сакланырга;

3) Журналист тикшерү субъектына карата әхлакый һәм гомумкешелек принципларын бозарга тиеш түгел;

4) Журналистка информация чыганагын чишәргә ярамый;

5) Билгесез җирдә, шартларда белмәгән кешеләр белән журналист-тикшерүче очрашырга тиеш түгел;

6) Журналист уртаклыкны саклый белергә, ике як фикерне кабул итә белергә тиеш;

7) Журналист юридик таләпләрне яхшы белергә тиеш.

8) Үз вакытында психологик басым һәм куркынычсызлыкны сизә белергә тиеш.

9) Вакыт-вакыт журналист тикшерү темаларын алыштыргалап торырга тиеш.

10) Бу кагыйдәләрне үтәгәндә һәм юридик нормаларны белгән очракта тикшерүче-журналистның эше яхшы һәм уңышлы була. Хәвеф-хәтәрләрдән дә исән калу мөмкинлеге күпкә зуррак.

Гомумән, журналист тикшерүенә алынганчы бик нык

әзерләнергә, үзеңнең хокукларың һәм бурычларың турында белергә һәм куркынычсызлыгың хакында да онытмаска кирәк.

Тикшерү вакытында журналист, фактларны эзләп табуга нигезләнеп, үз версиясен тәкъдим итәргә тиеш. Аның максаты – хәлне ачып, проблемага чыгу. Журналист тикшерүе предметы исемлегенә халыктан яшерелгән төрле җинаятьләр, конфликтлар, тарихи серләр керә. Хәзерге журналистикада түбәндәге феноменнар аеруча еш тикшерү предметы булып тора:

- коррупция;
- сәяси җинаятьләр;
- икътисади җинаятьләр;
- криминал;
- тарихи серләр.

Боларның һәрберсе һәм шулай ук башка предметлар җәмгыять тормышының теге яки бу моментында актуаль булырга мөмкин. Бу исә күренешнең ничек һәм нидән килеп чыгуын, «якыннан караганда» нәрсә икәнлеген, моның җәмгыятькә нәрсә бирәчәген ачыклау өчен журналистның «тыкшынуын» таләп итә.

Журналист тикшеренүе берничә этаптан тора:

- тема табу;
- мәгълүмат туплау;
- анализлау һәм кәгазьгә төшерү.

Журналист-тикшерүче үзенең мәгълүмат туплау эшчәнлегендә төрле-төрле методлар куллана. Һәр журналистның үзенә генә хас үзенчәлекле методлары булса да, һичшиксез, алар бүтән методлар белән бергә кулланыла. Теге яки бу методны сайлап алу журналистның максатыннан һәм тикшерү предметыннан тора.

Җинаять эшләре белән бәйле журналист тикшерүен суд залыннан язылган репортаж, очерклар белән буташтырырга ярамый. Очеркчы, фельетончы да ниндидер җинаятьләр турында яза ала, әмма ул инде билгеле булган фактларны анализлый. Андый язмаларда сүз тикшерү эше төгәлләнгән, гаепләләре берсүзсез расланган җинаять эшләре турында барса, журналист тикшерүенә рәсми фаразлар шик астына куела. Төзелеше буенча бу жанрдагы язмалар мәкаләгә тартым. Биредә авторның укучыга җиткерергә теләгән төп фикере, ягъни тезис, рәсми рәвештә игълан ителгән һәм укучыга инде мәгълүм булган фикердән аерыла. Автор үз фикерен үзе эзләп тапкан фактлар, документлар, детальләр белән дәлилли.

Гомумән, журналист тикшерүе жанр буларак та үзенең позициясен ныгыта бара. Журналистикада гадәттә өч төрле жанрлар үсешен күзәтәбез. Хәбәри, аналитик һәм әдәби-публицистик төрләргә бүлеп карыйбыз. Ә чит ил матбугатына күз салсак, мәсәлән, Америкага, анда боларга тагын ике жанр өстәлә – төгәл журналистика һәм журналист тикшерүе. Соңгысы бездә дә активлашып китте инде. Бу газета һәм журналларда журналист тикшерүенә багышланган бүлекләр, махсус рубрикалар барлыкка килүеннән үк күренә. Чыннан да, әлеге жанр кешеләргә мөһим булган иҗтимагый һәм сәяси юнәлештәге вакыйгаларны белергә, аларда катнашырга булыша. Мондый язмалар күтеп алына һәм укучылар тарафыннан яратылып укыла.

***Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр***

1. Җәмгыятьтәге кайсы күренешләр журналист тикшерүнең объекты була ала?

2. Журналистикада «тикшерү», «журналист тикшерүе» терминнары. Аларның гаммәви мәгълүмат чараларында кулланылышы.

3. Журналист тикшерүенең максаты нидән гыйбарәт?

4. Россиядә журналист тикшерүенең традицияләре.

5. Татар журналистикасында тикшерүләр үткәрү тәҗрибәсе**.** Журналист тикшерүләре үткәрүче татар журналистларын атагыз.

6. Журналист тикшерүе нигезендә гадәттән тыш хәлләр: җинаять эшләре, финанс махинацияләре коррупция, трагедия һ.б.

7. Журналист тикшерүенең үзенчәлекләре.

8. Журналист тикшерүе һәм хокук саклау органнары тикшерүе арасындагы уртак һәм аермалы сыйфатлар нинди?

9. Журналист тикшерүендә саклык чараларын куллану

10. Уңышлы журналист тикшерүе үткәрүнең нинди шартлары бар?

11. Тикшерү эшендә саклык чараларын санагыз.

## *ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. ТЕЛЕВИДЕНИЕДӘ ЖУРНАЛИСТ ТИКШЕРҮЕН ӨЙРӘНҮ*

### *1. Телевидениедә журналист тикшеренүе тапшырулары: тарихи җирлек*

Телевидениедә журналист тикшеренүе жанрының башланып китүе «Фитиль» дип аталган киножурнал белән бәйле. Аның беренче чыгарылышы 1962 елда күрсәтелә. Әлеге киножурнал кысаларында аерым сюжетлар журналист тикшеренүе жанрында эшләнә. 10 минутлык «Фитиль» тапшыруында документаль, мультипликацион, уйналган (вакыйганы актерлар ярдәмендә махсус әзерләү) 3-4 сюжет күрсәтелә. Аны хәтта дөньякүләм кинематография тарихында иң беренче даими рәвештә күрсәтелгән сатирик киножурнал дип тә атыйлар. Сатирик булгач, аңлашыла, сюжетта сатира алымнары белән җәмгыятьтәге җитешсезлекләр тәнкыйтьләнә, вазыйфаларын тиешенчә башкармаган кешеләр фаш ителә. Бер полоса фельетонга караганда, 3 минутлык «Фитиль» сюжеты әлеге җитешсезлекләрне бетерү, проблемаларны хәл итү вакытын тизләтә. Тема кытлыгы булмый. Халык контроле комитетына килгән мөрәҗәгатьләрдән дә, редакциягә килгән хатлар аша да темалар сайлап алына. Җылы якларда җиләк-җимеш чери, Себердә болан тиреләре эшкәртелмәгән килеш ята, заводларда сыйфатсыз товар җитештерелә. Югыйсә, бу эшләрнең башында торучылар план йөз процентка үтәлгән дип хисап тота. «Фитиль» журналистлары әлеге ялганннарны фаш итә, гаеплеләрне атый. Әлбәттә, кайбер темаларга кагылырга, бигрәк тә Үзәк Комитет әгъзалары турында сөйләргә ярамый. Шул сәбәпле кайбер тикшеренүләр эфирга бирелми кала. Ләкин алар, гомумән «Фитиль»дә күрсәтелгән башка сюжетлар, аның ничек эшләнеше турында берничә китап бастырылды. Ә «Фитиль»не әзерләүче С.Михалков, А.Столбов, С.Киселев и Ю.Егоров 1978 елда Дәүләт премиясенә лаек булды.

Сәяси вәзгыть кыйбласын үзгәртеп коруга борган елларда Үзәк каналда яшьләр өчен тапшыру пәйда булды. Эфирга ул атналык хәбәри-музыкаль һәм публицистик тапшыру дип бирелде. Ул тапшыру «У нас на кухне после 11» дип аталып, күптәннән, хәтта егерме ел элек үк тәкъдим ителгән була. Ләкин Үзәк телевидение җитәкчеләре эфирга бирергә рөхсәт итми. Бары тик

1987 елның икенче октябрендә генә шушы максат тормышка ашырыла. КПСС ҮК идеология секретаре Александр Яковлев хуплаганнан соң, яшьләр өчен тапшыру эфирга чыга. Тора-бара ул «Взгляд» дип атала башлый. Бу исемне яшьләр редакциясен җитәкләгән Эдуард Сагалаев тәкъдим итә. Әлеге тапшыруны әзерләп, алып барган Дмитрий Захаров, Владислав Листьев, Александр Любимов, Владимир Мукусев, Александр Политковский ул чорның иң танылган алып баручы-журналистларына әверелә. Хәзерге жанр классификациясе буенча «Взгляд»ны мәгълүмати-аналитик дип атарлар иде, чөнки аның нигезен хәбәри сюжетлар тәшкил итә, әмма кайбер сюжетлар журналист тикшеренүе жанрында да эшләнә. «Взгляд»ны телевизион журналистикада яңа стиль тудырган мәктәп дип тә саный телевидение белгечләре. Әлеге тапшыруда чыныгу чорын узган тележурналист Владислав Флярковский әйтүенчә, «карашчылар» ябык ишекләрне ачтырасы, бик тирән казыйсы булса да дөреслекне беләсе, аңлашылмаганны аңлыйсы килү омтылышы белән аерылып торды.

1980 нче еллар азагында Ленинград телевидениесе гомумдәүләт статусына ия була, әлеге каналны карау мөмкинлеге дә булдырыла. Тамашачы яратып карый, чөнки Ленинград журналистлары таланты, кыюлыгы, заманчалыгы белән Мәскәүләрне дә уздыра. Аеруча «Музыкальный ринг», «Пятое колесо», «Открытая дверь», «Зебра» тапшырулары тамашачыларны яңалыгы, гадәти булмавы белән җәлеп итә. Бигрәк тә «600 секунд» тапшыруы аерылып тора. Александр Невзоров җирле яңалыклар турында хәбәр итсә дә, ленинградлылар өчен генә түгел, башка төбәкләрдә дә кызыксыну уята. Алып баручының шәхси осталыгы, үз-үзен тотышындагы кискенлек, кырт кисүчәнлек, шул ук вакытта гадилеге дә тамашачыны карарга мәҗбүр итә, моңа әлбәттә Александр Невзоровның журналист тикшеренүе жанры алымнары белән эш итүе дә этәргәндер.

Телевидениедән тыш журналист тикшеренүе жанрында әзерләнгән материаллар көндәлек матбугатта күренә башлый. Хәтта махсус басмалар барлыкка килә. Мәсәлән, 1989 елда язучы Юлиан Семенов «Совершенно секретно» газетасын бастыра башлый. 1990 нчы елда әлеге басмада журналист Артема Боровик эшли башлый. Аңа кадәр «Огонек» журналының Әфганстандагы махсус корреспонденты, «Взгляд» тапшыруының алып баручысы

ярдәмчесе булып эшләп тәҗрибә туплаган журналист баш мөхәррирнең беренче урынбасары вазыйфасын башкара. Аннан үзе баш мөхәррир була. 1991 елны «Россия» телеканалыннан Артем Боровикның «Совершенно секретно» дип аталган тапшыруы күрсәтелә. Нәкъ менә шушы тапшырудан Россия телевидениесендә журналист тикшерүе жанры даими кулланышка керә. «Совершенно секретно» тапшыруы тулысы белән шушы жанр кысаларында әзерләнә. Юстиция министрының отставкага китүе, «Мобитекс» ширкәте, Владислав Листьев, Галина Старовойтова үлеме белән бәйле журналист тикшеренүләре нәкъ менә шушы тапшыруда күрсәтелә. Тора-бара үзәк каналларда журналист тикшеренүе жанрында әзерләнүче әлеге тапшырудан тыш, «Специальный корреспондент», («Россия»), «Профессия репортер» («НТВ»), «Чрезвычайное происшествие» («НТВ»), «Человек и закон» («Беренче канал») тапшырулары да барлыкка килде.

Татарстанда иң беренче телевидение рәсми рәвештә 1959 елның 3 ноябрендә эшли башлый. Утыз ел буе «Татарстан» каналы җирле мәгълүмат белән таныштыручы бердәнбер булып кала. Бары тик үзгәртеп кору елларыннан соң гына Казанда «Эфир» коммерцияле каналы (1991 ел, 15 апрель), «Татарстан – Яңа Гасыр» спутник телевидениесе (2002 ел 26 август), «Первый городской» (2012 ел, 1 декабрь) һәм «Татарстан 24» (2016 ел, июнь) телеканаллары ачылды.

Ярты гасырдан артык вакыт аралыгында телевизион журналистлар тарафыннан хәбәри, аналитик, әдәби-публицистик жанрларда бик күп тапшырулар әзерләп күрсәтелде. Телевизион тикшеренү жанрында эшләүчеләр, кызганычка каршы Татарстан Республикасы журналистлары арасында бик аз. Бу, күрәсең, региональ шартларда эшләү үзенчәлеге белән бәйле. Шулай да иҗтимагый-сәяси тапшырулар редакциясе тарафыннан әлеге четрекле жанрда эшләү омтылышы ясалды. Беренчеләрдән булып журналист тикшеренүләрен «Атна», «Кыйбла» тапшырулары кысаларында Илфат Фәйзрахманов башлап җибәрде. Аларда армиядәге башбаштаклыклар, Чечняга җибәрелгән солдатлар язмышы, пирамида корбаннары һәм башка мәсьәләләр турында бәян ителде. «Татарстан – атналык күзәтү» тапшыруында да аерым сюжетлар эшләнде. Мәсәлән, Фирдүс Гыймалтдиновның Чиләбе өлкәсендәге татарлар язмышы хакындагы материаллары, нәкъ менә

журналист тикшеренүе жанрында. Шулай ук «Эфир» каналында башланып, «Казан» телекомпаниясендә дәвам иткән «Адымнар» тапшыруында да Сәрия Хәбибиуллина мөхәррир булган вакыттан аерым сюжетлар журналист тикшеренүе алымнарын файдаланып әзерләнә. Әлеге жанр үзенчәлекләрен «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе журналисты, «Авыл офыклары» тапшыруы авторы һәм алып баручысы Раиф Гыймадиев оста файдалана.

«Татарстан – Яңа Гасыр» каналының «7 дней» тапшыруында да кайбер сюжетлар журналист тикшеренүе жанрында эшләнә. Әлеге тикшеренүләрнең авторлары: Михаил Любимов, Рәмис Латыйпов, Илзирә Сибирцева, Игорь Севрюгин, Зөфәр Дәүләтшин, Тимур Бикмурзин, Ренат Әхмәтҗанов.

## *2. Телевидениедә журналист тикшеренүе жанрында иҗат итү үзенчәлекләре*

Журналист тикшеренүенең башка гаммәви мәгълүмат чараларындагы кебек үк телевидениедә дә әзерлек өлеше бар. Нигездә, һәр тикшеренүнең асылы – барырга тиешле оешмаларны, очрашасы кешеләрне ачыклау, планын төзү; тикшеренү өчен сайланылган темага кагылышлы беренче мәгълүматны туплау; чыганаклар белән эшләү; җыелган материалның эзлеклелеген барлау; исбатлау, дәлилләү өчен нигез булырлык рәсми документларны табу, төп интервью уздыру; юридик экспертиза (кирәк дип табылса) һәм материалны әзерләүдән гыйбарәт. Моннан тыш, телевидение өчен әзерләнгән тикшеренүдә төп интервьюдан тыш, экспертлар чыгышы, шулай ук башка белгечләрнең, әлеге тикшеренүгә катнашы булучыларның синхрон рәвешендә аңлатма-шәрехләүләре кулланылырга мөмкин.

Тикшеренергә алыначак тема нинди генә булмасын, барыбер, хакыйкатьне, дөреслекне исбат итү, ялгышлыкны, закон бозып башкарылган гамәлне фаш итү белән бәйле. Шуңа да әлеге тема тикшеренергә алынырга мәҗбүр итәрлек җитди сәбәпләргә нигезләнә. Бу жанрда эшләүче журналист, кайбер очракта хәтта, хокук саклау органнары тарафыннан да тикшерелеп бетмәгән, очына чыга алмаган җинаятьләрдән кисәтә, гомумән булдырмау өчен үз-үзен дә аямый. Журналистлар арасында нәкъ менә журналист тикшеренүе жанрында эшләүчеләрнең гомере куркыныч астына куела.

Тикшеренү эшенә журналист берәр вакыйга, очрак, көтемәгән хәл тәэсирендә яисә шәхси кызыксыну нәтиҗәсендә алынырга мөмкин. Шулай ук халык арасында гайбәт буларак таралган мәгълүмат та журналист тикшеренүе әзерләү өчен этәргеч биргән очраклар бар.

Телевидениенең кайчандыр могҗиза буларак кабул ителгәненә бүгенге тамашачыны ышындырып та булмый. Һәр өйдә телевизор булу да гадәти. Телевидениедә эшләүчеләрнең һөнәри үзенчәлекләрен тамашачы еш кына матур кыяфәт белән генә чикли. Телевидение журналистика тармагы булып формалашып кына килгән чорда, телевизион журналистка хәтта начар ярлык та тагылган иде. Янәсе, телевизион хәбәрче әйтмә һәм язма сөйләм үзенчәлеклерен аңлап бетерми, мәсәлән, газетада эшләгән теләсә кайсы журналист телевиденидә эшли ала, ә телевизион репортерны баш мөхәррир, гомумән, газета редакциясенә эшкә алмаячак. Әлеге ялгыш фикер шактый вакыт тележурналистның иҗади сәләтен кечерәйтеп күрсәтте. Риман Гыйлемханов, Филисә Хәкимова, Роберт Миңнуллиннар да телевидениедә эшләгән иде, ләкин аларның басма матбугатта һөнәри осталыгы кимемәде. Шулай ук телевизион журналист хезмәтенең асылы камера, микрофон һәм башка техник җиһазларга бәйле, дип аңлату да дөреслеккә туры килми. Журналист хезмәтен техникага гына кайтарып калдыру телевидениедә иҗади һөнәр ияләре юк, диюгә тиң. Ә алар булган, бар һәм булачак. Чөнки кыска гына хәбәрне җиткерү өчен дә сценарий әзерләргә кирәк. Газетада басылган бер генә мәкалә, хәтта иң шәп дигәне дә, телевизион тапшыруда эшкәртелмәгән килеш сценарий буларак кулланыла алмый.

Сценарий һәрбер таршыру өчен аерым язылса да, гомуми нигезе бер. Әлбәттә, очерк сценарие белән телевизион хәбәрләр сюжетының сценарие бер үк түгел. Кайбер корреспондентлар, ашыгыч сюжет әзерләгәндә, сценарийны планлаштырып, күзаллап кына яза. Ә ни өчен кирәк соң сценарий? Ансыз эшләп буламы? Бу сорауларга җавап биргәнче, язма сүз белән әйтмә сүзнең, бигрәк тә телевизион сөйләмнең аермасын ачыклыйк.

*Телевидение сөйләменең* гамәлгә ашыру шарты тел чараларын экран контексты таләбе нәтиҗәсендә сайлаудан барлыкка килә. Экран контексты күрсәтү чараларыннан башлана. Телевидениенең өстенлеге – чынбарлыкта булган вакыйганы күрсәтү белән бергә,

тамашачыда әлеге вакыйгада катнашкан, үз күзләре белән күргән хис тудыра алуда.

Телевизион сөйләм күрмә рәт, әйтмә рәт һәм тавыш берәмлекләренең үзара берләшүеннән туа. Шушы компонентларның үзара ярашуы телевидение сөйләмен барлыкка китерә.

Газета журналистының әдәби образ тудыруда төп чарасы сүз һәм укучы күзаллавы. Ә телевизион корреспондентның сурәтләү чаралары болар белән генә чикләнми. Беренчедән, сүзнең сөйләм үзенчәлеге (тавыш тембры, интонация), икенчедән, күрмә рәт, ягъни видеосурәт тәэсире. Корресондент хәбәрне вакыйга урыныннан турыдан-туры җиткерергә дә мөмкин. Тамашачыга тәэсир итү, ышандыру көче зур булу сәбәпле, телевизион сюжет әзерләгәндә, стендап алымы да еш кулланла. Видеорәтнең образлылыгы параллель яисә ассоциатив монтаж алым кулланып та арттырыла ала. Өстәвенә, күрү, ишетү һәм аңлау принцибы да мәгънәви образлылыкны көчәйтү үзенчәлегенә ия. Мәсәлән, ришвәт алганда тотылган җитәкче турында видеосюжет әзерләгәндә, корреспондент, ким дигәндә, кадр артына укылачак текст яза һәм синхрон куллана. Текстта кемнең, нинди шартларда, нәрсә эшләве һәм башка мәгълүматлар бирелә. Әлеге текстны монтажлау өчен сурәт нинди булырга тиеш? Әгәр хокук саклау хезмәткәрләренең үзләре тарафыннан төшерелгән оператив видеоязмалары булса, һичшиксез, аны кулланырга кирәк, чөнки тамашачы өчен бу рәвешле дәлилләп күрсәтү кызык, дөреслекне ассызыклый. Мәсәлән, текстны укыганда ришвәт биргән җитәкченең өч катлы шәхси өе янындагы бассейннан йөзеп чыгып, кызынып ятуы күрсәтелсә, тамашачыда канәгатьсезлек хисе туа, җитәкчеләр рәхәткә чыдый алмый, дип нәфрәтләнә. Яисә кадр артында шул ук текст укылганда, кадрда әлеге җитәкченең авыру хатынына су эчереп, балаларына ашарга пешереп, дәрес әзерләтеп йөргән вакытын күрсәтсәк, телевизор караучы аны кызганачак, хәтта ришвәтне авыру хатынына ярдәм итәр өчен алган, дигән фикер дә туарга мөмкин. Димәк, тамашачыга бер үк текстны монтаж үзенчәлекләрен файдаланып, сурәтләр бәрабәренә төрле мәгънәдә җиткерергә мөмкин.

Шулай ук телевизион материал әзерләгәндә, стендап яисә корреспондентның кадрда чыгыш алымы еш кулланыла. Бу очракта

төшерү урыны сурәттә дәлил буларак күрсәтелә. Шуңа да яздырганчы фонның мәгънәви бөтенлеккә хилафлык китермәвен тикшереп алу зарур. Интервью алган очракта да шул ук хәл. Әгәр арткы фонда кемдер басып, комачаулап тора икән, нинди генә әһәмиятле фикер әйтелсә дә, эфирга бирелми калачак.

Телевизион текстка бик таләпчән булырга кирәк. Текст гади тел белән, кыска җөмләләр ярдәмендә, җиңел аңлашыла торган итеп языла тиеш. Бу телевизион материал әзерләгәнгә **беренче кагыйдә.**

Камерага төшерер алдыннан ни турында сөйлисен генә түгел, ә сүзләрнең тамашачыга ничек тәэсир итәчәген дә күзалларга, хәтта ничек төшереләчәген, нинди алымнар кулланылачагын ачыкларга кирәк. Монысы **икенче кагыйдә**. Экранда соңгы елларда криминаль тематикага бәйле тапшырулар күбәеп китте. Федераль каналлар гына түгел җирле телевидение компанияләре дә тамашачыга криминаль хроника күрсәтә. Мәсәлән: «Досье 02» , «Перехват», «Чрезвычайка», «НЭП», «Татарстан без коррупции» тапшырулары нәкъ шундыйлардан. Кайсыларыдыр ябыла, ләкин алар урынына яңалары күрсәтелә. Нәкъ менә шушы криминаль темага багышланган тапшыруларда журналист тикшеренүе жанры бик актив кулланыла. Шунысын да белү мөһим, әлеге темага алынган журналист үз хокукларын, материал әзерләнәчәк темага кагылышлы кануннарны, этик кагыйдәләрне аерата яхшы белергә тиеш. Әйтик, транспорт һәләкәте булган урында үлүчеләр булса аны ничек күрсәтергә, тамашачыга вакыйга урыныннан барысын да ничек бар шулай күрсәтү урынлы булачакмы? Шушы сорауларга җавап бирә алмаса журналист тикшеренүе дә, гомумән сюжет та дөрес корылмаячак. Кайбер тәҗрибәсез корреспондентлар сюжетта әллә ничә үле гәүдә, яисә күңелсез очракның башка нечкәлекләрен күрсәтеп тамашачыны тетрәнергә мәҗбүр итә. Ләкин профессиональ журналист тамашачыны куркытырга тиеш түгел. Киресенчә, күңелсез очраклар килеп чыкмасын өчен уйланырга этәрергә кирәк.

Телевизион журналистның газета корреспондентына караганда әңгәмәдәше алдында өстенлеге бар. Камерага яздырылган интервьюдан беркем дә баш тарта алмый. Сөйләгәнен кире кагып, ул кеше мин түгел идем дип, журналистны мәхкәмәгә биреп гаепкә тарту да нәтиҗәсез калачак. Димәк, экран аша

житкерелгән хәбәрнең дәлилләү көче зур. Моннан үзеннән-үзе **өченче кагыйдә** туа, вакыйгада катнашучылар белән күбрәк аралашып, фикерләрен, кичерешләрен камерага яздырып калырга кирәк. Чөнки кадр артында сөйләнәчәк текстка караганда, вакыйганы белүчеләр сөйләгәнне тыңлау күбкә тәэсирлерәк. Телевизион журналистка телевидениенең терминологиясен белеп эш итү дә мөһим. Мәсәлән, стендапның ни икәнен аңлатып үткән идек, ә синхрон – журналист кирәк дип тапкан белгеч, шаһит, гомумән кемнең дә булса кадрда сөйләме.

Шушы өч кагыйдәне дөрес файдаланырга өйрәнсә, телевизион журналист өчен сценарий язу шактый җиңеләя. Телевидение, белүебезчә, күмәк хезмәт. Мәсәлән, газетта әзер материалның басылмый калынуы бик сирәк очракта гына була. Ә язу бары тик авторга бәйле. Телевизион журналистның төп хезмәттәше оператор. Әгәр ул кирәкле кадрларны төшермәсә, синхрон яздырганда кирәкмәгән өстәмә тавышлар керсә, гомумән, язма барышында микрофон дөрес эшләмәсә, сюжет әзерләнми калачак. Кайвакыт монтаж ясаучы материалны ялгыш сөрттереп тә атарга мөмкин. Шуңа да телевизион журналист, бу җаваплылыкны тоеп, хезмәттәшләре белән аңлашып эшләргә тиеш. Нәкъ менә шушындый күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен телевизион журналистка эшне сценарийдан башларга кирәк тә. Ул башта план рәвешендә генә булырга мөмкин. Ул планда, гадәттә, җавап бирелергә тиеш сораулар языла:

1. Төшерү төркеменә нинди чаралар белән максатка ирешергә?
2. Кайсы жанрда эшләсәң, материал үтемлерәк була?
3. Сюжетның структурасы нидән гыйбарәт?
4. Материалны әзерләгәндә, кемнәрдән интервью алыначак, ә кемнәрнең синхроны кулланылачак?
5. Эшнең күләме, аны башкарыр өчен иҗади һәм техник чаралар нидән гыйбарәт?

Бу телевизион сюжет әзерләгәндә туа торган гомуми сораулар. Һәр материалның үзенә генә хас нечкәлекләре була. Гомумиләштерелгән әлеге сорауларга җаваплар да биреп барыйк.

***Төшерү төркеменә нинди чаралар белән максатка ирешергә?*** Бу сорауга җавап биреп, без тамашачы нәрсә белергә тиеш һәм тамашачыга нәрсә әйтергә телибез икәнлеген аңлатабыз. Алай гына да түгел, без тамашачыны кайбер очракта кисәтәбез,

оялтабыз, игътибар иттерәбез. Мәсәлән:

- *Оятсыз оялса, бик нык ояла икән, ошбу караклар да яме качкан чырайларын яшереп маташалар.*
- *Мәхәббәт белән уйнарга ярамый, уеннан уймак чыгарга мөмкин.*
- *Күзләрегезне яхшылабрак ачыгыз, югары осланлылыр, район башлыгыгыз бит карак!*

Җөмләләр кыска һәм аңлаешлы.

Жанрлар төрлелегенә килгәндә, телевидение корреспонденты журналистика теоретиклары тәкъдим иткән гомуми классификациягә таянып эшли. Әлбәттә, телевизион журналистның әйтү, күрсәтү һәм техник үзенчәлекләр белән бәйле аермалыклар исәпкә алына. Шунысын да искәртеп үтү мөһим, башлап җибәрүче корреспондент өчен башта хәбәри жанларда эшләү мәктәбен үтү соңрак аналитик һәм публицистик жанрларда эшләүне күпкә җиңеләйтә.

Журналист тикшеренүе буларак тәкъдим ителгән тапшырулар телевидениедә нигездә репортаж, очерк яисә фильм һәм ток-шоу жанрында эшләнелә.

Репортаж – бер вакыйганың эзлекле бер үсештә чагылдыру. Корреспондент белән бергә тамашачы чынбарлыктагы кебек вакыйга үзәгендә «кайный». Репортажның бу төренә мисал итеп «Чистосердечное признание», «Дежурная часть» тапшыруларын атарга була.

Очерк яисә фильм рәвешенә эшләгән журналист тикшеренүенә үткән вакыйгаларны барлау, геройның язмышын аңлату, тарихи алшартларына күзәтү ясау, кайбер очракта проблеманың глобальлеген ассызыклау хас. «Совершенно секретно», «Криминальная Россия», «Следствие вели» тапшырулары бу юнәлештә үрнәк булган иде.

«Ток-шоу» – телевизион журналистика жанрлары системасында чагыштырмача яңа калып. Асылда ул – тамаша. Тамашада алып баручы (алар берничә дә булырга мөмкин), студиядәге кунаклар, экспертлар, үз кичереш, хис-тойгыларын белдерү өчен махсус чакырылган тамашачылар катнаша. Кайбер очракларда журналист тикшеренүе ток-шоу жанрын формат буларак куллана. Бу тамашачыга тәэсир итүнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен махсус эшләнә. «Жди меня», «Независимое

расседование» ток-шоу форматында эшләнгән тапшырулар.

Телевидениедә теләсә нинди жанрдагы сюжет билгеле бер калыпка нигезләнеп эшләнә. Калыпның гомуми үрнәге:

- Видеорәт
- Репортаж алымы яисә композициясен планлаштырып (яктылык, ракурс, фон кебек өстәмә эффектларны кулланып) төшерелгән материал
- Тавыш
- Кадр артындагы текст
- Стенд-ап
- Синхрон
- Музыка
- Интершум

Видеоязма ике компоненттан тора. Берсе – сурәт, икенчесе – тавыш. Тавыш бу очракта җыелма атама. Ул үз эченә кадр артында укылачак текстны, интертавышны, синхронны, музыканы, стенд-апны ала.

Сурәт – төрле планда, төрле ракурста төшерелгән кадрлар җыелмасы. Журналист тикшенерүе әзерләнгәндә, өстәмә видеоматериаллар да кулланыла. Аеруча хокук саклау хезмәткәрләре тарафыннан төшерелгән тикшеренү экспериментлары еш кулланыла. Шулай ук дәүләт яисә шәхси архивта сакланган видеоязмалар да урынлы булган очракта файдаланыла. Видеорәт буларак сайлап алынган кадрлар мәгънәви бөтенлекне тудырырга ярдәм итә. Сурәт сүзне дәлилли, тулылындыра, ләкин кабатламый. Сүз дә үз чиратында өстәмә мәгълүмат бирә, төп фикерне җиткерә. Гомумән, кадр артындагы текст белән, синхрондагы аңлатма, стендапта җиткереләсе мәгълүмат берсен-берсе тулылындып бармаса, фикер өзелә. Һәрберсе үзенә бер функция үтәсә дә бергәләшеп бөрбөтен текст барлыкка китерәләр. Моның өчен кадр артындагы текст белән синхрон чыгышын бәйләүче мантыйкый «күпер»-җөмләләр булырга тиеш.

Билгеле бер тема мисалында журналист тикшеренүе өчен әзерләнәчәк калып-план болайрак булырга мөмкин. Тема: Юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү.

1. Асфальты ашалып беткән чокыр-чакырлы юл, машиналар шул чокырларга төшмәс өчен каршы полосодагы юлга чыгып

әйләнеп узарга мәҗбүр. Чират, бөке, машина сигналы кычкырткан тавыш, шоферлар ачулы;

2. Синхрон ГИБДД. Әлеге юлда күпме һаләкәт очраклары теркәлгән.

3. Синхрон. Машина йөртүчеләр зары;

4. Коеп яңгыр ява, Болотная урамындагы юл чокыры янында корреспондент стендап яздыра. Кулында метр, яңгыр суы белән тулган чокырның тирәнлеген үлчи, аңлатма бирә;

5. Шәһәрнең иң яхшы сыйфатлы юллары;

6. Синхрон «Автодор» хезмәте җитәкчесе аңлатмасы, алар ягыннан гаеп юклыгын аңлатуы;

7. Юл төзүчеләр бригадасы җитәкчесе юл төзү материалларының сыйфатсыз булуы, җитеп тә бетмәве турында сөйли. Әле дә хезмәт хакы алмаганнарын, бу хакта судка мөрәҗәгать итүләрен хәбәр итә;

8. Журналист суд карары белән килешмәвен белдерә, әлеге җимерек юлларны төзекләндерергә тотылырга тиешле акчаларның югалуын документлар ярдәмендә дәлилли. Гомумән, «Автодор» хезмәткәрләре хисабында әлеге юллар кәгазьдә күптән төзекләндерелгән, дип исәпләнелүен исбатлый;

9. Журналист әлеге җимерек юлларда зыян күргән кешеләр хакында статистик мәгълүматлар бирә;

10. Әлеге чокырлы юлда һәлакәткә очраган шофер синхроны;

11. Синхрон. Автодорда эшләгән, ләкин аннан куылган элеккеге шофер-хезмәткәр юл төзү өчен тиешле булган чимал белән үз кесәләренә акча эшләүчеләрне фаш итә.

Шушы рәвешле әзерләнгән калыпны сценарий итү өчен текст кына язасы кала. Димәк, сценарий язганда, бер якка нәрсә төшереләчәге, ә бер якка ни сөйләнәчәге языла. Әлбәттә, мисал итеп китерелгән план-калып ул шартлы, һәр журналистның үз эш стиле бар.

Шулай да тикшеренү жанрында эшләргә җыенган журналист, иң беренче чиратта, «Гаммәви мәгълүмат чаралары турындагы» Законны бик әйбәт, хәтта яттан белергә тиеш. Яшерен камера белән төшерү белән бәйле өлешенә аеруча игътибарлы булу да кайбер күңелсезлекләрдән саклап кала.

Съемкага барганда техник җиһазларның җитәрлек булуын

тикшерү дә мөһим. Мәсәлән, кассета, флешка, аккумулятор җитәме?

Журналист тикшеренүе жанрында эшләүчеләргә еш кына хокук саклау органнары хезмәткәрләре үзләре үк юлларына аркылы төшә, шул шартларда да журналист югалып калмый. Эшеннән ваз кичми. Бер сүз белән генә әйткәндә, бу фидакарьлек һөнәргә бирелгәнлек дип атала. Тамашачы да бит нәкъ шундый журналистны хөрмәт итә, тапшыруларын күтәп ала.

### *3. Журналист тикшеренүе жанрында әзерләнгән материалга анализ*

«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең «Авыл офыклары» тапшыруында журналист тишеренүе жанрында эшләнгән материаллар шактый. Раиф Гыймадиев материалларын репортаж алымын кулланып әзерли, ягъни вакыйганы эзлекле бер үсештә чагылдыра. Корреспондент белән бергә тамашачы чынбарлыктагы кебек вакыйга үзәгендә «кайный». Мәсәлән, Кама Тамагы районыннан әзерләнгән материалында корреспондент ни өчен районның игенне җыеп алу күрсәткечләре түбән булуын тикшерә, анализлый.

Уракның соңга калу сәбәпләрен ачыклауны «Идел» җәмгыяте басуларыннан башлый. Чөнки кызу эш вакытында әлеге кырда комбайннар эшләми, сәбәбе – суктырылган игенне бушатырга машина юк. Корреспондент, материалына өстәмә мәгълүматлар табып, әлеге районда комбайннарның да чагыштырмача аз булуын искәртә.

Тикшеренүнең тәэсирен статистик мәгълүматләр белән баета. Аеруча комбайнчыларның сөйләве тәэсирле. Журналист «Идел» җәмгыяте карамагындагы урып-җыю барышында килеп чыккан проблемаларны комбайнчылар, баш агроном, «Кармал» бүлеге җитәкчесе һәм «Ак Барс» холдинг компаниясе генераль директорының агросәнәгать комплексы буенча урынбасары аша аңлатып бирә. Шул рәвешчә фикер төрлелеге барлыкка килә. Синхрон бирелгәндә, сөйләүченең исем-фамилиясен, вазыйфасын да титр белән күрсәтү мәҗбүри. Журналист аңлатма бирер өчен теләсә кемне сайлап алмый, шушы темага кагылышлы кешеләрне җәлеп итә.

Мәсьәләне хәл итү юлын да күрсәтә Раиф Гыймадиев. «*Урынлы*

*сорау туа, хәл шундый кискен булгач, нигә читтән, башка районнардан, күрше өлкәләрдән ялламаганнар соң ашлык ташу өчен машиналарны?»* – дип сорау куя автор. Тикшеренү барышында шәхси йөк машиналары булган кешеләрне дә эшкә чакырырга мөмкинлеген искәртә журналист. Сәбәбен дә ачыклый: «*Узган елда күрсәткән хезмәтләр өчен машина хуҗаларына һаман түләнмәү әле бер хәл икән. Игенче механизаторлар белән сөйләшә торгач, «Идел» җәмгыятендә хезмәт хакларының да вакытында бирелмәве ачыкланды»*.

Журналист тикшеренүенең азагында «Идел» җәмгыятендә килеп чыккан проблеманың чишү юлларын «Ак Барс» холдинг компаниясе генераль директорының агросәнәгать комплексы буенча урынбасары әйтеп бирә. Нәтиҗә ясап әйткәндә, журналист үз максатына ирешкән. Барлык сорауларга да җавап табылган**.**
Журналист тикшеренүе жанрында эшләнгән материалның үрнәге:

**Материалның исеме: Кама Тамагы**
**Материалның авторы: Раиф Гыймадиев**
**Материалның эфирга чыгу көне: 23.09.17**
**Материалның эфирга чыгу каналлары һәм вакыты:**
**8:30 – Россия 1;**
**18:15 – Россия 24.**
**Журналист кадрда:**

*Шөкер, сентябрь аенда да аграрчыларга уңай һава торышы булмады түгел. Шактый район игенне югалтуларсыз, быелгы соңарган урак өчен вакытында җыеп алуга иреште. Республика буенча 23нче сентябрьгә уңышны нибары 18 процент мәйданда суктырып аласы калган иде. Барлыгы 4 350 мең тонна икмәк амбарларга урнаштырылган инде.*

*Сез «Авыл офыклары» тапшыруын карыйсыз, исәнмесез! Быел иген уңышы һәр гектардан уртача 34әр центнер чыккан дип күрсәтелә әлегә. Иң мул уңыш – Зәй районында. Зәйлеләр гектардан 49,9 центнер белән уракны тәмамлады. Аннан 46шар центнер белән Нурлат һәм 44әр центнер уңыш белән Сарман игенчеләре куандыра.*

*Ике дистәләп районда урып-җыю эшләре тулысынча тәмамланды. Ә менә Әгерҗе, Тукай, Кама Тамагы районнарында урак тоткарлана. Аларда әле кырык бишәр процент җыелмаган кырлар бар. Инде болай да республика районнары арасында иң аз*

*иген мәйданнары булган төбәкнең берсе - Кама Тамагында уракның соңару сәбәпләре белән танышып кайттык бу атнада.*

**Кадр артында:** Быел Кама Тамагы районында үстерелгән 21,5 мең гектар мәйдандагы игеннәрнең 1 230 гектары «Кызыл шәрыкъ» хуҗалыгыныкы, 923 гектардагысы фермерларныкы һәм иң саллы өлеш – 19,5 мең гектар мәйданда икмәк «Ак Барс» холдингына караган «Идел» җәмгыятенеке икән. Без килгән көнгә – 19 нчы сентябрьгә, районда әле барлык игеннәрнең 18 проценты җыеп алынмаган иде. Республика яссылыгында караганда, бу иң начар күрсәткеч.

Синхрон. **Илфат Вәлиев - Кама Тамагы районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе** (14,41,28/14,39,33)

**Кадр артында:** Әлбәттә инде, уракның озакка сузылу сәбәпләрен ачыклау максатыннан без «Ак Барс» холдингының «Идел» җәмгыяте басуларына юнәлдек. Көн бик матур, кояшлы, җылы иде. Читтән караганда, хәйран мул уңышлы күренүче бодай басуында заманча, зур егәрлекле комбайннарның икмәк суктырып йөргәнен күргәч, күңелләр тагын да күтәрелеп китте. Эш гөрли бит... Ләкин куанычлы хисләр озакка бармады. Кырдагы җанлылыкка хозурланып, видеоязмага төшерә генә башладык, ике Нью-холланд  комбайны туктап калды. Бункерлары ашлык белән тулган. Ә тулы бункерларны бушатырга машина юк та юк.

Синхрон. **Дамир Заһидуллин - «Идел» җәмгыяте комбайнчысы** (14,15,20/14,15,52)

**Кадр артында:** Аңлашылганча, андый шартларда әлләни нәтиҗәле эшләп булмый инде ул. Көнлек ашлык суктыру күләме ике тапкырга кими дигән сүз бит. Дамир Заһидуллин да быелгы урак чорында зур күрсәткечләргә ирешә алмаган.

Синхрон. **Дамир Заһидуллин - «Идел» җәмгыяте комбайнчысы** (14,16,35)

**Кадр артында:** Бәлки башка комбайнчыларның эшләре көйлерәк барадыр дип, басуның икенче башына киттек. Барсак, анда да өч комбайн туктап тора иде. Аларның да бункерлары тулган, алар да ашлык бушатырга машина көтәләр. Әлеге комбайнчылар белән әңгәмәнең эчтәлеге дә охшаш булды.

Синхрон. **Илдар Әхмәтшин - «Идел» җәмгыяте комбайнчысы (14,26,55). Мөдәрис Минһаҗев - «Идел»**

**җәмгыяте комбайнчысы**

**Кадр артында:** Уртача исәпләгәндә, көнгә нибары күп дигәндә 430ар центнер гына ашлык суктырганнар килеп чыга. Әлбәттә, мондый заманча, зур егәрлекле комбаннар өчен бу бик аз күрсәткеч. Игенче-механизаторлар үзләреннән торганның барысын да эшлиләр, тырышалар ди, «Идел» җәмгыятенең баш агрономы.

Синхрон. **Фәрит Садыйков – «Идел» җәмгыятенең баш агрономы** (14,37,47).

**Кадр артында:** Көнлек ашлык суктыру күләменең азлыгы әлеге дә баягы машиналар булмауга бәйле икән. Комбайннар бункер тулганчы эшләп алалар да, машина көтеп сәгать буе басып торырга мәҗбүр.

Синхрон. **Илдар Әхмәтшин - «Идел» җәмгыяте комбайнчысы (14,29,31/14,27,45). Мөдәрис Минһаҗев - «Идел» җәмгыяте комбайнчысы**

**Кадр артында:** «Идел» җәмгыятендә урак соңаруның төп сәбәбе әнә шул икән. Дөрес, биредә, тулаем алганда, Кама Тамагы районында, комбайннарның аз булуы да мәгълүм. Мисал өчен, «Идел» җәмгыятендә 19,5 мең гектардагы игеннәрне суктырып алу өчен үзләренең нибары 20 генә комбайннары бар. Бер комбайнга уртача бер мең гектарга якын иген мәйданнары туры килә дигән сүз. Бу бик югары күрсәткеч. Ләкин комбайнчыларның һәм, ни гаҗәп, җитәкчеләрнең дә аныклавынча, урак соңаруның төп сәбәбе комбайннар аз булуда түгел.

Синхрон. **Хәйдәр Миңнуллин - «Идел» җәмгыятенең «Кармал» бүлеге җитәкчесе** (14,23,57), **Фәрит Садыйков – «Идел» җәмгыятенең баш агрономы** (14,08,05), **Илфат Вәлиев - Кама Тамагы районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе** (14,39,50).

**Кадр артында:** Урынлы сорау туа, хәл шундый кискен булгач, нигә читтән, башка районнардан, күрше өлкәләрдән ялламаганнар соң ашлык ташу өчен машиналарны? Кызганычка каршы, әлеге сорауны «Идел» җәмгыятенең директорына бирә алмадык. Ул районда түгел иде, Казанга чакыртканнар икән. Баш агроном булган машиналарны санап чыкты.

Синхрон. **Фәрит Садыйков – «Идел» җәмгыятенең баш агрономы** (14,09,21).

**Кадр артында:** Аңлашылганча, 18 машина белән генә

комбайннарга тоткарлык ясамыйча ашлыкны ташып өлгерә алмаганнар. Баш агроном сүзләренә караганда, соңгы көннәрдә килгән ярдәм арткан, бүген инде 31 машина ашлык ташый ди. Ләкин комбайннар саны да ишәйгән. Бер Буа районыннан гына да ярдәмгә 13 комбайн килгән бит. Нәтиҗәдә, барыбер машиналар җитешми. Хәлгә аңлатма бирүне үтенеп, телефон элемтәсе аша җәмгыятьнең баш оешмасына – «Ак Барс» холдинг компаниясе генераль директорының агросәнәгать комплексы буенча урынбасарына мөрәҗәгать иттек.

Синхрон. **Камил Галиев - «Ак Барс» холдинг компаниясе генераль директорының агросәнәгать комплексы буенча урынбасары** (5,47/6,21).

**Кадр артында:** Нәтиҗәдә, чынбарлыктагы хәлнең нинди икәнен күреп үттек инде. Комбайннар машина көтеп тилмерә. Районда булган шәхси «КамАЗ»ларның да бик азы гына эшкә җәлеп ителгән.

Синхрон. **Илфат Вәлиев - Кама Тамагы районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе** (14,40,44), **Камил Галиев - «Ак Барс» холдинг компаниясе генераль директорының агросәнәгать комплексы буенча урынбасары** (3,45).

**Кадр артында:** Узган елда күрсәткән хезмәтләр өчен машина хуҗаларына һаман түләнмәү әле бер хәл икән. Игенче механизаторлар белән сөйләшә торгач, «Идел» җәмгыятендә хезмәт хакларының да вакытында бирелмәве ачыкланды.

Синхрон. **Дамир Заһидуллин - «Идел» җәмгыяте комбайнчысы** (14,16,55/14,17,14), **Солтан Шәкүров - «Идел» җәмгыяте комбайнчысы** (14,34,26).

**Кадр артында:** Ә бәлки белгечләргә, җитәкчеләргә вакытында биреләдер дип, хезмәт хакын кайсы айга алулары белән кызыксынам. Баксаң, аларның да акча күргәннәре юк икән.

Синхрон. **Фәрит Садыйков – «Идел» җәмгыятенең баш агрономы** (14,36,11), **Хәйдәр Миңнуллин - «Идел» җәмгыятенең «Кармал» бүлеге җитәкчесе** (14,38,29), **Илфат Вәлиев - Кама Тамагы районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе** (14,44,18).

**Кадр артында:** Авыр хәл. Инде терлекләрне сата башласалар, проблема тагын да катлауланырга мөмкин. Шуны аңлап, «Ак Барс»

холдинг компаниясе җитәкчелеге мәсьәләне чишү юлларын эзли анысы.

Синхрон. **Камил Галиев - «Ак Барс» холдинг компаниясе генераль директорының агросәнәгать комплексы буенча урынбасары** (0,20).

**Кадр артында:** Быел ашлыкны сату бәясе түбән булу да холдинг хуҗалыкларының хәлен катлауландыра, билгеле. Ләкин барыбер үстергән уңышны җыеп алу беренчел бурыч булып кала. Шулай авырлыклар белән булса да, бу көннәрдә Кама Тамагындагы «Идел» җәмгыятендә дә уракны тәмамларга ниятлиләр.

**Журналист кадрда:** Шулай итеп, республика буенча тагын 20 мең гектар мәйданда игеннәрне суктырып аласы бар иде 22 сентябрь мәгълүматлары буенча. Гади математик исәпләүгә караганда, тулаем икмәк җыемы көтелгән 5 миллион тонна чиген узар кебек.

Инде югалтуларсыз җыеп алып бетерергә язсын.

***Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр:***

1. Телевидениедә журналист тикшеренүе тапшырулары кайчан барлыкка килгән?
2. Ни өчен «Взгляд» тапшыруын телевизион журналистикада яңа стиль мәктәбе дип атыйбыз?
3. Журналист тикшеренүе жанрында эшләүче журналистлар эшчәнлегенә сыйфатлама бирегез.
4. Татарстан телевидениесендә журналист тикшеренүе жанрының башлангычы.
5. Журналист тикшеренүенең төп этаплары нидән гыйбәрәт?
6. Журналист тикшеренүенең телевизион үзенчәлеге.
7. Журналист тикшеренүе буларак репортаж үзенчәлеге.
8. Журналист тикшеренүе жанрында эшләнгән очерк яисә тапшыруларның исемнәрен атагыз.
9. «Ток-шоу»да журналист тикшеренүе була аламы?
10. Журналист нинди кануннар нигезендә эшли?

## *ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК. ЖУРНАЛИСТ ТИКШЕРҮЕН АЛЫП БАРУ МЕТОДИКАСЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ*

### *1. Тикшерүгә әзерлек*

Тикшерүгә әзерлек – ул, иң беренче чиратта, мәгълүмат туплау белән бәйле. Бер карасаң, бу күренеш бүтән жанрларда иҗат итүче журналистларга да хас, тик башкалардан аермалы буларак, журналист-тикшерүче өчен бу мәсьәлә кыенлаша. М.Шостак үзенең «Репортер: профессионализм и этика» китабында мондый фикер әйтә: *«Тикшерү яшерен фактларны эзләп табуга нигезләнгән автор версиясен тәкъдим итә. Аның максаты – ситуацияне «ачу», «проблемага чыгу». Моның өчен журналист фактларны үзе таба. Ул детектив әсәр язган кебек гаепләрлек мөмкинлек булдыру өчен фактлар эзли. Тик моны конкрет кемнедер гаепләү түгел, ә дөреслекне ачу өчен эшли»*. Шулай итеп, журналист-тикшерүче актуаль һәм зур әһәмияткә ия мәгълүматны туплау белән генә чикләнмичә, җәмгыятьтәге яшерен күренешләр белән эш итә. Журналистка һәрвакыт тикшерену предметын күз алдында тотарга кирәк.

Тикшерү предметы теләсә кайсы очракта түбәндәге өч төркемнең берсенә карый:

1. Ачылмаган эшләр, аңлашылмаган вакыйгалар, башкаручысы табылмаган шау-шулы җинаятьләр. Мәсәлән, «Московский комсомолец» газетасы журналисты Дмитрий Холодов, «Новая газета» журналисты Игорь Домников, Анна Политковская, Наталья Эстемироваларны үтерүчеләр әле һаман да табылмаган. Шулай ук Артем Боровик үлеме яки Бермуд өчпочмагы табышмагында үтерүче кем икәнлеге һәм өчпочмакта ниләр булып ятуына берәү дә җавап бирә алмый. Тик бу очракта эшләү җиңелрәк, чөнки бу табышмакларның чишелүе күпләрне кызыксындыра. Журналист рәсми оешмалар ярдәменә таяна ала.

2. Ачылган, әмма журналистта шик уяткан эшләр. Нигә? Ничек? Кем? Шундый сорауларга җаваплар табылган, кабул ителгән фикер дә бар, тик журналист бу фикерне шик астына ала һәм үзе тикшерү эшен башлый. Мәсәлән, Николай II гаиләсе мәетләре инде кабул ителгән тәгълимат буенча табылган һәм Санкт-Петербургта күмелгән. Һәм менә кисәк кенә журналист бу гаилә үтерелмәгән яки башка җирдә күмелгән, чөнки мәетләр юк дип, бу

эшне яңадан кузгата, үз тикшерүен башлый. Ленинның үлеме, Сергей Есенинның үз-үзенә кул салуы кебек күптән булган вакыйгаларның шаһитләре инде юк, детальләр онытылган, шунлыктан мондый эшләрне яңа күзлектән тикшерү күпкә авыррак. Рәсми оешмалар ярдәменә дә өметләнеп булмый, чөнки журналист алар дөрес дип тапканны кире кага.

3. Ачылмаган эшләр һәм яшерен җинаятьләр. Бу очракта журналист гаеплеләрне ачыклау, җинаятьне ачу гына түгел, аның барлыгын да дәлилләргә тиеш. Әгәр беренче ике очракта вакыйгалар факт буларак расланган булса, соңгы очракта җәмгыятьне җинаять кылынганлыгына ышандырырга кирәк, шуннан соң гына гаеплеләрне эзли башларга була. Әлбәттә, мондый тикшерүләр алып бару – җаваплы, катлаулы эш. Хәтта еш кына тикшерү башлауның сәбәбен яшерергә дә туры килә.

Нинди төркемгә караган очракны ачыкларга алынса да, журналист тикшерү предметының төгәл чикләрен һәрвакыт күз алдында тотарга тиеш. Җитди вакыйгаларда еш кына өстәмә мәгълүматлар пәйда була. Мәсәлән, дәүләт чараларын үзләштергән түрәнең башка җитди гаебе дә мәгълүм булган, ди. Мондый очракта журналист-тикшерүче беренче вакыйгага фикерен тупларга, ә язма героеның башка җитешсезлеген икенче материалда яктыртырга яисә тиешле органнарга ачыклык кертергә тиеш.

Журналистны аягы ашата дигән сүзләр, тикшерү материаллары турында сөйләгәндә, бигрәк дөреслеккә туры килә. Китапханә, архив, Интернет ни дәрәҗәдә булышса да, вакыйга урынына үзе барган журналистның материалына репортаж элементлары кертеп җибәрүе укучыны тагын да җәлеп итә. Коры фактлар, документаль дәлилләр аудиторияне бик тиз туйдыра. Катлаулы тикшерүләр үткәргәндә каршылыклар очрамый калмый. Үз юлында очраячак киртәләр белән алдан таныш булуы журналистның эшен һичшиксез җиңеләйтә.

### *2. Журналист тикшерүен алып бару методикасы*

Журналист тикшерүе өчен материал җыйганда, күп төрле методларга мөрәҗәгать итәргә туры килә. Мәсәлән, төп материалны җыйнаганда фаразлар туплана, аларны тикшерү өчен күп көч сарыф ителә. Моның өчен махсус методлар-алымнарны куллануның әһәмияте арта. Журналист тикшерүенең алымнарын ике төркемгә

бүләргә мөмкин. Болар – мәгълүмат җыю алымнары һәм табылган мәгълүматны анализлау алымнары.

Тикшерү вакытында, алып барыла торган ситуациядән чыгып, төрле алымнар кулланыла. Кайвакыт берничә алым бергә дә кулланырга мөмкин. Без аларның мөһимнәрен һәм еш кулланыла торганнарын карап үтәрбез.

***Күзәтү методы*** шәхси күзәтүләргә нигезләнгән. Күзәтү журналистикада төп һәм өстәмә алым буларак кулланыла ала. Көндәлек, гадәти күзәтүләрдән аермалы буларак, журналист күзәтүе билгеле бер максатка юнәлгән. Күзәтүче һәм күзәтелүченең бәйләнешенә карап, күзәтү туры яки турыдан-туры булмаска мөмкин. Кыска һәм озак була. Күзәтү ачык һәм яшерен була ала. Журналистның вакыйгада катнашуына карап, күзәтү журналист катнашкан һәм катнашмаган төргә бүленә.

Күзәтү методы мәгълүмат туплауның бер алымы булып тора. Бу таралган метод. Күзәтүнең нигезен сизү, кабул итү, күзаллау тәшкил итә. Күзәтү – мәгълүмат туплауның күз белән кабул итүгә корылган һәм билгеле бер максатка юнәлдерелгән төре ул. Шулай итеп гади кабул итүне аңлы рәвештә куелган максат активлаштыра һәм журналистны кирәкле мәгълүматка юнәлтә. Журналистның күзәтүе һәрвакыт шәхси характерда була. Журналист үзенең күзәткән вәзгыятеннән иң мөһим һәм кирәкле детальләрне сайлап ала. «Журналист нәрсә һәм ничек күзәтәсен ачык белергә тиеш. Аз ишетергә, ләкин тыңлый белергә, аз күрергә, ләкин күзәтә белергә кирәк. Шуңа күрә күзәтү процессына алдан әзерләнү мөһим», – дип киңәш итә психолог С.Л.Рубинштейн.

Күп күренекле журналистларның үзләре тикшерәчәк проблеманы якыннан белү өчен төрле һөнәр ияләре булып эшләп караулары билгеле. «Известия» газетасы журналисты В.Надеинның фельетон әзерләү өчен базарда сатканы, Алла Трубникованың монастырьга монашка булып урнашып, андагы хәлләрнең эчендә кайнап, И.Фәйзрахмановның бомж булып утырып, аларның тормышларын ачыклап, хәер сорашып, журналист тикшерүе язмалары әзерләве билгеле. Күзәтү танып-белү процессы, объектны ачыклау, аның белән бәйләнешкә әзерлек, танышу һәм өйрәнү кебек этаплардан тора. Танып-белү объектын ачыклау, сайлау күзәтү объектын аерып ала һәм күзәтү мәйданын чикли. Объектны шулай аерып алып күзәтү журналист эшенең мөһим

әзерлек өлеше. Ул журналистның тикшерү максатына, вакыйганың характерына, конкрет мәсьәләгә бәйле. Күзәтүнең предметын аерып алу журналист күзәтүнең максатына бәйләнгән. Кайбер очракта күзәтү предметын аерып алуга кабул итү процессының психофизик механизмнары тәэсир итә. Күзәтү турыдан туры һәм читтән торып булырга мөмкин. Турыдан-туры күзәтү вакытында журналист вакыйгалар, кешеләр белән элемтәгә керә, ә читтән торып күзәтүдә журналист читтән карап торып җыелган яисә башка чыганаклардагы мәгълүматны куллана. Вакыт ягыннан да күзәтүләр оператив һәм дәвамлы булырга мөмкин. Оператив күзәтү тиз хәзерләнә торган язмалар өчен кулланылса, теманы тирәнрәк яктырту өчен дәвамлы күзәтү кирәк. Күзәтү шулай ук ачыктан-ачык һәм яшерен булырга мөмкин. Туры күзәтү вакытында журналист-тикшерүче үз максатын тирә-яктагылардан яшерми, тирә-юньдәгеләр бу хакта беләләр. Мондый төр күзәтү вакытында журналист үзенең максатына ирешү, төгәл мәгълүмат алу өчен вакыйганың үзәгенә кереп эш итә. Коллективның һәрбер әгъзасы белән аралаша, таныша, кызыксындырган сорауларына конкрет җавап ала. Яшерен күзәтү вакытында журналист тирә-яктагыларга үзенең журналист-тикшерүче булуын да, нинди максат белән килүен дә белгертми. Бу гадәттә катлаулы, конфликтлы хәлләрне өйрәнгәндә кулланыла. Күзәтү шулай ук журналистның вакыйгаларга үз катнашы белән яки катнашмыйча да булырга мөмкин. Мәсәлән, беренче очракта журналист дини сектаның эшчәнлеген тикшерү өчен анда үзе йөри башлый, ә икенче очракта бу турыда читтән күзәтеп яза.

Журналист күзәтүендә вак-төяк нәрсәләргә дә игътибар бирелергә тиеш. Бу бик әһәмиятле. Мәгълүматны туплаганда, журналист беренче чиратта җыйнак, белемле, нык ихтыярлы кеше булырга тиеш. Тикшерүдә киткән, аз генә үзгәртелгән мәгълүмат та бик күп каршылыклар китереп чыгарырга мөмкин. Әгәр журналистның ялган мәгълүмат бирүе ачыкланса, бу кешеләр мәнфәгатенә зыян салса, монда журналистны «Массакүләм мәгълүмат чаралары» турындагы законны бозуда гаепләргә мөмкиннәр. Шул ук Законның 49нчы маддәсе нигезендә ул үзенең мәгълүмат чыганагын сер итеп тә сакларга тиеш. Киресенчә булганда, ул кешеләрдә үзенә булган ышанычны бетерергә мөмкин. Ә бу журналист эшчәнлегенә зур зыян сала.

Бер генә журналист тикшерүе дә ***интервью һәм әңгәмә алымнарыннан*** башка узмый. Кайбер тикшерүләр документлар тикшерүдән башланып, соңыннан кешеләр белән әңгәмәләр, сорашулар булып дәвам итәргә мөмкин. Ә кайбер очракта журналист иң элек кешеләр белән очрашып сөйләшеп, тикшерелә торган мәсьәлә буенча алар фикерен белеп, соңыннан документларга мөрәҗәгать итә ала.

Әгәр гади интервьюда кеше үзе теләп мәгълүматны тулы бирергә тырышса, журналист тикшерүендә сорауга җавап бирүченең, килеп чыгачак күңелсезлекләрне истә тотып, бик сак кына мәгълүмат бирүе, нәрсәнедер яшереп калдырырга тырышуы ихтимал. Журналист белән ачылып китмәскә һәркемнең үз сәбәбе булырга мөмкин. Журналист шуңа оста психолог булырга, кешеләр белән уртак тел таба белергә тиеш. Бигрәк тә конфликтлы ситуацияләр буенча сораштыру вакытында журналист гади язып баручы гына түгел, әңгәмәдәше белән сөйләшүне оста оештыручы булып, дөреслекне табарга бурычлы. Кешеләрне сораштыру техникасы журналист тикшерүе үткәрүчедә иң югары дәрәҗәдә булганда гына ниндидер уңышка ирешеп була. Ә бу техникага түбәндәге кагыйдәләр керә:

- гади, таныш, төгәл төшенчәләр белән эш итү;
- әңгәмәдәш белән итәгатьле булу;
- әңгәмәдәше хаклы булган очракта аның сүзләренең дөреслеген ачыктан-ачык тану;
- әңгәмәдәше кабул иткән аргументлар белән генә эш итү;
- башта әңгәмәдәш китергән дәлилләрне тыңлап, үзеңнекеләрне соңыннан китерү;
- әңгәмәдәшеңә хөрмәт белән карау;
- әңгәмәдәшеңнең фикер йөртүен игътибар белән тыңлау.

Тәҗрибәле журналистлар әңгәмәдән качучы, журналист белән контактка барырга теләмәүчеләрне сөйләштерүдә төрле чаралар кулланалар. Бу, мәсәлән, әңгәмә барышында пауза ясау. Әлеге очракта кеше пауза вакытында журналистның үзеннән җавап көткәнен аңлый, пауза озакка сузылган саен җавап бирми котыла алмаячагын белә. Шулай ук «үртәп кызыксындыру» методы да яхшы нәтиҗә бирергә мөмкин. Журналист әңгәмәдәшенә үзенә билгеле бер-ике фактны атый һәм әңгәмәдәшендә кызыксыну уята.

Әңгәмә вакытында журналист үзенең нинди сораулар

бирәчәген алдан уйлап куйган булырга тиеш. Аларның шулай ук полиция яки прокуратура тикшерүчесе кебек әңгәмәдәшенең йөзенә бәреп соралмавы да журналист тикшерүе өчен мөһим.

Шулай ук әңгәмә оештыру урынын сайлап алу да журналист тикшерүендә зур роль уйный. Эш урыннарында кешеләр журналистка ачылып китәргә ашыкмыйлар, аларны кибеттә, кунакта, өендә туры китереп сүз башлау кайбер очракларда күпкә отышлырак була.

Журналист үзен кызыксындырган күпчелек сорауларга җавапны мәгълүмат йөртүче белән аралашканнан соң гына ала. Моның өчен журналист әлеге сорауда компетентлы булырга тиеш. Әңгәмәгә әзерләнгәндә, журналист түбәндәгеләргә игътибар итәргә тиеш:

а) интервьюга әзерләнгәндә журналист үзенең «чыганагы» турында күбрәк белергә;

б) кызыклы сораулар төзеп куярга;

в) интервьюны шәхси әңгәмә формасында оештыру уңышлырак, чөнки телефон яки башка техник чаралар буенча оештырылган интервью көтелмәгән рәвештә тәмамланырга мөмкин;

г) интервью алдыннан «чыганак» белән очрашу турында килешеп куярга;

д) әңгәмәдәшнең фамилиясен, әтисенең исемен, һөнәрен, дәрәҗәсен, вазифасын истә калдырырга;

е) интервьюны «чыганак» белән психологик бәйләнеш урнаштырудан башларга;

ж) әңгәмәдәшкә үзе турында сөйләргә мөмкинлек бирергә, бу ике арадагы киеренкелекне бетерергә ярдәм итә;

з) «әйе» яки «юк» дип кенә җавап биреп була торган сорауларны бирмәскә. Әңгәмәне тулы җаваплар бирә алырлык итеп оештыру зарур. Моның өчен: «Сезнең фикерегезчә, ни өчен болай булган?» яки «Шул минутларда сезне нәрсә гаҗәпләндерде?..» формасындагы сораулар бирергә;

и) «Нәрсәне дә булса аңлатып китәсегез килмиме?» – дип сорау уңышлы түгел. Әгәр дә әңгәмәдәш җаваптан качса, сорауны үзгәртеп, берничә сораудан соң тагын биреп карарга:

к) җавап тулы булмаганда, әңгәмәдәшкә сорауга тулырак җавап ишетергә теләвегезне сиздерергә. Катлаулы сорауларны

интервьюның ахырында бирергә.

л) җавапларны биреп бетергәч, әңгәмәне салмак кына тәмамлау өчен сөйләшүне дәвам итәргә. Әңгәмәдәшкә рәхмәт әйтеп, кирәк булган очракта шалтыратырга рөхсәт сорарга.

Журналист тикшерүендә әһәмиятле метод булып ***эксперимент методы*** тора. Ул фәнни һәм тикшерү экспериментларына охшаш. Фәндә һәм юриспруденциядә бу метод еш кулланыла. Журналистикада бу алым һөнәр алыштыру алымы буларак та тикшерү эшләре барышында уңай бәяләнә. Ул тикшерүче-журналистка проблеманың эченә кереп язарга ярдәм итә. Һөнәр алыштыру шулай ук яхшы тәҗрибә тупларга да ярдәм итә.

Эксперимент ул журналистның вакыйгаларга үзе катнашып күзәтү методына охшаш. Аңардан аермалы буларак, бу очракта журналист эксперимент вакытында ситуацияне ясалма рәвештә тудыра. Бу журналистка озакка сузылган күзәтү вакытында алган мәгълүматларны тизрәк җыярга мөмкинлек бирә. Чит ил журналистикасында моңа мисал итеп журналист Гюнтер Вальраф эшчәнлеген китерергә була. 1967 елда Вальрафка эре сәнәгать предприятиеләрендә элеккеге нацистлар кул астында хәрби отрядлар төзелүе билгеле була. Бу отрядлар баш күтәрүче эшчеләргә каршы торырга тиеш булалар. Журналист күпме тырышса да, беркем дә аңарга серне ачмый. Ул үзен әлеге мәсьәләне күзәтүче министр кинәшчесе итеп таныта һәм үзенә кирәкле мәгълүматны алуга ирешә.

Җир йөзендә һөнәрләр күп төрле һәм аларның һәркайсы журналист тикшерүе аша нинди дә булса яңа ягын ачарга, тикшерелә торган проблеманы эченә кереп өйрәнергә мөмкинлек тудыра.

Гомумән, тикшерү барышында журналистка төрле алымнар кулланырга туры килә. Шуларның берсе – һөнәр алмашу. Еш кына «һөнәр алмашу» ысулы этик яктан төрле авырлыклар китереп чыгара һәм кешеләргә, оешмаларга әхлакый һәм матди зыян китерә. «Һөнәр алмашканда», журналист мәгълүматны «арттырып» яки алдап бирергә тиеш түгел. Шуның өстенә, сенсацион яңалык яки язмага аерым бер төсмер өстәү өчен кешенең яшерен серләрен ачып бирергә ярамый.

Журналист тикшерүен ***документлар белән эшләү методыннан*** башка күз алдына китереп булмый. Документ – матдиләштерелгән мәгълүмат. Документлар, мәгълүматны теркәү ысулына карап, басма, кино, магнитофон тасмалары, диск, флешкадагы язма һ.б. рәвешендә, авторга бәйле рәвештә шәхси һәм иҗтимагый, статусы буенча рәсми һәм рәсми булмаганнарга, табылу ысулына карап, әзер документлар һәм журналист заказы буенча әзерләнә торганнарына, эмпирик материалга якынлыгына бәйле рәвештә беренчел һәм икенчел төрләргә бүленә. Беренчел документлар – икенчедән, рәсмиләре – рәсми булмаганыннан ышанычлырак. Журналист-тикшерүчегә документлар белән эшләгәндә аерым таләпләрне үтәргә кирәк. Алар түбәндәгедән гыйбәрәт:

- күчереп алган очракта, аның төгәл чыганагын, исемен, нәшер ителү вакытын һәм урынын, шулай ук бит санын һәм мәгълүмат алынган битне күрсәтү;
- басылмаган документ булса, аның төгәл исемен, имза һәм мөхерләрен, имза куючыларның фамилия һәм вазыйфаларын, саклану урынын һәм саклану номерларын теркәп кую;
- документтан цитата китерелгәндә, аны һәрвакыт куштырнаклар эченә алу, документның исемен һәм чыганакларын, цитата алынган бит санын күрсәтү;
- бөтен цитаталар, саннар, фактлар, исем-фамилияләр кәгазьгә күчереп алынганнан соң, тагын бер кабат җентекләп тикшерелергә тиеш;
- документка бәя биргән вакытта, автор бу бәянең субъектив булуына ишарәләргә, минемчә, минем уемча кебек гыйбарәләр белән ассызыкларга бурычлы.

Документтагы мәгълүматны кат-кат тикшерү мөһим. Документ дигәч тә, әле ул һичшиксез дөрес дигән сүз түгел. Төрле документларны кисештереп тикшерү аеруча уңай нәтиҗә бирә. Документның төп нөсхә яисә төгәл күчермә булуын тикшерү дә кирәк. Архивларда сакланган күчермәләр белән чагыштырып карау бигрәк тә максатка ярашлы.

### *3. Журналист тикшерүенең төп этаплары (чыганаклар белән эш итү)*

Теләсә нинди журналист тикшерүе түбәндәге этаплардан тора.

Тикшерү этаплары – ул куелган сорауларга җавап алу һәм көтелгән нәтиҗәгә ирешү өчен үтәргә кирәк булган баскычлар.

- план төзү;
- беренчел мәгълүмат туплау (җыю) һәм эшкәртү;
- чыганаклар белән эшләү;
- җыелган мәгълүматны системага салу;
- дәлилләр базасын булдыру;
- генераль (төп) интервью;
- юридик экспертиза;
- текст язу.

Тикшерү планы – кирәкле дәлилләрне, шаһитләрне һәм куелган сорауларга җавап табу өчен эшләргә кирәкле адымнарның эзлеклелеге. Язмача план һәр тикшерү өчен мөһим. План бигрәк тә бер зур журналист тикшерүенең төрле юнәлешләрен берничә журналист башкарганда – төркем белән эшләгән чакта файдалы. Мәсәлән, журналист тикшерүләре агентлыкларында мондый план бүлек җитәкчесенең кабинетында эленгән махсус тактада сурәтләнә. Шуңа күрә һәркем журналист тикшерүенең һәр тармагы нинди стадиядә икәнлеген ачык күрсәтә.

**1.** Схема 1.

| **Без беләбез** | **Без белмибез** |
|---|---|
| Вакыйганың кайда булганын | Нинди максатка бәйле булганын |
| Вакыйганың кайчан булганын | Монда шаһитләр, вакыйганың геройларын ачыклау һ.б. бик күп фактлар кирә |
| Фактура | |

1. Беренче схеманы ачыкларга тиеш булабыз.
2. Вакыйганың шаһитләрен табу.

Журналист үзенә мөһим булган барлык фактларны, даталарны аерым бер дәфтәргә теркәп барырга тиеш, бу тикшерү эшенә ачыклык кертәчәк.

Журналистка тикшерүенең һәр этабыннан соң хисап язу, ягъни башкарган эшләренең хисабын язарга киңәш ителә.

Язманы редакцияләү күп нәрсәгә ачыклык кертә. Язылачак материал турында фикер:

3. Материал турында фикер алышу (мисал өчен редактор белән);

4. Тонны билгеләү (нинди рәвештә материал языла);

5. Язманың күләмен билгеләү;

6. Журналистның график материаллар белән һәм фотохәбәрче буларак эшчәнлеге;

7. Үзара элемтә;

8. Кирәкмәгән киңәшләрдән саклану, редактордан тыш киңәшләшмәскә;

9. Вакытны дөрес бүлү.

Димәк, сез тикшерү планын төзедегез ди. Хәзер инде беренчел мәгълүматны җыю һәм эшкәртүгә күчәргә мөмкин.

***Беренчел мәгълүматны туплау (җыю) һәм эшкәртү*** вакытында, ике төр чыганак белән очраша:

- ябык чыганак;
- ачык чыганак.

Беренче өлеш ачык чыганаклардан объект яки вакыйга турында мәгълүмат туплау. Икенче өлеш – төрле мәгълүмат чыганакларында теркәлгән объектив мәгълүматны эзләү.

***Чыганаклар белән эшләү*** тикшерү планының аерым бер баскычы булып тора. Тикшерүгә кемдер килеп тема тәкъдим итү яки ярдәм сорап хат язумы – мәгълүмат туплауның беренче этаплары булып тора. Мәгълүмат хәбәр итүче белән әңгәмәне сак оештырырга кирәк.

***Ачык чыганаклар*** рәтенә төрле массакүләм мәгълүмат чаралары керә: телевидение, радио, газета. Шулай ук ачык чыганакның иң киң таралган төре буларак Интернет челтәре тора. Интернет-сайтлар, форумнар һәм интернет-блоглар үз эченә никадәр мәгълүмат туплаганны күз алдына китерүе дә авыр. Һәм әлеге форумнардагы фикер алышулар, журналистның үзенең аралашуы, хезмәттәшләре белән тәҗрибә туплавы – тикшерү темасының килеп чыгуы өчен менә дигән чыганак булып тора. Гомумән, ачык чыганаклар буенча мәгълүмат туплау зур китапханәдә эшләүгә тиң. Үзеңне кызыксындырган сорау буенча ГМЧдагы барлык материалларны карап чыгыгыз, интернеттан файдаланыгыз, кирәк булса, архивка мөрәҗәгать итегез. Нәтиҗәдә, сез кыйммәтле мәгълүмати досьега ия булырсыз. Әлеге материалларны анализлау, һичшиксез, теманы гомуми күзаллау гына түгел, ә алдагы эзләнү өчен дә азык булыр.

Массакүләм мәгълүмат чараларыннан тыш, журналист ачык

рәвештә мәгълүматны төрле мәгълүмат хезмәтләреннән, пресс-релизлардан, хокук яклау органнарының, бигрәк тә Эчке эшләр министрлыгы, янгын саклау идарәсе, гадәттән тыш хәлләр һәм гражданлык оборонасы эшләре, прокуратура, ГИБДД, РУБОП, ФСБ, шәһәр һәм район хакимиятләре, коммерция структураларының мәгълүмат хезмәтләреннән ала ала. Ләкин алда әйтеп үтелгән органнарның мәгълүматлары дөрес була дигән сүз түгел, чөнки аларның мәгълүмат хезмәтләре журналист файдасына түгел, ә нәкъ менә үз Хезмәтләре файдасына хезмәт итә, шуңа күрә мәгълүмат берьяклы булмасын өчен, тикшерү алып бара торган журналист аны кат-кат тикшереп, дөреслегенә инанырга тиеш, шуннан соң гына ул аны үз эшендә куллана ала. Иң әйбәте журналист мәгълүматны коры хәбәр яки резонанс тудыручы вакыйгадан, пресс-релизлар аша түгел, ә нәкъ менә шәхси контактка, аралашуга корылган процесстан алырга тиеш.

Закон буенча һәр журналист мәгълүмат туплау хокукына ия. Мәгълүмат артыннан ул хокук саклау органнарыннан тыш, махсус хезмәтләргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин (медицина хезмәткәрләре, МЧС, коткару хезмәте, коммуналь хезмәткәрләр, янгын сүндерүчеләр һ.б.) Ләкин чынлыкта еш кына алар теге яисә бу мәгълүмат дәүләт сере, медицина сере дигән һ.б. сәбәпләр табып, информация бирүдән баш тарталар.

Журналист өчен ачык булган мәгълүмат чыганагының берсе булып суд утырышлары тора. Суд утырышларның күбесе, шул исәптән, җинаять эшләрен тикшерү дә ачык рәвештә үтә. Искәрмә булып дәүләт серләре карала торган утырышлар яки сексуаль көчләү белән бәйле булган ябык яки ярымябык утырышлар гына тора. Ләкин бу очракта суд карары җәмгыять өчен ачык рәвештә яңгырый. Суд утырышларында халыкның, шул исәптән, журналистларның катнашуы һәм суд утырышын күзәтүләре РФ Конституциясе һәм процессуаль кодекслар белән идарә ителә. Ләкин журналистка фото һәм видеокамерлар кулану рөхсәте бары тик судья һәм хөкем ителүче каршы килмәсә генә бирелә.

Журналист тикшерүе агентлыкларында махсус архив - аналитика бүлекләре бар. Аның хезмәткәрләре бүгенге күпчелек ачык чыганак буенча мәгълүмат эзләү технологияләрен яхшы белә. Шуңа күрә мондый агентлыкларда беренче этап журналистка кагылмый да. Кагыйдә буларак, яңа тикшерү темасын билгеләгәч

тә, запросны архив-аналитика бүлегенә юллыйлар һәм, берникадәр вакыттан соң, ачык мәгълүмат чыганакларында барлык мәгълүмат нигезендә төзелгән, системалаштырылган досье алалар.

Беренчел мәгълүматны туплау һәм эшкәртү этабының икенче өлешенә, ягъни төрле мәгълүмат чыганакларында теркәлгән мәгълүматны эзләүгә күчәбез.  Әлеге мәгълүмат соңгы эшкә дөреслек кенә биреп калмыйча, нигезле нәтиҗәләр ясарга ярдәм итә.

Журналист тикшерүендә журналист ***ябык мәгълүмат чыганаклары*** белән дә кулланырга тиеш. Бу аның үзенчәлеге булып та тора. Халыкка мәгълүм булмаган, ябык информацияне җиткерү – иң мөһим аспектларның берсе. Ябык (конфиденциаль) мәгълүмат чыганагы булып төрле дәрәҗәдә яшерелгән һәм шифрланган документлар, электрон һәм телефон элемтәләре аша килгән беркем белми торган мәгълүмат (димәк, бу очракта «прослушкалар», социаль челтәрдәге шәхси сайтларга, битләргә үтеп керүне әйтергә мөмкин), махсус яшерелгән элемтә һәм мәгълүмат базалары тора.

Шунысын әйтеп үтәргә кирәк: билгеле бер объектив нәтиҗәләр алыр өчен журналистка әллә ни эшләргә дә кирәк түгел. Мәсәлән, сез, дәүләт хезмәтен коммерция эшчәнлеге белән бергә алып бара торган түрә турында материал әзерлисез, ди. Терки торган оешмага гади генә сорау (запрос) җибәрү бу мәгълүматны раслый яки кире кага ала.

Журналист запросы – кайвакыт мәгълүмат алуның иң кулай юлы. Кызганыч, кайбер журналистлар әлеге мөмкинлектән файдаланмый.

Журналист тикшерүендә ябык мәгълүмат чыганакларын куллану, материалдан сенсация ясап калудан тыш, журналистның киләчәк карьерасында да нокта куярга мөмкин һәм шул очрактан журналистны җаваплылыкка тарту очрагы да барлыкка килә. Компетентлы органнар ябык мәгълүмат ничек итеп журналист кулына эләгүен ачыклый башлау – журналист өчен бик үк уңай нәтиҗә түгел.

Журналист-тикшерүче түбәндәге һөнәри осталыкка ия булырга тиеш:

- документацияне анализлый белү;
- чыганаклар белән эш итә белү (архивлар, налог хезмәтләренең документларын, телефон счетларын  өйрәнү);

- хокук яклау органнары белән эшли белү;
- «журналист һөнәрен алыштыра» девизы астында эшләү.

Гомумән, сезне кызыксындырган тема буенча ачык һәм махсус чыганаклардан беренчел чыганак нигезендә мәгълүмат җыелып һәм системага салынып бетте. Редакциядән китеп, журналист тикшерүенең икенче этабына – ***чыганаклар белән эшкә*** күчәргә мөмкин.

Иң башта ук шунысын әйтеп китәргә кирәк, журналист тикшерүе кысаларындагы чыганаклар белән эш тулысынча бер шартка бәйле: сезнең яки хезмәттәшләрегез карамагында конкрет бу очракта кирәкле чыганаклар бармы? Әгәр бар икән – сезгә бары тик алар белән очрашып сөйләшергә туры киләчәк, юк икән – табарга, танышырга һәм сезне кызыксындырган мәгълүматны бүлешергә күндерергә, ышандырырга кирәк.

Кеше белән эшләү психология белән нык бәйле һәм ул тәҗрибә белән килә. Ләкин ике сүз белән булса да мәгълүмат чыганаклары белән эшләүнең махсус хезмәтләрдә кулланыла торган кайбер этапларын язып китү кирәк.

– кандидатны билгеләү;
– хезмәттәшлеккә җәлеп итү;
– тикшерү;
– аның белән эшчәнлекне кирәкле юнәлештә алып бару;
– хезмәттәшлек өчен кирәкле вакытны билгеләү;
– вакытында контактны (араны) өзү.

Әлбәттә, журналистларның һәр мәгълүмат чыганагы белән җитди эш оештыру өчен махсус хезмәтләрдәге сыман мөмкинлеге юк, ләкин бу эш алымнарын белеп тору комачауламас.

Мөһим кагыйдәне истә тотыгыз: чыганаклардан алынган һәр мәгълүматны компьютерда теркәп барырга һәм архивка җибәрергә, ягъни ***тупланган мәгълүматны системага сала*** белергә кирәк**.**

Мәкаләгезне хәзер үк язмасагыз да, алынган мәгълүматтан соңрак та куллана аласыз. Моннан тыш, мәгълүматны вакытында теркәп бару табылган фактларны логик эзлеклелеккә салырга ярдәм итә. Бер тема буенча эшләгәндә, төрле чыганаклардан алынган мәгълүмат бер файлга (электрон рәвештә) һәм папкага (кәгазь вариантта) җыела. Бу эшегезне җиңеләйтеп, җитәкчелек алдында нәтиҗәле хисап тотарга ярдәм итә. Мисал өчен, андый папка түбәндәге бүлекләрдән тора:

– беренчел мәгълүматлар;
– документлар;
– язмалар күчермәсе (яки ачык чыганаклар буенча досье).

Болар барысы да сезнең эшегезнең бер өлеше, беренчел белешмә булып тора. Белешмә – һич тә журналист материалы түгел. Ул бергә җыелган, системага салынган кыскача мәгълүмат. Үзегезгә аның кайсы өлеше тикшерелгән, ә кайсысы расланмаган икәнен билгеләгез. Сез анда җитешмәгән мәгълүмат бар икәнен дә күрерсез. Белешмә нигезендә тикшерү ахырында журналист ирешкән нәтиҗәләре турында сөйли. Ни генә булмасын, белешмә сезнең архивта калачак. Әгәр дә кайчан булса да кабат әлеге темага кире әйләнеп кайтырга туры килсә, яңадан шул ук мәгълүматны җыярга кирәк булмаячак.

Мәгълүмат чыганаклары белән әңгәмәләр турында хисаплар папканың беренче өлешендә, «шәхси мәгълүмат» бүлегендә хронологик тәртиптә урнаштырыла. Әзер булганнан соң, хисаплар мәгълүмат чыганакларының электрон архивына күчерелә.

Барлык мәгълүмат тупланып беткәннән соң, тизрәк мәкалә бастырасы килә. Күбесе журналист һөнәренең мөһим принцибын – конфликтның ике ягын да тыңларга дигән кагыйдәне санга сукмыйча, шулай эшли дә. Материалыгызда гаеп ташланган якка сүз әйтергә, җавап тотарга мөмкинлек бирергә тиешсез. Әлеге этап ***генераль интервью*** дип атала.

Аннан башка чын журналист тикшерүен тәмамланган дип санап булмый. Генераль интервью әхлак номаларын үтәү өчен генә кирәк түгел, аның белән материалыгызның төзелеше үзгәрер. Аны башка төрле оештырырга туры килер, чөнки сез уйлап та карамаган көтелмәгән фактлар килеп чыгуы, ачыклануы ихтимал. Тикшерү фигурантына материал белән танышып чыгарга тәкъдим итәргә кирәкми, хәтта бу эш артык. Их яхшысы – аның үзенә кагылган өлешен генә күрсәтергә. Әгәр ул сезнең белән сөйләшергә теләми икән, мәкалә ахырында фактларны шәрехләүдән һәм әңгәмә корудан баш тартты, дип язарга мөмкин. Бу сүзләр бары тик укучының ышанычын гына арттырачак.

Кайбер чит ил галимнәре тикшерү фигуранты белән эшнең беренче этабында гына очрашырга тәкъдим итә. Алар фикеренчә, нинди генә саклык чаралары күрсәгез дә, тикшерү объекты барыбер эшегез турында беләчәк. Бу исә эшне тагын да кыенлаштыра, чөнки

ул төрле алдау юлына басарга, фактларны кире кагарга мөмкин. Үзегезне кызыксындырган персонаж янына ул үзенә карата сезнең тарафтан булган кызыксыну турында белгәнче, көтелмәгәндә барсагыз, аның ихлас булуына өмет итә аласыз. Әлеге аргументация мантыйксыз түгел, ләкин ул журналистларга һәм ГМЧга карата цивилизацияле караш булган илләргә күбрәк туры килә. Еш кына тикшерү героеның, мәкалә әзерләнеп ятуы турында ишеткәч, аның басылып чыгуына төрлечә каршы булуы турында ишетергә туры килә.

Киләсе мәҗбүри алым – ***юридик экспертиза***. Квалификацияле юрист тикшерүеннән башка конфликтлы материал басмага тапшырыла алмый. Әгәр дә редакциядә юридик хезмәт юк икән, үзегез ышанган юристка тикшертергә тырышыгыз. Юрист мәкаләгезне раслады ди. Хәзер бары тик газетаның сезнең тикшерү нәтиҗәләрен бастырып чыгаруын гына көтәргә кала.

Журналист тикшерүе, әлбәттә, данәле товар. Ләкин аның элементлары, аерым этаплары көндәлек, гадәти материаллар әзерләгәндә дә кулланыла.

***Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр***

1. Тикшерүгә әзерлек ничек башлана?
2. Журналист тикшерү предметын нинди төркемнәргә бүлеп карарга була?
3. Журналист тикшерүен алып бару методикасы – нәрсә ул?
4. Журналист тикшерүендә нинди алымнар кулланыла?
5. Күзәтүнең нинди төрләре бар?
6. Интервью һәм әңгәмә алымнары турынданиләр беләсез?
7. Әңгәмә кору кагыйдәләреннән журналист-тикшерүче өчен мөһим булган пунктлар нинди?
8. Тикшерүдә “һөнәр алмашу” алымының өстенлеге нәрсәдә?
9. Документлар белән эшләүнең текстта әһәмияте нинди?
10. Журналист тикшерүе методларын файдаланып берәр тикшерү эшен башлап җибәрергә әзерләнгәндә, иң беренче нәрсәләрне истә тотарга кирәк?
11. Тикшерү материалын язарга әзерләнегез. Тема сайлау, проблеманы ачыклау, материалны туплау һәм тикшерү башлап җибәрү.

## *ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК. ЖУРНАЛИСТ ТИКШЕРҮЕНЕҢ ХОКУКЫЙ ҺӘМ ЭТИК НИГЕЗЛӘРЕ*

Журналист тикшерүе жанрында эшләүче журналист үз эшчәнлегенең хокукый һәм әхлакый чикләрен яхшы аңлаган очракта гына үз максатларына ирешә ала. Бу урында без максат дигәндә аның шәп материал язып бастыруын һәм башкаларга да, үзенә дә зыян салмавын гына күз алдында тотмыйбыз. Иң элек шуңа игътибар бирергә – журналист тикшерүенең төп максаты нәрсәдә соң? Хаклык эзләүдә, әлбәттә. Максатка омтылганда, кайчакта журналистка төрле чаралар да бара кебек тоелырга да мөмкин. Әмма дөреслекне ачу өчен тырышып йөргән кеше берничек тә закон һәм әхлак таләпләренә игътибарсыз калырга тиеш түгел.

### *1. Журналист тикшерүен тормышка ашырганда кулланыла торган хокукый чыганаклар*

Һөнәри эшчәнлек алып барышында журналист, теләсә кайсы законга буйсынучан граждан кебек үк, үз иленең законнарын, юридик нормаларын үтәргә тиеш. Хокукый чыганакларга тукталыйк.

Социаль институт буларак, журналистиканың эш принциплары РФ Конституциясенә, «Гаммәви мәгълүмат чаралары турындагы», «Полиция турындагы», «Федераль дәүләт куркынычсызлыгы», «Дәүләт сере» турындагы законнарга нигезләнә. Болардан тыш, Җинаять кодексы, Гражданлык кодексы һәм башка шундый норматив хокукый документлар да бар әле. Редакция уставы турында да онытырга ярамый. Кызганыч, журналист эшчәнлеген билгеләүче законнарның күбесе әле язылa гына, ә кайсыберләре исә сәяси принциптан юкка да чыгарыла. Ләкин бу гына журналистларның хокукый яктан белемсезлеген аклый алмый.

Әлеге норматив документларда дәүләт тарафыннан аларның хокуклары һәм бурычлары бәян ителә. Иң беренче чиратта Россия Федерациясе Конституциясе таләпләрен карап китик. Төп законның 29нчы маддәсе цензураны тыя, сүз һәм фикер иреген, 13нче маддәсе фикер төрлелеген гарантияли. Шулай ук шәхес дәрәҗәсен төшерергә ярамау (21нче маддә), шәхси тормышның, шәхси һәм

гаилә серләренең кагылгысызлыгы, кешенең намусын һәм матур исемен яклау (23нче маддә), кешенең шәхси мәгълүматларын үз рөхсәтеннән башка җыю, саклау һәм тарату тыелуы (24нче маддә), берәүләрнең икенчеләрдән өстенлеге, нәфрәт, дошманлык пропагандасының тыюлуы турында да махсус таләпләр куелган. Безнең өчен Конституциянең 26нчы маддәсе дә бик мөһим: ул журналистка ирекле рәвештә мәгълүмат җыю һәм тарату хокукын бирә.

Шул ук таләпне без «Гаммәви мәгълүмат чаралары турындагы» законның 47нче маддәсендә дә очратабыз: журналистка мәгълүматны эзләү, сорату, алу, тарату, төрле документлар һәм материаллар белән танышу, алардан күчермәләр ясау (авторлык хокуклары турында онытмыйча), техник чаралар ярдәмендә тавыш, сурәт яздыру хокукы бирелгән. Дөрес, ул таныша торган документлар һәм материаллар дәүләт сере яки башка төрле закон тарафыннан саклана торган сер булмаска тиеш.

Журналист тикшерүе үткәргәндә, еш кына төрле оешмалар үзләренең документларын коммерция сере дип атап, журналистка бер мәгълүмат та бирми. Бу очракта журналист закон буенча оешмада буш эш урыннары булу турындагы, экология һәм монополиягә каршы көрәш турындагы законнарны бозучы, бухгалтер хисапларындагы мәгълүматларның, шулай ук оешмага коммерция эшчәнлеге белән шөгыльләнү рөхсәтен биргән документларның «сер» категориясенә кермәвен белергә тиеш.

Дәүләтнеке булмаган серләрнең кагылгысызлыгын тәэмин итү бурычы аларның ияләренә яки эш урыны буенча сакларга тиешле кешеләргә салына. Әгәр журналистка вазыйфаларын үтәү барышында шундый серләрне саклау бурычы бирелгән яки андый серләр билгеле булган икән, ул аларны таратса, РФның Җинаять кодексы белән җавап бирәчәк.

Сүз уңаеннан, чит илләрдә бу хәлнең ничек торганлыгына да күзәтү ясап китик әле. Бездәге кебек «ГМЧ турындагы» закон барлык илләрдә дә юк. Австрия, Швециядә бар, ә менә Германиядә андый нормалар аларда административ бүленешне тәшкил иткән Җирләрдә кабул ителә, Франциядә ГМЧ турында төрле кодексларда искә алына, Австралия, Канада, Голландия, Норвегия, Испания, Бөекбритания, АКШта да аерым законнар юк диярлек.

## *2. Журналистларның хокуклары һәм бурычлары*

Журналист-тикшерүче алдында законның күптөрле таләпләрен үтәү һәм шул ук вакытта һөнәри вазыйфасын башкару арасындагы балансны тоту бурычы тора. Журналистка Россиядә гамәлдә булган норматив документлар җирлегендә ике шартны үтәргә кирәк. Беренчедән, җәмәгатьчелектән качырылган кырын эшләрне ачыклау, халык хөкеменә чыгару. Икенчедән, закон белән каршылык булдырмау. Кайчакта дөреслекне ачар өчен кирәк булган мәгълүматларны табу журналисттан законны бозуны да таләп итәргә мөмкин. Әмма ул, Законны бозган очракта, шул закон алдында җавап бирергә, суд җаваплылыгына тартылырга мөмкин икәнлеген онытырга тиеш түгел. Журналист тарафыннан закон бозылган очракта, моның белән тиз арада каршы яклар файдаланып, аны суд хөкеме каршына чыгарырга мөмкин.

Закон журналист тикшерүен мәгълүмат белән эшләүнең төрле этапларында төрле аспектларда чикли. Түбәндә һәрберсен аерым карап китәбез:

Мәгълүмат туплау этабында хокукый чикләүләр аеруча актив кулланыла. Ул «ГМЧ турындагы» законның 49 маддәсендә урын алган. Әлеге маддә буенча журналистның бурычлары түбәндәгедән гыйбарәт:

- хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре белән беркетелгән редакция уставын үтәү;
- журналистның эзләп тапкан мәгълүматын тикшерү хокукы бар дип ассызыкласак, шул ук вакытта бу аның хокукы гына булып калмыйча, «ГМЧ турындагы» Законның 49 нчы маддәсенең 1 нче өлеше буенча аның бурычына да әверелә;
- мәгълүмат чыганакларының үз исемнәрен күрсәтү таләбен үтәү;
- аерым таләп булса, алынган мәгълүматны һәм аның чыганагын яшереп саклап калу;
- журналист, җәмәгать мәнфәгатьләрен саклау таләп ителгән очраклардан кала, аерым кешеләрнең шәхси тормышы турында мәгълүмат таратырга теләсә, иң элек шул кешенең үзеннән рөхсәт алу;
- кешедән мәгълүмат алганда, аның кем булуына карамастан, видео- , аудио-, фототехника әсбаплары кулланылу турында хәбәр итү;

- аерым бер материалны бастырганнан соң, аның суд белән бәйле бәхәсләр китереп чыгару мөмкинлеген редакторга алдан ук хәбәр итеп кую да журналистның бурычы;

- редактор закон белән тыелган эш кушкан очракта, аннан баш тарту шарты;

- һөнәри эшчәнлеген башкарганда, кемнең дә булса соравы яисә таләбе нигезендә, шәхес һәм вазыйфа таныклыгын күрсәтү бурычы.

Журналист-тикшерүчегә мәгълүмат җыю этабында төп кагыйдәне – сер саклау мәсьәләсен дә күздә тотарга кирәк. Законда шул мәгълүматны табу юлларын исәпкә алып караганда, мәгълүматның берничә төрен аерып чыгаралар: гражданлык әйләнешендәге, һәркемгә дә ачык булырга тиешле һәм ябык мәгълүмат төрләре.

Мәгълүмат туплау этабында алынган мәгълүматны газетага тапшырганчы, ягъни ул матбугат чарасында дөнья күргәнче, аның «ГМЧ турындагы» законның 50нче һәм 51нче маддәләренә туры килүен тикшерергә кирәк. Аның беренчесе яшерен язмалар әзерләүгә кагыла, ә икенчесе журналистка үз хокукларыннан дөрес файдалану мәсьәләсен ача. Законда каралган тыюлар үтәлмәгән очракта, журналист-тикшерүчегә материалы дөнья күргәннән соң зур күңелсезлекләр яный.

Нигәдер барлык журналистлар бу закон нигезләрен тиешенчә файдаланмый. Ә анда исә журналистка тикшерүен җиңеләйтә алырдай пунктлар урын алган. Бүгенге көндә аеруча актуаль булганы – 39нчы маддә. Мәгълүмат сорап мәрәҗәгать итү турында ул.

Редакция дәүләт органнары һәм оешмалары, иҗтимагый оешмалар, аларда эшләүче кешеләр эшчәнлеге турында мәгълүмат сорап мөрәҗәгать итә ала. Мәгълүмат сорап мәрәҗәгать итү телдән һәм язма рәвештә була ала. Соралган мәгълүматны күрсәтелгән органнар, оешма һәм берләшмәләрнең җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, матбугат хезмәте хезмәткәрләре яки шуңа хокукы булган башка кешеләр бирә ала.

Яшерен камера куллану исә, күп кенә Европа илләрендә закон белән җайга салынган гамәл. Аны пассив рәвештә яздыру һәм актив рәвештә яздыруга бүлеп карарга була. Беренче очракта, алдан ук урнаштырылган камера хозурына чит кешеләр дә эләгергә мөмкин, ягъни моны законны бозу итеп исәпләргә була.

Икенчесендә аппаратура белән кеше үзе идарә итә ала (камера дипломатта яки киемдә яшерелгән булырга мөмкин). Бу очракта исә камера тикшерү өчен кирәкле булган объектны гына колачлый һәм кайбер килеп туарга мөмкин кыенлыклардан азат итә.

Яшертен камера һәм телефон яздырулары белән эш иткәндә, киләчәктә туарга мөмкин проблемаларны күздә тотып эш итәргә кирәк. Мәсәлән, язмада монтаж булмавын дәлилләү яки төп геройлар белән төрле аңлашылмаучанлыклар килеп чыгу ихтималы.

Тикшерү барышында журналистка төрле чыганаклардан видеотасмалар килеп ирешергә мөмкин. Аның дөреслеккә туры килүен башка чыганаклар аша инанырга кирәк. Бу журналист-тикшерүченең бурычы, чөнки бу мәгълүматны журналистны юлыннан яздырырга теләгән кешеләр дә эшләргә мөмкинГади кешеләр һәр вазыйфа башкаручылардан (должностные лица) мәгълүмат алганда, журналист-тикшерүче аудио-, видеоязма алып барылуы, фотога төшерелүе турында кисәтергә тиеш. Әмма кайчакта бу гамәлләр яшерен рәвештә дә башкарыла. Закон кысаларында булсын өчен, аның берничә шарты бар.

Яшерен камера куллану да күңелсезлекләр китереп чыгарырга мөмкин. «ГМЧ турындагы» Законның 50 маддәсе буенча, журналист 3 очракта гына яшерен аудио-, видеоязма, кино һәм фото аппаратура куллана ала.

1) әгәр гражданнарның конституцион хокукларын һәм иреген бозмаса;

2) әгәр иҗтимагый ихтыяҗларны яклау өчен кирәк булса, һәм вакыйгага катнашы булмаган кешеләрне танып алуга каршы чаралар күрелгән булса;

3) әгәр язмаларны күрсәтү суд карары нигезендә алып барылса.

### *3. Кеше хокуклары бозылган очраклар*

Журналист-тикшерүче тарафыннан аерым бер шәхеснең намусын пычратучы язма дөнья күргән очракта, зыян күргән як РФның Гражданнар кодексындагы 152нче маддәсенә нигезләнеп судка бирә ала. Бу маддәдә намус, дәрәҗә, һәм эш репутациясен яклау турында сүз бара. Суд чынлап та зыян салынган дип тапса, гражданның намусына, дәрәҗәсенә яки эш репутациясенә зыян салган мәгълүматлар нинди ГМЧда таратылган булса, алар шул ук ГМЧда кире кагылырга тиеш. Суд карары үтәлмәсә, суд закон

бозучыга процессуаль законнарда күрсәтелгән күләмдә һәм тәртиптә штраф сала ала. Штраф түләү закон бозучыны суд карары белән билгеләнгән эшне үтәүдән – ялган мәгълүматларны кире кагудан азат итми.

Намусына, дәрәҗәсенә яки эш репутациясенә зыян салган мәгълүмат таратылган граждан, кире кагу белән берраттән, аларны таратудан килгән чыгымнарны һәм әхлакый зыянны түләүне таләп итәргә хаклы.

Әгәр гражданның намусына, дәрәҗәсенә яки эш репутациясенә зыян салган мәгълүматны тараткан затның кем икәнлеген ачыклау мөмкин булмаса, аның турында мондый мәгълүматлар таратылган зат, таратылган мәгълүматларның чынбарлыкка туры килмәвен тануны сорап, судка мөрәҗәгать итәргә хаклы. Судка юридик зат һәм зыян күргән һәр РФ гражданины мөрәҗәгать итә ала.

Җавап тотучылар исемлегенә без редакцияне дә (әгәр ул юридик зат булса), гамәлгә куючыны да (редакция юридик зат булмаган очракта); материал авторын да кертәбез. Чөнки журналист, шәхеснең ирегенә, намусына һәм дәрәҗәсенә карата эшләнгән җинаятьләрдә гаепләнгәндә, РФның Җинаять кодексы кысаларында җавап тота.

Сүз уңаеннан, җавап бирү һәм кире кагу хокукы күп илләрнең хокукый нормаларында искә алынмый. Мәсәлән, Австралия, Канада, Англия законнарында ул каралмаган, ә АКШның Югары суды җавап бирү хокукын бирүче законнары Конституциягә каршы килә дигән карар чыгарды.

«ГМЧ турындагы» законның 46нчы маддәсе бәхәсле якларның вакытын бушка уздырмау, суд чыгымнарын экономияләү максатыннан, хокукы бозылган дип саналган кешеләргә турыдан-туры редакциягә мөрәҗәгать итү мөмкинлеген бирә. Әгәр дә редакция бу затның хокуклары бозылган дип тапса, аның кире кагу язмасын бастырып чыгара.

Франция, Германия, Швециядә мондый очраклар гражданлык һәм җинаять эше буларак карала, ягъни гайбәт тараткан журналист гадәти кеше кебек җавапка тартыла. Шунысы кызык, Германия, Англия, Франция, Австриядә судка бирүче кеше аның турында таратылган мәгълүматның дөреслеккә туры килмәвен үзе расларга тиеш, ә Норвегиядә, киресенчә, мәгълүмат таратучы журналист үз мәгълүматының дөреслеген раслый. Швециядә журналистлары

хокук бозган өчен мөхәррир җавапка тартыла, ә Англиядә хәтта газетаны таратучыларга да суд җаваплылыгы салынырга мөмкин.

Журналист тикшерүләре закон белән тыелмаган, аерым кысалар белән чикләнмәгән. Андый эшчәнлек барышында массакүләм мәгълүмат чаралары белән хокук саклау органнары арасында нәтиҗәле хезмәттәшлек оештырырга мөмкин. Әмма, белгечләр әйтүенчә, соңгы елларда журналистлар белән суд органнары арасында кискен мөнәсәбәтләр урнаша бара. Мәгълүмат җитешмәүдән кайчакта дөрес булмаган фактларга таянган криминаль репортажлар, журналист тикшерүләре дә очрый. Дөрес мәгълүматка булган ихтыяҗны канәгатьләндерү максатыннан, кайчакта редакцияләр суд органнарында үзләрен яшерен рәвештә мәгълүмат белән тәэмин итеп торырлык кешеләр дә булдыргалый. Әмма бу рәвешчә сатып алынган мәгълүмат еш кына берьяклы, субъектив булып чыга.

Әле эшли генә башлаган яшь журналистлар ирек һәм бәйсезлек төшенчәләрен аеруча үз итә. Нәкъ менә яңа гына журналистлык хезмәтенә тотынган кешеләр язмаларының геройларына кирәгеннән артык бәйләнәләр, тәнкыйть материалларын язуны артык күрәләр. Чөнки шул юл белән популярлык казану җиңелрәк. Чынында шулай килеп чыга да кебек: тәнкыйть сүзләре белән чыгыш ясарга яраткан журналистлар бер-ике ай эчендә бик танылып китәргә мөмкин. Әмма таякның икенче башы да бар бит әле: шул ике ай эчендә ул шул бер аралашкан кешеләре, геройлары белән башка аралашмас хәлгә килә, аның өчен күп кенә оешма ишекләре ябыла. Мисал өчен, суд залларыннан репортажлар әзерләргә тиешле журналистны шул залларга кертми башласалар, аңа нишләргә кала? Әлбәттә, бу суд органнарында эшләүчеләргә, мәгълүмат бирүчеләргә, язмаларың геройларына ялагайланырга кирәк, дигәнне аңлатмый. Киресенчә, журналист һәрвакытта да объектив булып калырга, фикер йөртә белергә тиеш, әмма материал тыныч, нейтраль тонда әзерләнсә, моннан журналист та, укучылар да отачак кына.

Яшь журналистларга тагын шунысын да истә тоту зарур: суд-тикшерү эшләре белән бәйле хезмәткәрләр, хокук саклау органнарында эшләүчеләр законга нигезләнеп кенә эш йөртә, фикерли, журналистларның материалларын кабул итә. Шуңа да алар хокук саклау өлкәсендә белемсез журналистларның ул темага язарга омтылуын бик начар бәяли. Еш кына шул темаларга

язучылар хокук органнары хезмәткәрләреннән алган интервьюны хокук өлкәсендә белем туплауга әйләндереп калдыра. Мисал өчен, Үзәк сайлау комиссиясе җитәкчеләреннән еш кына сайлау турындагы законнарда сүзнең нәрсә турында баруы, Конституцион суд рәисеннән «ике-өч сүз белән Конституциянең нәрсә икәнлеген аңлатып бирүен», ә Югары суд рәисеннән анда ничә судья эшләве һәм аларның бирегә эшкә каян килүләре белән кызыксынган сораулар бирелә икән. Югыйсә, болар турында законнарны укып карап яки башка әңгәмәдәшләр аркылы да белеп була бит.

Суд утырышына исә журналистны залга кертү-кертмәү мәсьәләсен бары тик судья гына хәл итә ала. Залда тәртип саклаучы ролен үтәүче сакчылар бу хокукка ия түгел. Судья утырыш вакытында фотога, кино яки видеога төшерүне тыярга да мөмкин. Әмма блокнотка язып баруны тыя алмый.

Германия, АКШ кебек илләрдә суд утырышларында фотога төшерергә ярамый, шуңа да аларда суд репортажлары фотолар белән түгел, рәсемнәр белән бизәлә.

Журналистның тыйганнан соң да залда яшерен рәвештә фотога яки видеога төшереп утыруын күреп алсалар, аны шунда ук чыгарып җибәрәчәкләр. Инде күрми калсалар да файдасы юк, чөнки ул язманы күрсәтергә яки бастырып чыгарырга ярамый: шулай эшләгән очракта, журналистны җавапка тартырга мөмкиннәр.

Әлбәттә, тулы канлы журналист тикшерүе язарга ачык чыганакларда булган фактлар гына җитми. Күп кенә илләрдә вазыйфа биләгән кешеләрнең конфиденциаль дип саналган мәгълүматны язма яки телдән тапшыруы этиканы бозуга саналмый. Журналист мондый мәгълүматны куллана ала. Мисалга, Испания, Франция, Италия кебек илләрдә, ачык мәгълүматны алуда төгәл кагыйдәләр булмау сәбәпле, журналист һәм сәясәтче арасындагы аралашу яшертен мәгълүматны бернинди аерым шартларсыз алуга корылган.

Голландия һәм Скандинавия илләрендә исә сәяси тормыш ачык дип санала. АКШта һәм Швециядә дәүләт мәнфәгатьләрен яклауга хезмәт иткән мәгълүматны таратучыларга карата бернинди җаваплылык каралмаган.

Бөекбритания, Россия, Норвегиядә исә журналист мәгълүмат чыганагын сер итеп сакларга тиешле. Законда каралган аерым

ситуациялəрдəн башка, билгеле. Шулай итеп, ул үзенең, редакциянең абруен да саклый.

Четерекле мəсьəлəрнең берсе ул – телефон сөйлəшүлəре. Журналистка үз сөйлəшүлəрен аудиоязма сыйфатында саклап бару этика кагыйдəлəренə туры килə, материал əзерлəгəндə дə файдалы. Ə менə бүтəн ике кеше арасында барган сөйлəшүне яздырган вакытта, журналист этик кысадан чыга. Катнашучыларның берсе телефон сөйлəшүенең язылып баруына рөхсəт биргəн очракта гына ярый. Материал басылыр алдыннан икенче катнашучы да үз фикерлəренə бəя бирə алу хокукына ия.

### *4. Журналист тикшерүе барышында очрарга мөмкин булган əхлакый чиклəүлəр*

Кайчакта журналист хокук күзлегеннəн генə карап бетереп булмый торган ситуациялəргə дə очрарга мөмкин. Бу вакытта кирəкле юнəлешне аңа мораль, əхлак күрсəтəчəк. Əхлакый талəплəр – кешелəр, аерым социаль төркемнəр һəм җəмгыятьнең үзлектəн көйлəнешен тəэмин итүче нормалар алар.

Тикшерү алып баручы журналист, башка жанрларда эшлəүче хезмəттəшлəреннəн аермалы буларак, этик мəсьəлəлəр белəн ешрак очраша. Чөнки тикшерү – ул зур игътибарга һəм җəмгыять өчен зур əһəмияткə ия булган материал. Ул күп кенə мəгълүмат чыганакларына нигезлəнеп языла. Мəсəлəн, кешелəр, документлар, үзеңнең күзəтүлəрең. Күп очракта хакимият тарафыннан яшерелеп торган мəгълүматлар да килеп чыгарга мөмкин. Шулай итеп, əлеге жанр хокук өлкəсендəге проблемаларны гына түгел, ə этик мəсьəлəлəрне дə алгы планга куя. Бүгенге көндə матбугат битлəрендə укучы өстенə яңгыр булып яуган журналист тикшерүлəренə караган язмалар күбəеп китте. Бу илдə барган сəяси вакыйгалар белəн тыгыз бəйле. Озак еллар буе сүз иреге булмаудан интеккəн матбугат чаралары XX гасырның 90 елларында иркен сулап куйды. Файда китерүче, җəмгыятьтəге начар күренешлəрдəн котылырга ярдəм итүче тəнкыйть белəн бергə, расланмаган, дəлилсез фактлар, түбəнсетүче бəялəмəлəр, гражданнарның намусына һəм дəрəҗəсенə зыян салучы фикерлəр дə урын ала башлады. Шуңа да тəнкыйть язмалары укучылар тарафыннан да, журналистлар арасында да объективлык, кыюлык, дөреслек дəрəҗəсе ягыннан, ягъни əхлакый аспекттан тикшерелеп, игътибар

үзәгенә алына.

Безнең илдә этикага скептик караш хөкем сөрүгә карамастан, журналист һөнәре абруен кайгыртучылар өчен бу тема аеруча актуаль. Шуңа күрә дә журналист-тикшерүчеләр өчен бердәм этика кодексын булдыру зарур.

Төрле илләрдә этика мәсьәләсе төрлечә хәл ителә. Күбесендә махсус «этик фильтрлар» эшли. Алар журналист материалының кирәк дип тапканын гына халык хөкеменә чыгаруга ярдәм итә. Ул түбәндәге баскычлардан гыйбәрәт:

1. Илдәге законнар этик кысаларны билгели.

2. Бердәм этик нормалар профсоюзлар һәм журналистлар оешмалары тарафыннан кабул ителә.

3. Аерым ГМЧ һәм редакция кабул иткән этик кагыйдәләр дә бар.

4. Этика мәсьәләләрен һәр конкрет очрак буенча ГМЧы җитәкчелеге хәл итә.

5. Конкрет журналистның этик карашлары алгы планда тора.

Россиядә югарыда әйтелгәннәрнең беренче һәм бишенче пунктлары эшләп килә. Яшерен видеокамера куллану, кешенең шәхси тормышының кагылгысызлыгы һ.б. шундый мәсьәләләрне илдәге законнар күпмедер дәрәҗәдә җайга сала. Редакция кагыйдәләренә килгәндә, анда этик нормалар редакциянең матди хәленә яки репутациясенә зыян салу куркынычы янаганда гына эшли башлый.

Журналист тикшерүе алып баручы этика кысаларында ике төрле проблема белән очрашырга мөмкин. Беренчеләре мәгълүматны җыю һәм эшкәртү методларына бәйле булса, икенчеләре турыдан-туры материалга һәм журналистның үзе алдына куйган максатларына кагыла, ягъни аерым фактларны халык хөкеменә чыгарганда, аның нәрсәдән чыгып эш йөртүенә карый.

Журналист тикшерүендә кулланылган фактларның күбесе ачык чыганаклардан алына. Бу басылып чыккан яки һәркем ирешә алырдай мәгълүмат. Мондый чыганаклардан алынган мәгълүмат белән эш итү журналистка бернинди этик проблемалар тудырмый. Шулай да һәрвакыт уяу булырга кирәк, чөнки күпмедер вакыттан соң, журналистның шәхси архивында булган мәгълүматлар «начар» кулларга эләгеп, геройларга зур зыян салырга мөмкин. Мәсәлән, аерым оешманың матди хәле турындагы досье. Бу мәгълүмат

тикшерү эшенә генә түгел, ә криминал, шантаж белән эш итүчеләрдә дә кызыксыну уятырга мөмкин. Шуңа күрә мондый материалларны ят куллардан сакларга кирәк.

Әлбәттә, тулы канлы журналист тикшерүе язар өчен ачык чыганаклардагы фактлар гына җитми.

Еш кына журналист-тикшерүчегә мәгълүматны сатарга теләүчеләр дә очрый. Көнчыгышта бу нисбәттән ике кагыйдә яшәп килә:

- мәгълүмат чыганагына акча мәгълүматны табуга сарыф иткән вакытка карап түләнә;

- әлеге килешү аерым документ белән расланырга, имзаланырга тиеш. Кыенлыклар килеп туган очракта, аны дәлил буларак күрсәтеп булачак.

Россиядә, моңа бәйле аерым кагыйдәләр булмау сәбәпле, мәгълүматны турыдан-туры хәбәрче сатып алу кемгәдер ришвәт бирү кебек бәяләнергә дә мөмкин. Ул мәгълүмат язма рәвештә бирелеп, редакция тарафыннан расланса, аңа гонорар формасында да акча түләп булыр иде, билгеле, һәм кайбер редакцияләр шулай эшли дә. Тик күп очракта, мәгълүмат бирүче үз сүзләрен язма рәвештә теркәргә теләми һәм бу табигый да.

Тикшерү барышында журналистка төрле методлар кулланырга туры килә. Шуларның берсе – һөнәр алмашу. Еш кына «һөнәр алмашу» ысулы этик яктан төрле авырлыклар китереп чыгара һәм кешеләргә, оешмаларга әхлакый һәм матди зыян китерә. «Һөнәр алмашканда», журналист мәгълүматны «арттырып» яки алдап бирергә тиеш түгел. Шуның өстенә, сенсацион яңалык яки язмага аерым бер төсмер өстәү өчен кешенең яшерен серләрен ачып бирергә ярамый.

Журналист-тикшерүче каршында килеп туган тагын бер бәхәсле мәсьәлә ул – заказга эшләү. Күп очракта тикшерү алып барган журналистны заказга эшләүдә гаепләргә мөмкиннәр. Заказга эшләнелгән очракта, журналист тикшерүе, заказ бирүче фикереннән генә чыгып, берьяклы гына үткәрелә. Соңгы арада матбугат битләрендә журналист тикшерүләре, үзләренең төп миссияләреннән читенеп, «пиар» функциясен дә үти башлады, ягъни аерым конфликтлы мәсьәләгә алынып, журналист проблеманы кирәкле яссылыкта сурәтләп бирми, ә бары тик кемнеңдер имиджын күтәрүгә хезмәт итә. Мондый язмалар сайлау

агитациясе барышында күп очрый һәм этика кысаларына туры килми.

Журналист һәм мәгълүмат чыганагы арасында була торган мөнәсәбәтләрдә этик нормалар аеруча мөһим, чөнки әгәр аларны бозса, журналист үзе тикшерә торган җинаятьләрне башкарган җинаятьчеләрдән кайсы ягы белән яхшырак булыр иде соң? Димәк, шәхси файда, сәясәт, акча – болар берсе дә жрналистны юлдан яздырырга тиеш түгел, тикшерүенең башында бары тик җәмәгать ихтыяҗлары гына тора ала.

Журналист тагын «җәмәгать ихтыяҗлары» һәм «җәмәгатьчелек кызыксынулары» дигән ике төшенчәне бутарга тиеш түгел. Җәмәгатьчелекне күп нәрсә, шул исәптән, төрле танылган кешеләрнең шәхси тормышына бәйле гайбәтләр дә кызыксындырырга мөмкин бит.

Мәгълүмат чыганакларына хөрмәт белән карау мөһим. Әгәр алар исемнәрен яшереп калдырырга теләсәләр, иң элек моның сәбәбен сорарга кирәк. Сәбәпләре ачыклангач, әгәр вәгъдә бирелә икән, журналист аңа тугъры калырга, чыганакны беркемгә дә ачмаска тиеш.

Җыелган һәм таратылган мәгълүмат кемнәрнедер акларга, ә икенчеләргә борчу, мәшәкать, зыян китерергә дә мөмкин, димәк, урынсызга рәнҗетүдән сак булырга, аеруча балалар һәм үз-үзләрен яклый алмый торган башка төркемнәр белән игътибарлы булырга кирәк. Кешеләр белән аралашканда, кайгы, борчу кичергән, якыннарын югалтканнар белән сөйләшкәндә, аларның күңел яраларына усал кагылмаска тырышу мөһим.

Мәгълүмат чыганаклары белән бу кагыйдәләрне үтәгән очракта да, журналист язма «геройлары» белән аралашканда, алай сак кыланмаска да мөмкин. Бер яктан караганда, журналист дөрес эшли кебек: журналист тикшерүе жанрындагы язмаларның «геройлары» булып ришвәтчеләр, җинаятьче төркем әгъзалары, карак, көчләүче, үтерүчеләр тора бит. Андый затларның журналистта хөрмәт хисе уятмавы аңлашыла. Әмма бу аңа алар белән сөйләшкәндә әхлак турында онытып торырга мөмкинлек бирми. Әгәр ришвәтче турында яза икән, ул бу кешенең ришвәт алуга кагылышлы якларын гына сурәтләргә тиеш, әйтик, аның шәхси тормышындагы серләрен, мисал өчен, гаиләсендә хатынына хыянәт итүе турындагы мәгълүматны язмасыннан төшереп калдырырга тиеш.

Журналист «геройлары» белән шәхси очрашып сөйләшергә омтылса, яхшырак, шул рәвешчә, ул аларга җавап бирү хокукын тәэмин итә.

Урындагы кешеләр, җитәкчеләр, сәясәтчеләр кебек җәмәгатьчелек күз алдында торган затларга караганда, журналист гади халыкның шәхси тормышы турындагы серләренә аеруча игътибарлы булырга тиеш.

Кемне дә булса җинаять эшләүдә шикләнүче дип игълан иткәнче, автор йөз кат уйласын иде. Гади халыкның дөреслекне белү хокукы белән шикләнүченең хаклы судка булган хокукы арасында баланс сакланырга тиеш.

Чынлыкта исә этик нормалар редакциянең матди хәленә, яки репутациясенә зыян салу куркынычы янаганда гына эшли башлый. Әле бу кагыйдәләр дә язма формада теркәлмәгән диярлек. Күп кенә көнбатыш илләрендә исә алар махсус документларда яшәп килә һәм һәр журналист тарафыннан үтәлергә тиешле канун буларак яши. Шуны да әйтергә кирәк, чит илләрдә журналист-тикшерүчеләрнең этик мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән ассоциацияләре бар. Россиядә мондый оешма XX-XXI гасыр чикләрендә генә пәйда булды, шуңа күрә дә бу өлкә бердәм этика нормаларына формалашып өлгермәгән. РФ һәм ТР Журналистлар берлеге каршында эшләүче этика мәсьәләләрен караучы коллегия утырышларында теге яки бу проблемаларны өйрәнәләр, гаеплеләр җавап тота.

### *5. Журналист язмаларында китәргә мөмкин булган хаталар*

Бик еш кына журналист тикшерүе алымы белән табылган мәгълүматларны кулланып текст төзү барышында хаталар китәргә мөмкин. Андый очраклар журналистны гаепләү, аннан да бигрәк, башкарган хезмәтен юкка чыгару, тупланган мәгълүматларын законсыз дип табу өчен нигез булып торырга мөмкин. Шуңа күрә журналист тикшерүе текстын әзерләгәндә, автор һәр сүзне, җиде тапкыр уйлап, бер тапкыр язарга тиеш.

Әдәпсез сүзләр, дөрес булмаган терминология куллану да журналистның тикшерену нәтиҗәләрен судка бирүгә китерергә мөмкин.

Мәсәлән, кешеләр турында сөйләгәндә, күчерелмә мәгънәдә булса да, хулиган, бандит, карак, бур, фахишә, шпион кебек сүзләр

куллану судка мөрәҗәгать итүгә китерергә мөмкин. Аның бит карак, бандит дигәннәренең юридик мәгънәдә, төрле закон актларында кулланылу факты да бар. Экспертлар тарафыннан бу сүзләрнең күчерелмә мәгънәдә, читләтеп, сарказм белән кулланылганын раслап булган очракта да, журналистның үзен гаепләп, барлык тапкан мәгълүматларын юкка чыгарырга мөмкиннәр.

Сатлыкҗан, дошман, сәяси фахишә кебек публицистик төсмер салынган сүзләр дә җитәрлек дәлилләр булмаган очракта кулланылса, журналистка зыян салырга сәләтле.

Җитәрлек дәлилләр булмаган килеш, материал геройларына надан, акылсыз, бюрократ, ялкау кебек сыйфатламалар тагу да закон тарафыннан акланмый.

Әйтик, «Фәлән Фәләнев алдый» диелсә, бу сүзләре өчен журналистны судка өстерәмәсләр дә, әмма «Фәлән Фәләнев алдакчы» дигән өчен башыннан сыйпамаячаклар.

Күп вакытта журналист геройларның исемнәрен күрсәтми, фамилияләренең баш хәрефләрен генә бирә. Әмма язмада сөйләнәчәк вакыйгалар, аның кайда яшәве, нинди хәлләргә таруы, гаилә хәле турындагы мәгълүматлар буенча кем икәнен танып алу авырлык тудырмый. Менә шундый вакытларда әлеге кеше, үзенең хокуклары бозылуда гаепләп, журналистны судка бирсә, суд аның матур исеме, намусы һәм дәрәҗәсен яклап чыгарга мөмкин.

Төрле шау-шулы, гаугалы вакыйгалар турында суд тикшерүе барышында ул турыда газета-журналларга язып чыгарга, радио, телевидениедән сөйләргә мөмкин, әмма рәсми тикшерү эшләре тәмамланмый торып, шул вакыйгаларны сурәтләгән китап бастырып чыгаруны тоткарлап торырга кирәк. Кем белә, бәлкем суд гаепле кешене гаепсез итеп тә танырга мөмкин бит. Ә инде китап кибетләренә таралган китапны кире җыеп алып булмаска мөмкин.

Әйтәсе сүзне дә әйтергә, җаваплылыктан да ничек котылып калырга соң?

Беренчедән, журналист әйтәсе килгән фикерен хикәя җөмләләр кулланып түгел, сорау формасында, анысында да җавап көтелми торган риторик мөрәҗәгатьләр аркылы әйтә ала. Мәсәлән, «Фәлән Фәләнев, хезмәт вазыйфаларын файдаланып, үз кесәсен калынайткан, бюджет акчаларын үзләштергән» диясе урынга «Кызык, Фәлән Фәләневнең эшләгән эшләрен хезмәт вазыйфаларын

файдаланып, үз кесәсен калынайткан, бюджет акчаларын үзләштергән дип әйтеп була микән?» дип язылса, журналист өчен куркыныч янамаячак.

«Бәлкем», «миңа калса», «минем фикеремчә», «халык сөйләвенчә» кебек сүзләр куллану да язма геройларына судка мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек калдырмый.

Прокуратура тарафыннан тикшерелүче, тиздән судта каралачак теләсә-кайсы вакыйганы да «җинаять» дип атарга ярамый. Журналист, хәтта үзенең шәхси тикшерүе вакытында кире какмаслык дәлилләр таба алган очракта да, гаепләнүчене җинаятьче дип атый алмый. Бары шул дәлилләр нигезендә аңа карата гаепләү белдерүе белән чыга ала. Аңа кадәр, журналист «гаепләнүче», «шикле», «тикшерү астында тотылучы» дип кенә әйтә ала, әмма «җинаятьче» дип атарга, гомумән, бу кешенең шәхси тормышына кысылып, аның гаиләсен һәм туганнарын түбәнсетергә хакы юк. Ул бары укучыларына дөреслекне язарга, вакыйганы ничек бар шулай күрсәтергә тиеш. Язмасында герое турында теләсә нәрсә әйткән журналист бары субъектив бәя биргән дип санала.

Бигрәк тә танылган кешеләр арасында гаепләнүчеләр булса, бу вакыйганы айлар буе яктыртырга була. Мондый язмалар авторы һәрвакыт игътибар үзәгендә булачак. Шуңа күрә дә аннан аеруча да сак булу сорала.

### *Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр*

1. Социаль институт буларак, журналистиканың эш принциплары нинди законнарга нигезләнә?
2. Россия Федерациясе Конституциясендә журналистларга кагылышлы нинди таләпләр бар?
3. «Гаммәви мәгълүмат чаралары турындагы» закон журналист алдына нинди бурычлар билгели?
4. Коммерция сере нәрсә ул?
5. Нинди мәгълүматларны коммерция сере белән бутарга ярамый?
6. Чит илләрдә сер белән бәйле нормалар бармы?
7. Мәгълүмат туплау этабында журналист алдында торган хокукый чикләүләр нинди?
8. Журналист өчен сер саклау мәсьәләсенә карашыгыз нинди?
9. Төрле органнар, оешмаларга мәгълүмат сорап мәрәҗәгать итү ничек алып барыла?

10. Яшерен аудио-, видеоязма, кино һәм фото аппаратура куллану нинди очракларда үзен аклый, дип уйлыйсыз?
11. Кешеләрнең намус, дәрәҗә, һәм эш репутациясен яклау турында журналистларга нәрсәләрне белү мөһим?
12. Журналист өчен гаепсезлек шартын саклау шарты нәрсә ул?
13. Журналистларның суд утырышларында катнашу мөмкинлеге мәсьәләсе.
14. Журналист тикшерүе үткәрүнең әхлакый яклары турында нәрсәләр беләсез?
15. Этика мәсьәләсенә төрле илләрдә нинди карашлар кабул ителгән?
16. Махсус «этик фильтрлар» нәрсә ул?
17. Мәгълүматны җыю һәм эшкәртү методларына бәйле этик фильтрлар турында сөйләгез.
18. Журналист материалына һәм журналистның үзе алдына куйган максатларына кагылышлы этик фильтрлар турында сөйләгез.
19. Ачык чыганаклардан мәгълүмат җыю турында ниләр беләсез?
20. Һөнәр алмашу алымын үтәү барышында этик нормаларга зыян килергә мөмкинме?
21. Журналист өчен заказга эшләү рөхсәт ителәме?

# *БИШЕНЧЕ БҮЛЕК. ЖУРНАЛИСТ ТИКШЕРҮЕ ЖАНРЫНДА ӘЗЕРЛӘНГӘН ЯЗМАЛАРГА АНАЛИЗ*

## *1. Хәзерге татар матбугатында тикшерүләр үткәрү тәҗрибәсе*

Бүген эзләнү һәм тикшерү амплуасы журналистларны кызыктыра торган өлкә. Үзенең авырлыклары, билгеле бер куркыныч яклары булса да, бу өлкәдә эшләүче журналист бик тиз танылу ала. Ул һәрвакыт иң үткен язмалар әзерли, эшчәнлек алып барганда, гадел һәм җаваплы булып кала. Журналист үзен язучы гына түгел, тикшерүче буларак та хис итә.

Журналист тикшерүе белән кызыксынган һәр журналист бу эшчәнлек төре белән шөгыльләнә ала. Моның өчен теләк булу, гаделлек, хакыйкать өчен көрәшә белү кирәк. Тикшерү нәтиҗәсендә язылган материал күпкә кыйммәтрәк һәм халык хәтерендә яхшырак истә кала, тикшерү тарихына яңа эзләр сала.

Хәзерге катлаулы заманда юк кына социаль каршылыклар гел чыгып кына тора, шуннан алар конфликтларга, аннары төбәкара, милләтара, глобаль проблемаларны да китереп чыгаралар. Шул ук вакытта мондый темалар журналистларны үзләренә җәлеп итә һәм еш кына журналист тикшерүе объекты булып тора. Мондый очракларда журналистның төп кораллары: чыганакларны, кешеләрне өйрәнү, төрле типтагы документлар белән эш итә белү, сабыр гына дөрес интервью алу, әхлак кагыйдәләрен онытмыйча, социаль җаваплылыкны тоеп эш итү.

Журналистның тикшерү материалы, дөрес эш этапларын үтәгәндә, дөрес алымнар кулланган вакытта гына көчле була. Әйтик, норматив хокукый дәлилләр белән эшенә йомгак ясау, авторитетлы һәм бу мәсьәләдә компетентлы кешенең фикерен яктырту (үзе каршы булмаса), шаһитләрнең күрсәтмәләре, статистик, документаль мәгълүматларны яктырту тикшерү материалын ышандырырлык итә һәм дөреслеген күрсәтә.

Журналист-тикшерүче үзенең тикшерү объектын сайлаганчы бик ныклап уйларга тиеш, аннары аны яхшылап өйрәнү зарур. Фактларга нигезләнеп, дөрес дәлилләү чаралары кулланып, һәр фикерен кат-кат тикшереп, законнан һәм этик кагыйдәләрдән чыкмыйча, хакыйкать белән сугарылып язылган очракта гына, материал тиешле дәрәҗәдә язылачак.

Бу бүлектә соңгы вакытта актив журналист тикшерүе алымнары белән эш иткән «Ватаным Татарстан», «Безнең гәҗит», «Ирек мәйданы», «Акчарлак», «Сираҗи сүзе» газеталарында эшләүче журналистларның иҗатларына, эш алымнарына күзәтү ясарбыз, осталык мәктәбе белән танышырбыз. Теге яки бу авторның иҗат үзенчәлекләренә тукталырбыз. Нигездә, аерым журналистларның иҗаты бәяләнәчәк. Тикшерү материалларына анализ ясалачак.

***«Безнең гәҗит».*** «Безнең гәҗит» газетасы журналист тикшерүенә киң мәйдан бирә. Редакциясендә телефон тынып тормый. Гадәттә, ярдәм сорап шалтыраталар, укучылар газетадан яклау эзли. Журналист тикшереп кайткач, кызыклы язмалар әзерләнә. «Журналист өйрәнә, укучыларыбыз хөкем итә» сәхифәсендәге язмаларны алсак та, алар тикшерелеп, бөтен яклап өйрәнгәннән соң укучыларга җиткерелә.

Газета атнага бер тапкыр чыга. Әлеге газета татар телендә чыгучы бердәнбер иҗтимагый-сәяси демократик газета. 2003 нче елда беренче саны дөнья күрә. Газетада журналист тикшерүе материаллары еш басыла. Газетаның баш мөхәррире Илфат Фәйзрахманов: «Һәр газетада бер журналист тикшерүе булырга тиеш һәм ул протокол, полициягә кадәр барып җиткән булырга тиеш», – ди. Тикшерүче журналистлар арасында Айгөл Закирова, Фәнзилә Мостафина исемнәрен атап китәргә мөмкин. Газетаның һәрбер санында аларның тикшерү материаллары басылып килә. Әлеге газетада шулай ук Искәндәр Сираҗи, Эльвира Фатыйхова да эшләде, алар да журналист тикшерү жанрында иҗат иттеләр.

Газетаның баш мөхәррире Илфат Фәйзрахманов өчен дә бу жанр ят түгел. Телевидение журналисты булып эшләгән чорда ук аның тикшерүгә корылган сюжетлары шактый чыкты. Шулар арасында эксперимент методы белән эшләнгән сюжеты үзенчәлекле иде. Ул бомж булып көне буе йөри, яшерен камера аны төшерә. Журналистның бомжларның тормышларын белү, язмышларын аңлау өчен әзерләнгән тапшыруы күпләрне битараф калдырмагандыр. Илфат Фәйзрахмановның шәхси газетасын булдырганнан соң, әлеге жанрда язылган материалларга өстенлек бирүе юкка түгел. Чөнки мондый язмаларның үз аудиториясе бар. Төпле, өйрәнеп язылган, фикерле язмалар укучыны басмага якынайта, дөрес юл күрсәтә. Журналист объектив карашы белән

укучыда ышаныч уята. Кешеләр үзләрен яклаучыны, аңлаучыны табарга теләп, күпчелек гаделлек һәм дөреслек эзләп, газетага мөрәҗәгать итә. Редакция шулай итеп хокук өлкәсендәге белемне дә кулланып, кыерсытылганнар мәнфәгатен яклауны үз өстенә ала. Гомумән, «Безнең гәҗит» газетасын ярдәм кулы сузучы газета дип әйтергә була. Кешегә төрледән-төрле мәгълүмат ташкыны агылып торган вакытта, шуның астында күмелеп калмау, вакыйга һәм фактларга дөрес бәя бирү, үз кыйблаңны югалтмау өчен кирәкле дөрес сүзләр куллану, бернәрсәдән дә курыкмыйча, үз сүзен әйтә белгән көчле рухта язучы журналистларның булуы мөһим.

«Безнең гәҗит»тә хатлар бүлеге дә уңышлы гына эшләп килә, укучыларның ярдәм сорап килгән хатларына журналистлар журналист тикшерүе үткәреп, проблемаларны чишәләр. Газетада «Кайнар элемтә» дә эшләп килә – халык шалтырата ала, үзен борчыган сорауларын бирә һәм аларга җавап ала.

***«Акчарлак».*** Журналист тикшерүе язмалары «Акчарлак» газетасы да үз урынын алып тора. Газетада тикшерү эшләре белән шөгыльләнүчеләр арасында Эльмира Флүн, Лилия Заһидуллина, Марсель Әскәров, Лилия Йосыпова язмалары бар. Соңгы вакытта бу рубриканы Эльмира Флүн алып бара. «Акчарлак» газетасының интернет-сайтында да махсус «Журналист тикшерүе» рубрикасы эшләп килә. Анда журналист тикшерүе алып барылган язмалар белән танышырга була.

2001 елда «Акчарлак» газетасын Татарстанның халык артисты Габделфәт Сафин һәм аның тормыш иптәше Рузилә Хасим кызы Сафина оештыра. «Акчарлак», шәхси басма буларак, иң күп укучыларны туплый алган басма. Үзенең укучылары белән даими элемтәдә тора. «Акчарлак» газетасында укучылар арасында актив булган «Зарлы телефон» рубрикасы эшли. Анда үзләренең проблемалары, моң-зарлары, чишелмәстәй проблемалары булганнар шалтырата. Әйтергә кирәк, күп кенә журналист тикшерүе өчен азык бирердәй темалар әлеге рубрика аша да керә. Шул ук вакытта газета хатлар да ала һәм алар шулай ук тикшерү эшенә нигез булып тора.

Газетаның тикшерү эшләре алып баручы журналисты Эльмира Флүн мондый язмаларны барып һәм өйрәнеп язуның үз кыйммәте бар, дип саный. Аның фикеренчә, үз күзләрең белән күреп-күзәтеп һәм сөйләшеп язылган язмалар гына укучыны ышандыру көченә ия.

Э.Флүн башка төрле журналистиканы, күрмичә генә язмалар әзерләүне кабул итмәвен дә белдерде «Акчарлак» газетасы белән очрашу вакытында.

«Акчарлак» сайтында «Журналист тикшерүе» рубрикасындагы тикшерү эшенә кагылган язмаларны укырга, архивта элеккеге язмалар белән дә кабат танышырга мөмкин.

***«Ватаным Татарстан».*** Газетада озак еллар дәвамында «Хат юлга чакырды» дип аталган рубрика эшләп килә. «Журналист тикшерүе» рубрикасының аваздашы ул. Шул ук алымнар кулланыла, укучының проблемаларын хәл итүгә үзенең зур өлешен кертә әлеге рубрикада басылган язмалар.

«Ватаным Татарстан» йөз еллык тарихы булган басма. 1918 елда газета «Эш» исеме белән нәшер ителә башлый. Редакциягә һәрвакыт укучылардан хатлар күп килә. Газетада «Хатлар бүлеге», соңрак «Хатлар һәм социаль мәсьәләләр бүлеге» эшләп килде. Монда төрле характердагы хатлар килә. Алар төрле бүлекләргә таратыла. Журналистлар хатларны өйрәнү буенча эшли башлый. Кемдер юлга кузгала, кемдер шунда ук шалтырата башлый, кемдер ачыкларга керешә. Һәрхәлдә укучы хатына шунда ук реакция белдерелә. «Хат юлга чакырды» рубрикасының да башлангычы булып укучы хатлары тора. Аларда күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итәр өчен журналистлар журналист тикшерүендәге барлык алымнарны куллана. Бәлки әлеге язмаларны күптәннән журналист тикшерүе дип атау кирәк булгандыр. Чөнки газетада журналист тикшерүе исеме астында язмалар басылмый диярлек. Әмма «Хат юлга чакырды», «Борчыган мәсьәлә» дигән рубрикада тикшерү эшләрен үз эченә алган язмалар даими урын ала. Аларда төрле социаль мәсьәләләрне хәл итү, чишелмәстәй проблеманы ачыклау, укучы мәнфәгатен яклау, укучыларга булышуны максат итеп куела. Журналистлар тикшерүе язмаларының нәтиҗәлелеген дә күрергә гадәтләнгән. Теге яки бу журналист тикшерүеннән соң нәрсә үзгәргән, укучыларга редакциянең ярдәме тигәнме? Журналист килеп киткәннән соң үзгәрешләр булганмы? Ә андый язмалар һәрбер журналист тормышында була. Һәркем газетада теге яки бу бүлектә эшли һәм алар, командировкаларга чыгып, укучысына ярдәм итәргә ашыга. «Ватаным Татарстан» газетасында тәҗел мәсьәләләрне хәл итәргә атлып торучы журналистлар эшләде. «Хатлар һәм социаль мәсьәләләр» бүлеге мөдире Люция

Фаршатованың хат эзеннән язылган язмалары журналист тикшерүенең үзенчәлекләрен үзендә туплаган иде. Авыл җирендәге юлсызлык, мәдәният учакларының начар хәлләре, аерым кешеләрнең язмышларын, аларны борчыган мәсьәләләрне өйрәнеп язган журналистлар арасында Алсу Хәсәнова, Камил Сәгъдәтшин, Фәния Әхмәтҗанова, Римма Бикмөхәммәтова, Рәсимә Муллаянова-Галиеваларны санап китәргә була.

Газетада озак еллар дәвамында «Суд залыннан» рубрикасы эшләп килде. Аны журналист Камил Сәгъдәтшин әзерләде. Бу язмаларда суд утырышлары яктыртылды, күп кенә ачыкланмаган сорауларга җаваплар эзләнде. Әлеге материалларның шулай ук журналист тикшерүе алымнарын кулланып язылган мәкаләләр белән уртаклыгы шактый күп булды. Һәрхәлдә, журналист Камил Сәгъдәтшинны әлеге язмалардан соң үзен дә күп тапкырлар судка бирәләр. Бу язмалар эмоциональ фикер, тел-стиль чараларының байлыгы белән аерылып тора иде. Әлеге төр язмалар бүген газетада әзерләнми.

***«Ирек мәйданы».*** Татарча басмалар арасында ул популярлык казанган һәм күп тиражлы газеталарның берсе булып санала. Әлеге басмада укучыларны кызыксындырган барлык темалар да урын алган диярлек. Көн кадагына суга торган яңалыклар белән беррәттән, артистлар тормышы, криминал, фаҗигале хәлләр, дин, кызыклы киңәшләр, хокук темасы һәм журналист тикшерүләре дә урын алган. Журналист тикшерүләре язмалары әзерләгән журналист Рәмис Латыйпов иҗатын билгеләп үтү кирәк. Бүген аның эшчәнлеге башка ГМЧ белән бәйле булса да, заманында аның үткен язмаларын күп укырга мөмкин иде. Аларның күбесе «Шулай яшәп ятыш» сәхифәсендә чыкты. Хаклык таләп иткән темаларга алынган журналистларның тикшеренүләре, иҗат методы һәм аның эшләү этаплары үзенчәлекләре, һәрхәлдә, укучыны битараф калдырмагандыр.

«Ирек мәйданы» газетасы фаҗигале хәлләрнең кайнар эзеннән барып өйрәнеп тасвирлаган язмаларны биреп баруы белән аерылып торды. Бу рубриканы үз вакытында Эльмира Сәлахова алып барды. Тикшерү язмалары автор фотолары белән дә баетылды. Шулай ук Римма Бикмөхәммәтова язмаларында журналист тикшерүләренең адымнары кулланыла иде.

***«Сиражҗи сүзе»***. Әлеге басма шәхси газета буларак яңарак кына барлыкка килсә дә, үз укучылары таба алды. Газетаны оештыручы журналист Искәндәр Сиражҗи «Акчарлак», «Безнең гәҗит»тә эшләгәндә үк зур танылу ала. Укучыларын үз фикерен артыннан ияртә алу, газета укучысының проблемаларын чишү, аларга ярдәм итү максатыннан эшләгән язмалары аңа танылу алып килә. Эльвира Фатыйхова белән «Сиражҗи сүзен» әзерли башлаганда ук, газетаның укучы өчен бик кирәкле басма булуын аңлап алып эш итә алар.

Кыю, тәнкыйтькә корылган журналист тикшерүе язмалары газетада даими басылып килә. Баш мөхәррир Искәндәр Сиражҗи укучылар белән һәрдаим элемтәдә тора. «Электрон почтадагы хатлар, социаль челтәрләр аша аралашу барышында күп кенә темалар баш калкыта. Проблемалары булган кешеләр безне үзләре эзләп таба, без аларга ярдәм итәргә тырышабыз», – дип белдерә ул.

Газетада эшләүче журналист Эльвира Фатыйхова эш үзенчәлекләре турында менә нәрсәләр ди: «Журналист тикшерүе жанрында язгач, кайберәүләр пышылдап кына әйтергә курыкканны да газетага язарга, ягъни дөньяга чыгып кычкырырга туры килә. Телефоннан шалтыратып кисәтүләргә, янауларга ияләнелгән. Андыйга игътибар да итмим, иммунитет формалашкан, мөгаен. Подъезд төбендә саклап торып, «җитди сөйләшү»гә килгәннәре дә бар. Тик, гадәттә, мондый куркытулар уртак фикергә килү белән тәмамлана, мин – аларны, алар мине аңлый. Шәһәр уртасында машинама ике тапкыр атып киттеләр. Җинаять эше ачылса да, файдасы булмады, кемнәр атканын тапмадылар. Моны эшләүчеләр үзара аңлашуга өйрәнмәгән, шулай атышып кына мәсьәләне чишә, күрәсең. Без дә үз тикшерүебезне үткәрдек, кемнәр икәнен ачыкладык. Чынлап та, без шикләнгәнчә, Казан базарларына хуҗа булган әзәри кешеләре турында язуым ярамаган икән. Мондый вакыйгалар аркасында эштән күңел кайтырга тиеш түгелдер, чөнки һөнәрне сайлаганда ук үзеңне нинди куркыныч астына куюыңны бизмәнгә салып карыйсың, нинди юлдан атлавыңны чамалыйсың. Хәтта һөнәрләребезнең куркынычын исәпләмәгәндә дә, гомеребезнең кайсы мизгелендә нинди бәхет ишеләсен яки афәт киләсен беребез дә белми. Барыбыз да бер Аллаһы Тәгалә кодрәте белән яшибез».

## *2. Газетада чыккан тикшерү язмаларына анализ ясау*

***«Безнең гәҗит»тәге язмаларны өйрәнү.*** «Казанда тәрәзәче мошенниклар йөри» исемле мәкаләдә (авторы – Сөләйман Шакиров) журналист Казандагы Ломжа урамыннан тикшерү үткәрә башлый. Әлеге урамда яшәүче Марзыя апаның зарлануларыннан башланып китә. Зарланучы апаның тәрәзә куючы тарафыннан алданганын тыңлаганнан соң, шундый ук мошенниклардан зыян күрүче – бер-ике кешедән интервью алган. Соңыннан мошенникларның эзенә чыгып, телефон номерларын белеп, журналист үзе шалтыратып, тәрәзәгә заказ биреп караган. Әлеге мәкаләнең темасы кеше мөрәҗәгатеннән башланган. Ул укучыларны игътибарлы һәм тикшерүчән булырга өйрәтә. Бер үк вакытта журналист теманы ачып бетермәгән, дип уйларга да җирлек кала. Чөнки алдаучы фирмалар ничек бар, шулай кала. Аларга карата бернинди җинаять эше ачылмый. Журналистның телефоннан сөйләшүе белән генә чикләнелә.

Әлбәттә, журналист юрист та, полиция хезмәткәре дә түгел һәм артык күп вәкаләтләре юк. Әмма бу проблеманы чишү өчен кирәкле органнарга җиткерү һәм халыкка мәсьәләнең чишү юлларын күрсәтү – аның бурычы. Журналист тикшерүендә автор ябык чыганаклардан да кулланырга тиеш булгандыр. Халыкка мәгълүм булмаган, ябык информацияне җиткерү язманы кызыклырак, җинаять эше ачуны нәтиҗәлерәк итәр иде. Ябык мәгълүмат чыганагы булып төрле дәрәҗәдә яшерелгән һәм шифрланган документлар, электрон һәм телефон элемтәләре аша килгән беркем белми торган мәгълүмат «прослушкалар», социаль челтәрдәге шәхси сайтлар, тикшерелсә, нәтиҗәле журналист тикшерүе булыр иде.

«Безнең гәҗит» газетасында басылган «Бай йорты»нда батырлар яши» (2013нче ел, 11нче декабрь) дип исемләнгән журналист тикшерүенә тукталып үтик. Язмадагы конфликт Балтач районында яшәүче халык һәм район җитәкчеләре, ә, дөресрәге, хакимият арасында килеп чыккан. Иске, җимерелеп беткән, сәләмә йортта 4 гаилә яши икән. Әлеге йортның хәле бик мөшкел: идәннәре җимерек, торбалардан су ага, тараканнар, тычканнар кешеләрдән курыкмыйча, өйгә хуҗа булып йөриләр, ди. 2006-2007нче елларда әлеге йорт «Тузган торак» программасы

исемлегенә кергән. Монда торган кешеләргә инде яңа фатирлар да төзелгән икән. Махсус социаль программа буенча аларга яңа квартира бушлай тиеш икән. Өмет өзми көткән кешеләр яңа йортка газ кертергә дип акча да биргәннәр. Ләкин закон үзгәрү сәбәпле, кешеләрдән яңа квартира өчен акча сорый башлаганнар. Район җитәкчелеге социаль ипотекага басарга «киңәш» итә.

Журналист, җимерек өйгә барып, андагы хәлләрне күреп, хуҗаларны сораштырып кайткан. Соңыннан башкарма комитет рәисе Рамил Илдус улы Шакиров белән дә сөйләшү алып барылган. Нәтиҗәдә, автор – Эльвира Фатыйхова, җимерек йортта яшәүчеләргә торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына, Президентка юллап хат язарга киңәш итә.

Язма 4 бүлеккә бүленгән. Беренчесе язманың проблемасын аңлата: автор җимерелгән йортны тасвирлап күрсәтә. Икенчесе – «Сабантуйдан бирле йорт көтәбез». Монда җимерек өйдә яшәүчеләр белән сөйләшү, проблеманы алар күзлегеннән күрсәтеп язылган. Өченчесе – «Закон үзгәргәнне көтәләрме». Монда Эльвира Фатыйхова Рамил Шакиров белән интервьюны китергән. Дүртенчесе – «Алдамагыз – тотылырсыз!» дип исемләнгән. Монда инде автор, нәтиҗә ясап, үзенең киңәшләрен яза.

Эльвира Фатыйхованың язмасын борчылып язганы сизелә. Текстта күп кенә кабатлаулар, чагыштырулар, җанландырулар моны дәлилли. «Минем беркайчан да, кабатлап әйтәм, беркайчан да мондый начар хәлдәге йортны күргәнем юк иде...»; «...Мондагы хәлләрне үз күзем белән күргәнгә, кулым йөрәгемә куеп әйтәм: шушы йортка көн саен берничә кат кереп-чыгып йөргән, биредә әле дә яшәп ятучы кешеләрдән дә батыр кеше дөньяда юктыр...»; «...Йорт ике яктан бөкләнеп, түбәнең авырлыгына чыдый алмагандай, нечкә билле самавар хәленә кереп бара...»; «...Йортның «биле» нечкәргән саен, аның түшәме белән дивар арасы да шулкадәр ныграк киңәеп, йорт эченә җил үтә...»; «...Йортның янәшәсенә йөк машиналары узып китсә, ул калтырап куя...»; «...Әйтерсең лә, хәзер үк лапылдап җиргә сеңәр иде, тик эчтә яшәүче кешеләрне басып үтерергә курка...».

«Журналист тикшерүе» сәхифәсендәге язмаларны алсак та, алар тикшерелеп, бөтен яклап карап укучыларга җиткерелә. Кайбер язмалар башкаларның күңел кылларына тиеп, алар да үзләренең шундый хәлләрдә калганнарын, проблемаларын сөйләр өчен

киләләр. Газетаны укучылар арасында төрле сораулар туа, тормышларында төрле вакыйгалар була. Тикшерү язмалары әнә шулай туа.

«Безнең гәҗит»тә башлаган тәҗрибәсен Эльвира Фатыйхова «Сиражи сүзе»ндә дәвам итә. Аның журналист тикшерүе язмаларында нәкъ башлангыч иҗатындагы кебек тынгысызлык, шикләнү, төпченеп өйрәнүгә корылган эш сыйфатлары хас. Эльвира төрле социаль-икътисадый һәм иҗтимагый проблемаларны күтәргән мәкаләләрендә дә журналист тикшерүе алымнарын куллануны хуп күрә.

«Безнең гәҗит»тә соңгы вакытта журналист тикшерүләре белән даими шөгыльләнүче авторларның берсе – Айгөл Закирова. «Журналист өйрәнә, укучыларыбыз хөкем итә» сәхифәсенең даими авторы да ул. Күпләр өчен актуаль булган «Боровое» дача кооперативында йортсыз калу куркынычы янаган проблема хакында булган язманы анализлап үтик. «Йортсыз калсак, нишләрбез?» язмасы «Безнең гәҗит» газетасының 2014 елның 3 декабрь санында басылган иде. Аның авторы – тикшерүче журналист Айгөл Закирова. Кич белән өеңдә йокларга ятасың, ә иртән йортыңнан җилләр иссә, урамда каласың... Бу хәл төштә яки әкиятләрдә генә була дияргә ашыкмагыз. Лаеш районының «Боровое» дача кооперативында яшәүче кайберәүләр тиздән шушы хәлне үз җилкәләрендә татып карарга мөмкин. Әле 5-6 ел элек салынган өр-яңа  18 йортның язмышы кыл өстендә. Ә аларның хуҗалары, закон сагындагыларның бу йортларны сүттерәчәген уйлап, йөрәк өянәгеннән егыла башлаган... Узган ел территориягә янәдән министрлык һәм Лаеш районы прокуратурасы килеп, кешеләрнең тиешле чикләрдән 32 сутый җирдән читкә чыгуларын раслаган. Гадәттә, тәҗрибәле журналистлар мондый проблемаларны читтә калдырмый. Шуны истә тотып, Айгөл Закирова да «Боровое» кооперативының җитәкчесе Светлана Әхмәдиева белән очрашкан, йорт хуҗалары белән аралашкан, статистик мәгълүматлар белән кызыксынган.

Гадәттә журналист тикшерүгә алынган вакытта, беренче план төзелә. Ул мәгълүмат туплау һәм эшкәртү, чыганаклар белән эшләү, текст язудан гыйбәрәт. Тикшерү планы ул кушкан сорауларга җавап алу һәм көтелгән нәтиҗәгә ирешү өчен үтәргә кирәк булган бурычларны колачлый. Айгөл Закированың материалында бу эш

планы ачык күренә, материалда да эзлеклелек сизелә.

Әлеге тикшерелгән язмада Айгөл Закирова «Боровое» дача кооперативына барган, кооператив рәисе Светлана Әхмәдиева, йорт хуҗасы Мария Ильина һәм башка зыян күрүчеләр белән әңгәмәләр оештырган. Икенче эш – шаһитларны табу. Автор бу пунктны тулысы белән үтәгән. Бу проблема хакында шактый күп мәгълүмат чаралары язды. Шуңа да язма бай һәм эчтәлекле булсын өчен нигез бар. Авторның тикшерү эшендә аның бу тема хакында әйбәт белүе, мәгълүмати нигезе булуы сизелә. Ул проблемага объектив карый белгән.

Материалның уңай яклары белән беррәттән, кытыршы яклары да бихисап. Бер яктан автор мөһим проблема хакында язса, икенче яктан кайбер урында укучыларны шиккә төшерә. Мәсәлән: «Дача кооперативында яшәүчеләр, нindидер афера, мошенниклар корбаннары булмадык микән дип шикләнә...», «Экологик экспертизалар уздырдык, кешеләр йортларын рәсмиләштерелгәч, бу документлар министрлык тарафыннан расланды...», «Күптән түгел Боровоега тагын бер мәртәбә прокуратура килгән...». Авторның бу юллары шик тудыра. Әлбәттә, бәлки ул документлар белән дә эшләгәндер, кирәк очракта суд эшләре өчен материалы да бардыр, ләкин бу җөмләләр расланмаган. Аларны дәлилләүче протокол документлары булганлыгын материалда күрсәтү зарури. Алай булмаган очракта, дәлилсез фаразлар шик тудыра һәм халык гайбәтен сатуга гына кайтып кала.

Айгөл Закирова проблеманың чишү юлларын эзләгән һәм шундый нәтиҗәләргә килгән. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, газета битләрендә бу хәлне күтәргән материал басылу ул бу проблеманы чишүгә бер адым. «Бу проблема уңаеннан халык Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов исеменә хат та юллаган.. «Рөстәм Нургалиевич – яхшы күңелле кеше. Ул беркайчан да халыкның проблемаларына битараф булмады.Ул аңлаучан, хәлгә керә белә. Безне урамдагы сукбайлар хәленә калудан коткара ала».

Автор проблеманы халыкка күрсәтә, анализлый. Чишелеш юлларына килсәк, бу проблемага битараф калмыйча материал әзерли. Һәм зыян күргән халыкның, яклау эзләп, президентка мөрәҗәгатен күрсәтә. Айгөл Закирова язмасында халыкның фикерен һәм вакыйгалар барышын санап чыга.

Гомумән, «Журналист өйрәнә, укучыларыбыз хөкем итә»

дигән рубрикадагы язмаларны көтеп алучылар күп. ««Кышны катып үлмичә чыгуыбызга сөенәм», – Зәйдә газга кем хуҗа» («Безнең гәҗит», 2018 ел, 7 март); «Сабада түрәләр үз эшен штраф сугып халыктан эшләтә» («Безнең гәҗит», 2018 ел, 20 июнь); «Кукмарада иске йорттан күченүчеләргә «эт оясы» биргәннәр» («Безнең гәҗит», 2017 ел, 13 дек.,); «Улым агулар дип куркып яшим» («Безнең гәҗит», 2018 ел, 7 февр.,); «Көнчелекме, чарасызлыкмы: Җәлил бистәсе халкы Сарман районнан аерылып чыгарга җыена» («Безнең гәҗит», 2017 ел, 22 ноябрь,); «Лаештагы авылны инвестор бозау үләксәсенә күмгән» («Безнең гәҗит», 2019 ел, 3 апр.,); «Зәйдәге кабан дуңгызлары кешеләргә дә һөҗүм итә башламасмы?» («Безнең гәҗит», 2018, 21 ноябрь,); «Актанышта «Безнең гәҗит» газетасын ришвәткә сыер алуда гаеплиләр» («Безнең гәҗит», 2018, 14 март) кебек язмаларда журналистның төрле темаларга тикшерүләр үткәрүе күренә.

Араларында төрле дәрәҗәдә язылган һәм өйрәнгән язмалар бар. Әмма һәрбер язмада журналист тикшерүенең бөтен шартларына туры китереп эшләргә тырышулары, анализ, чишелеш юллары күрсәтелүе ачык күренә. Сүз дә юк, бер язмада, бер өйрәнеп язып чыгуда гына журналист бөтен проблеманы хәл итә алмый. Әмма аның килүен, аның теге яки бу проблеманы күтәрүен бөтен кеше беләчәк. Язма бит ташка басылган кебек матбугатта басылып чыга, мәгълүмат газета битендә рaслана. Журналистның текст барышында дөреслеккә чыгу, гаделлек эзләү, сорауларга җавап табуга нигезләнгән һәм шуның өчен кулланган эш методлары аеручa сизелә. Ул теге яки бу белгечтән комментарий ала, аларны күзәтә (кайчак яшерен күзәтү дә алып бара), аралаша-әңгәмә кора, интервью үткәрә, ике якның да фикерләрен тыңлый. Күп вакыт журналист тикшерүе язмаларын укыганнан соң, авторларның куркусызлыгы, кыюлыгы һәм батырлыгы да сокландыра. Әңгәмәдәшнең кайчак шулкадәр ике яклы фикер йөртүе аптырашта да калдыра. Газета битләреннән без әзер интервьюны укыйбыз. Әмма анда да журналистка дөрес карар кабул итүнең никадәр кыенлыгын күрәбез. «Лаештагы авылны инвестор бозау үләксәсенә күмгән» («Безнең гәҗит», 2019 ел, 3 апр.,) язмасы да шундый материалларның берсе. А.Закированың фикерләре аша укучылар дөреслек табарга тырыша. Әңгәмә барышында ул героен дөреслеккә чыгара да алмый. Әмма моның шулай икәнлеген язманы

укыган кеше сизә. Берничә мисал. *«Инвестор Закиров бер уңайдан минем исем-фамилияне, кайда эшләвемне дә язып алды. Әле сүз уңаеннан турысын бәреп, «Татмедиага буйсынасызмы сез?» – дип тә сорады. Аның ни сәбәпле соравы язмасам да аңлашыладыр. «Татмедиа»ныкы булсак, бу язма чыкмый да калыр иде, мәсәлән. Гомумән, бик кызык кеше булып чыкты инвестор. Бөтен сорауларга да җавабы әзер аның. Ләкин ул җавапларның дөреслеккә туры килүе генә бик шикле...*

*– Гомәр Фәритович, сез минем сорауларга җавап бирмисез. Ни өчен сезнең фермадагы сыер тизәкләре елгага ага?*

*– Анда бернәрсә дә беркая да акмый.*

*– Ник, акканын үз күзләрем белән күрдем бит. Видеога да төшердем.*

*– Әгәр сез күргән булсагыз – анда хәзерге вакытта тизәкне чистарту эшләре бара, экскаваторлар эшли, сизмәгән булсагыз!*

*– Әйе, чистартканнары бер дә сизелмәгән иде шул...*

*– Сизелми инде, сез бит начар әйбер генә күрәсез. Сез онытмагыз, минем дә юридик белемем бар! Мин сезнең газетаны яздырачакмын, укыячакмын, «не дай бог» анда дөреслеккә туры килмәгән мәгълүмат була! Хезмәт хакларым түләнгән, үләксәләр ятуы турында мин белми идем, һәм бөтенләй халык миннән зарланганчы, шуны онытмасын – мин монда 2,5 миллион сум салым түлим һәм объектлар төзелеше вакытында да, иганәчелек ярдәме дә күрсәттем!*

*Инвесторның үзен бик иркен тотып сөйләшүе гаҗәпләндерде. Берәү булса, авыл халкыннан гафу үтенер, бөтен әйберне тәртипкә салырмын дип, башын аска ияр, оялыр иде»*.

Ике арадагы әңгәмәнең бер өлеше бу. Максатыбыз – журналистның фикер йөртү үзенчәлеген күрсәтү. Журналист тикшерүен үткәрүче журналист үзен гаепләргә алынучы әңгәмәдәш белән дә бер дәрәҗәдә торып сөйләшергә тиеш. Әңгәмә кору барышында психологик киртәләрне җимерү, төрле характерлы кешеләрне сөйләштерү, кайчак адекват булмаган кешеләр белән аралашуның никадәр җаваплы  эш икәнлеген аңларга кирәк.

Журналистны күп вакыт язманың нәтиҗәсе юклыкта да гаепләп күрсәтергә мөмкиннәр. Кайчак тикшерү язмасының басылып чыгуы үзе үк нәтиҗә булып тора. Әңгәмә барышында инвестор да газетада басылып чыгачак язмадан куркып торуы

күренә.

Әлеге язманың укучы нәтиҗә итеп кабул итәргә гадәтләнгән соңгы абзацны укыйк. *«Авыл халкы да, җирлек башлыгы да бер үк сүз сөйли: Гомәр Закировка булган ышанычыбызны югалттык, диләр. Шәһәрдән килгән егет булгач, инвестор Закиров, бәлки, белеп бетермидер. Авыл халкының шундый гадәте бар – син аңа бер яхшылык эшлә, ул сиңа меңе белән кайтарыр. Шул ук вакытта, бер мәртәбә күңеле кайта икән, кабат ышанычны яулап алу мөмкин түгел диярлек. Ничә миллион сум салым түләвегез белән мактанмагыз – шәхси эшмәкәрнең бөтенесе дә түли ул салымны. Аның кереме авыл халкына түгел – сезнең кесәгә. Ә шулай да эшләгән урыныгыздагы халыкны хөрмәт итәргә һәм чисталык сакларга – сез бурычлы гына түгел, закон нигезендә тиеш тә!!! Айгөл Закирова, Казан–Лаеш–Казан».*

Кайбер журналист тикшерүе язмалары чыкканнан соң да А.Закировага төрле бәла ягучылар табыла. Мәсәлән, «Актаныштa «Безнең гәҗит» газетасын ришвәткә сыер алуда гаеплиләр» («Безнең гәҗит», 2018, 14 март) дигән язмада район турында бер язып киткән журналистны, дөрес язмаганлыкта гаепләп, интернет аша хат юллыйлар. Сыер алуда гаеплиләр. Журналист: *«Сыер алуым турында «Матбугат.ру» сайтында да берәү язып чыккан иде, бу кеше сез түгелме икән дип шикләнәбез, Тимерхан әфәнде. Кешегә нахак бәла ягу килешми, андыйларга закон кырыс. Җинаять эшләре ачыла башлый, мәхкәмәләргә чакырталар, шуңа күрә киләчәктә уйлабрак сөйләшергә тырышыгыз. Нишлим мин ул сыер белән. Балконыма алып чыгып асрыйммы? Телегез кычыта икән, хет лөгатькә туры килә торганрак гайбәт сөйләгез инде...»,* – яза А.Закирова.

Журналист тикшерү материалына кабат кайтып язылган язмага кабат журналист тикшерүе үткәрелә. Монда журналист үзен дә якларга тиеш була. Текстта белгеч тарафыннан да аңлатма бирелә. Юридик экспертиза үткәрелә. *«Кукмара районы прокуроры Шакиров Ришат Наил улы яла ягуга кагылышлы җәза төрләре турында аңлатты: «Яла ягу – РФ Җинаять Кодексының 128.1 маддәсе. Бу – бер кешенең, ялган икәнен белә торып, икенче кеше хакында аның репутациясен бозардай хәбәрләр таратуы дигән сүз. Мәсәлән, бу очракта, әгәр дә Тимерхан Заманов сезнең сыер алмаганыгызны белә торып, «Ришвәткә сыер алгансың», – дисә, бу*

*яла ягу, әгәр дә кешенең шушындый төр җинаять кылуы ачыкланса, иң йомшак җәза төре – 500 мең сум күләмендә штраф яки 160 сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләтү. Әгәр дә кеше синең исемеңне массакүләм мәгълүмат чаралары, форумнар аша пычратса, 1 млн сумга кадәр штраф түләячәк».* Менә шундый журналист-тикшерүченең эшен ачып сала торган язма.

***«Акчарлак» газетасындагы язмаларны өйрәнү.*** «Журналист тикшерүе» рубрикасындагы материалларны карап үтәрбез. Журналист Эльмира Флүн «Директорга кем каршы?» («Акчарлак», 2014, 5 июнь) язмасын менә нәрсә дип башлый: *«Игътибар итсәгез, «Акчарлак»та мин еш кына хат язучыларга рәхмәт әйтәм. Хатлар бүлеген җитәкләгәнгә генә түгел ул. Каләм тибрәтүчеләрне хөрмәт итәм чөнки. Хатларда төрле язмыш, төрле тормыш. Кайберләрен барлык редакция хезмәткәрләре белән йөрәк аша уздырып укыйбыз да, газетага тәкъдим итәбез. Көлдерә торганнары да очрый. Ярдәм сорап, үзләренә чакырып язучылар гына, гадәттә, исем-фамилияләрен калдыра, йә булмаса, ялган исем язалар. Ләкин шунысы аяныч, без моны соңыннан, командировкаларга баргач кына аңлыйбыз».* Автор текстны дәвам итеп, язмасының беренче бүлеген үк «Зарлы хат» дип атый. Димәк, биредә сүз, нигездә, укучы хаты турында барачак. *«Алексеевск районының Кыр Шонталысы авылыннан да шундыйрак хат килеп төште. Хат ахырында дүрт фамилия! Әмма инициаллары күрсәтелмәгән, кул да куелмаган. Монысы сәерерәк тоелды, әлбәттә. Хат бик озын, шуңа күрә аның кыскартылган вариантын тәкъдим итәм. «Кадерле редакция! Без Алексеевск районы Кыр Шунталы (авыл исеме дөрес язылмаган. – Э.Ф.) мәктәбеннән. Сезгә үзебезнең зарыбызны җиткерәбез», – дип башланып китә текст. Аннан авторның шул авылга баруы хакында, авылны, кешеләрне, мәктәп коллективын күзәтүен укыйбыз. Шулай ук журналист хатны язучыларны эзләп карый, аларны таба гына алмый. Кеше фамилияләрен теркәп җибәрүчеләрнең кемнәр булуын да ачыклап карарга тырыша. Азакта «Шулай да хатны кем язган соң? Ни өчен журналисттан юләр ясамакчы булган? «Исемнәребезне атамагыз» дигәч, бәлки мине эшемне ярты юлда калдырып китәр дип уйлагандыр? Хат авторларының ялган икәнен белмәсәм, мин, чыннан да, моның белән генә туктамый, тикшерүне дәвам итәр, мәгариф бүлегенә дә барыр идем, әлбәттә. ...Инде шуны да әйтим:*

*әгәр теләсәк, без хат авторының кемлеген дә ачыклый алыр идек. Конверт тышында адрес кулдан язылган... Пычранасы килмәде. Ләкин киләчәктә башкача эш итәргә туры килер, мөгаен. Безнең халыкның шулай түбәнлеккә төшүе күңелне борчый башлады», –* дип тәмамлый Эльмира Флүн. Азакта күпчелек текстлардагы кебек барып язылган урын да күрсәтелгән: Казан-Алексеевск-Казан.

Әлеге төр хат эзеннән язылган журналист тикшерүләре берникадәр электән килгән хат эзеннән рубрикасын хәтерләтә. Гадәти хат эзеннән язылган мәкаләдән аермасы сизелми дә кебек. Әмма журналистның язманың тикшерү өчен язылганлыгына да басым ясавы бу очракта аклый, ул тикшерү язмасының барлык этапларын үтә. Бөтен төр алымнарны куллана автор. Язмада чишелеш юлларын да күрсәтә. Эльмира Флүннең журналист тикшерүе материалларында «Соңгы сүз» дип аталган бүлекчә бар. Ул аның бөтен материалларында да кабатлана диярлек. Бу үзенә күрә журналистның теге яки бу мәсьәләгә мөнәсәбәте дигән сүз. Автор үзенең бу материалда соңгы фикерен өздереп әйтә, нәтиҗә ясый. Бу журналистның үзенә күрә бер фишкасы булып тора.

«Зәйтүнә апаның фатиры кая киткән?» язмасының азагында да «Соңгы сүз» бар. *«Менә шундый кызганыч тарих. Зәйтүнә апа миннән ярдәм көтә. Әмма акчасының кайда икәнен дә белми. Югыйсә, үзе: «Социаль хезмәткәр белән банкка салдык, мин аны өйгә алып кайтмадым», – дигән иде. Банктан кем алган аны? Кулында бер документ, бер кәгазь юк. Венера исә: «Мин аның акчасының кайда икәнен каян белим?!» – дип утыра. Шуңа күрә барлык өлкән яшьтәге, ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә мөрәҗәгать итәм: сак булсагыз, фатир, акча эшләрен үзегез генә ерып чыга алмасагыз, башкалардан ярдәм сорасагыз иде. Эльмира Флүн. Казан-Сарман-Казан».*

Бу язмада фатирның кая киткәне, кем гаепле, ни өчен Зәйтүнә апаның мондый хәлдә калуы һәм башка сораулар куелып, автор һәр соравына җавап табарга тырыша. Мәкалә биш өлештән тора: 1) Кереш өлеш, 2) Зәйтүнә апа фикере, 3) Хөснуллиннар, 4) Венера апа ни сөйли? 5) Соңгы сүз. Кереш өлештә – Э.Флүн укучыны алда булачак вакыйга белән таныштыра. Шушында ук төп геройның кайда, нинди халәттә булуын тасвирлап бирә. «Инвалид коляскасында утырган әбине төп башына утырту өчен әллә ни акыл кирәк түгелдер. Сарман районының Яңа Әхмәт авылында яшәүче

Зәйтүнә Гурьянова юлында изге кешеләр очрамаса, бүген картлар йортында, я булмаса инвалидлар өчен интернатта гомер кичерер иде. Туганнары фатирсыз калдыргач та, чит-ятлар үзләренә алып кайткан аны...». Икенче өлештә – Зәйтүнә апа фикере – төп геройның уй-фикерләре, хисләре, ничек фатирлы булуы һәм аннан колак кагуы, кыска гына бу турыда мәгълүмат бирелә.

Өченче өлештә – Хөснуллиннар гаиләсе хакында сүз бара. Зәйтүнә апаны караучы гаилә турында, ничек аны алып кайтулары һәм аның өчен җан атулары укучыга җиткерелә.

Дүртенче өлештә – «Венера апа ни сөйли?». Таякның ике башы булган сыман, бу вакыйгада ике төрле фикер булуы күренә. Ике якның фикерен дә тыңлап, бизмәннәрне тигезләргә тырыша Эльмира Флүн. Бишенче өлештә – соңгы сүз. Монда автор безне вакыйга эченә алып кергән сыман, шулай бераз кисәтеп, киңәшен бирә, хәтта сораулар яудырып вакыйганы тәмамлый.

Күренгәнчә, язма күләмле. Сорау-җавап, уй-фикер белән уралып бара. Моны берникадәр детектив әсәр дип тә атарга була. Автор монда вакыйганы күзәтеп, теркәп укучыга җиткерә. Журналист тикшерүе һәрвакыт шәхси характерда була. Э.Флүн дә үзенә хас булган адымнар белән күзәткән хәлләрдән иң мөһим һәм кирәкле детальләрне сайлап ала. Ул үзе дә бу хәлләрдә хис-кичерешләрен белдермичә кала алмый. Мәсәлән: «...шулкадәр дулкынланып, әрнеп сөйләде ки Венера, үзем дә аптырап киттем», – дип яза Эльмира.

Бу мәкаләдә журналист аерым позициядә тора, аны белдерергә тырыша. Тикшерүдә ул төрле тезислар, аргументлар, фикерләр белән бүлешә. Психологик дәлилләр вакыйганың көчен тагы да арттыру өчен кулланылган. Мәсәлән: «Венераның каенанасы кызганып, яшәп торырга фатирын биргән аңа», «Туйсак та туярбыз икән без аннан! Бөтен тынычлыгыбызны алды, ничек кенә мыскыл итми!», «Каян белим мин аның акчасын! Теләсә кая китеп олаксын!», «Мин имза куя алмыйм, үзләре куйган аны. Венераларны судка да җиреп карадык, суд аларны яклап карар чыгарды», «Нинди суд булсын? Барлык документлар тәртиптә бит, Зәйтүнә апаның башы киткән!».

Язманы укыганда, дөресрәге «Венера ни сөйли?» дигән бүлеккә кадәр килеп туган проблема инде шуның белән хәл ителгән сыман тоела. Чөнки вакыйга Зәйтүнәнең үз урынын, гаиләсен табуы

белән тәмамланыр кебек иде. Венерага карата башта бер фикердә буласың, аннан аның фикерен ишеткәч – икеләнә башлыйсың. Эльмира монда да үз фикерен укучыга әйтеп сала. Венераның әйткән сүзеннән аптыравын, гаҗәпләнүен яшерми.

Ничек кенә журналистка авыр булмасын, ул хисләргә бирелергә, бер якка гына өстенлек биреп, икенче якка битараф калырга тиеш түгел. Ул алтын уртаклыкны табып, укучыга килеп туган проблеманы ачып сала алса, язма уңышлы санала. Автор язмасында Зәйтүнәнең үткән тормышын, бүгенгесен кыска һәм аңлаешлы итеп, Хөснуллиннарның гаиләсе, нинди гаилә, ничек яшәүләрен, алар гаиләсе турында фикерләрне җиткерә. Журналист бу уңайдан үз фикерен дә әйтә: «Дөрес, Яңа Әлмәттә алар турында төрле фикер әйтәләр, берләре күккә чөеп мактый, икенчеләре «шул рәвешле акча эшлиләр ди». Әмма берсенең дә «шул рәвешле акча эшләргә» кулыннан килми. Теләкләре дә юк! Булдыксызлар гына кешедән шулай көнләшә һәм аның изгелеген аңламый һәм күрә белми, минемчә).

Э.Флүн күбрәк интервью методын куллана, бу аның язмасында да турыдан-туры чагыла. Ул геройларга риторик сораулар бирә. Ике якны «тигезләп», фикерләрен тыңлап, ничек тә проблеманы чишү юлын табарга тырышып, барысы белән дә әңгәмә кора. Текстта документлар белән эшләү бик сизелми. Э.Флүн бары геройларның сөйләве белән генә нинди документлар, кайда имза куелганын, суд булганын әйтеп уза. Үзе тикшерми, тикшерсә, бәлки «Венера апаның «нинди суд булсын?» дигән соравы, укучыны берникадәр аптыраушта калдырмас иде. Бу сорау чишелмичә, шулай эленеп кала. Документ эшен тикшергән булса, укучы өчен генә түгел, ә бәлки тулы бер хәлләргә йогынты ясарлык та җавап табылган булыр иде.

Тикшерү язмасы беркадәр криминаль вакыйганы язуны да хәтерләтә. Никадәр кырыслык һәм төгәллек таләп ителгән тема булса да, автор укучыга тел-бизәкләү чаралары аша да тәэсир итә. Укучы моны фактларны раслау дип кенә кабул итми, ә вакыйганы йөрәге аша үткәрә. Автор куйган максатларның да берсе бу. Һәрбер тикшерүнең нигезендә гыйбрәт тә ята.

2019 елның 4 апрелендә «Журналист тикшерүе» рубрикасында чыккан язмаларның берсе «Сакал сыпырып, әппәр итеп утырмадым» дип атала. Эльмира Флүн Биектау районы Чыпчык авылыннан Гөлнара ханымның шалтыратуыннан соң юлга

кузгала. Сүз мәчет һәм муллаларга кагылышлы булганга, автор сүз башында берникадәр дини мәсьәләләрне гомумиләштереп үтә. *«Соңгы вакытта мәчетләр белән дин әһелләре арасында туктаусыз аңлашылмаучанлыклар килеп чыга һәм моның сәбәпләре байтак. Беренчедән, диннән ерак торган кешеләр, ягъни денсезләр, мәчет проблемаларын аңлап бетерә алмый, икенчедән, дин белән дини йолаларны бутый, өченчедән, чыннан да кайбер муллалар үз сәясәтләре белән аңлы яки аңсыз рәвештә халыкка һөҗүм ясый һәм моны үзләренчә аңлатып: «Миңа мәчетне һәм зиратны карап торырга кирәк, мәчет акчага мохтаҗ», – диләр. Аннан, диндә сектага охшаш башка төрле агымнарны алга сөрүчеләр барлыкка килде»,* – дип башлый ул үзенең журналист тикшерүе язмасын.

Журналистка тикшерү эшләре уздыру, шалтыратып әйтелгән сүзләрнең дөреслеген тикшерү өчен районга кайтып ачыкларга кирәк була. Ул Биектау районы Чыпчык авылына кайтып, авыл мулласын да, мәчет хәлләрен дә күреп килә. Кешеләр белән сөйләшә. Үзе булган бөтен хәлләрне анализлап чыга. Азакта журналист менә нинди нәтиҗәләр ясый. *«Гөлнара, мин сезне авылыгызның мәчет тарихы, аның яшәеше белән таныштырдым. Һәм Рәшит хәзрәтнең аңлатмасын тыңладым. ТР Диния нәзарәте белән элемтәгә кердем. Әгәр дә сез үз фикерегездә каласыз икән, районыгызның Мөхтәсибәтенә – Тәлгать хәзрәткә барып, барысын да бәян итә аласыз. Аннан регион буенча Габделхәмит казыйга мөрәҗәгать итәргә була. Казый ике якны да тыңлаячак һәм хөкем чыгарачак. Әмма мин эшләр моңа кадәр барып җитмәс, Рәшит хәзрәт (язма аша – Г.Р.) сорауларыгызга җавап биргәндер, ачыклык керткәндер дип ышанып калам».*

Күп вакыт нәрсәнедер аңлап бетермәү аркасында, ике кеше арасындагы мөнәсәбәтләр катлауланып китеп, журналистның тикшерү үткәрүен таләп итә башлыйлар. Әлеге тикшерү эше язмасы да шундыйлардан. Журналист килеп, аңлату эшләре алып бармыйча, бу мәсьәләнең хәл ителмәве бар. Гомумән, һәрбер язмасында журналист Э.Флүннең тырышлыгын һәм җаваплылыгын да билгеләп үтәргә кирәк.

«Акчарлак» газетасында шулай социаль мәсьәләләрдән тыш, гаилә эчендә хәлләр, ир белән хатын мөнәсәбәтен яктырткан журналист тикшерүләре дә үткәрелә. Күбесендә язма авторлары

проблеманы хәл итү юлларын күрсәтеп кенә калмый, теге яки бу белгечтән аңлатма, киңәш-табыш бирәләр. Газетадагы күп кенә язмаларны басманың сайтыннан табып укырга була.

## 3. Тикшерү материалларында автор йөзе

Журналист тикшерүен башка жанрлардан аерып торган ягы – материалларда авторның да катнашуы, ягъни башка геройлар белән беррәттән, материалда сурәтләнгән вакыйгаларда авторның да булуы. Тикшерүнең ничек баруы, кайчан һәм нәрсәдән башлануы, тикшерү барышында юлыккан кыенлыклар, киртәләр һәм геройларының эмоцияләрен язып, журналист тикшерү процессын укучы өчен ачык һәм тәэсирле ясый.

Татар матбугатында тикшерү белән шөгыльләнүче журналистларның үзләренә генә хас сыйфатлары бар. Мәсәлән, Искәндәр Сиражи тикшерүләре белән Рәмис Латыйповның тикшерүләрен берничек тә бутап булмый. Илфат Фәйзрахманов, Эльвира Фатыйхова, Эльмира Флүн, Эльмира Сәлахова, Чулпан Шакирова, Лилия Заһидуллина, Фәнзилә Мостафина, Айгөл Закироваларның язмалары да шулай юк бер-берсеннән аерылып тора, чөнки бу авторларның һәркайсысының үзенә генә хас шәхси стиле бар. Шәхси «мин»нең тикшерүдә ничек чагылуына карап, авторның иҗади йөзе билгеләнә.

Журналист теге яки бу мәсьәлә буенча аерым позициядә торып, аны белдерергә тырыша. Бу нәрсәдә чагыла соң? Тикшерүдә мәсьәләсенә укучы игътибарын җәлеп итәр өчен ул төрле тезислар, аргументлар белән бүлешә. Бу очракта төрле психологик элементлар авторга укучысына тәэсир көчен арттыру өчен ярдәмгә килә.

Рәмис Латыйповка тукталсак (бүген ул башка төрле планда эш алып бара. «Татар-информ» мәгълүмат үзәгенең татар бүлеген җитәкли), авторның тематик планда үзенчәлекле эшләве күренә. Аның язмаларында иң еш күтәргән тема – авыл хуҗалыгындагы аянычлы хәлләр һәм авыл кешеләренең көннән-көн хәерчеләнә баруы. Аның тикшерүләре бер яклы гына түгел, моңа аның язмаларын анализлаганда инанасың. Латыйпов, тикшерүне һәръяклап үткәреп, иң беренче чиратта халык мәнфәгатьләрен яклый. Аның тикшерүләренең нәтиҗәлелеге – халыкны борчыган проблемаларны тирәнтен өйрәнеп, киң масса укучылар хөкеменә

чыгаруда.

Һәр тикшерүгә керешер алдыннан ул теге яки бу мәсьәләнең тирән тарихына күз салып, рәсми чыганакларда әлеге мәсьәләгә карата нинди фикерләр барлыгын укучы игътибарына тәкъдим итә. Беренчедән, бу журналистның тикшерүгә әзерлекле булуын сөйләсә, икенчедән, укучыга проблеманың асылына төшенергә ярдәм итә. «Ирек мәйданы»нда 2009 елның 13 санында чыккан «Ямаулы Ямаширмә» язмасында журналист-тикшерүче авыл хуҗалыгына бирелгән ташламалы кредитларның эшләү принцибын тикшергән. Язмадан күренгәнчә, монда рәсми мәгълүматлар буенча 20 фермер саналса, тикшерү барышында чынлыкта 4-5 кешенең генә фермер хуҗалыгын алып барганлыгы ачыклана.

Авыл хуҗалыгы продукцияләренә бәянең түбән булуының сәбәпләрен ачыклау белән беррәттән, Р.Латыйпов ташламалы кредит алганда, гади халыкның төрле-төрле кыенлыкларга, шул исәптән, бюрократик нормаларга туры килгән кәгазь боткасына юлыгуын ачык мисаллар аша күрсәтә. Журналист Биектау районының Ямаширмә авылындагы фермерлар белән очрашып сөйләшә. Бөтен мәгълүматны авылдагы фермерлардан ала, аларның хуҗалыгы белән шәхсән таныша. «Кемгә кредит кирәк?» бүлегендә Р.Латыйпов документлар белән эшли. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында булып, рәсми статистика белән таныша һәм терлек саны (әлбәттә, кайбер очракларда дип язарга кирәктер) кәгазьдә генә арткан булган, дигән нәтиҗә ясый. Әлбәттә, журналистка бу очракта аеруча игътибарлы булу сорала, чөнки бер генә хата да аңлашылмаучылыкка китерергә мөмкин.

Тикшерү бер яклы гына түгел, чөнки тикшерү барышында Латыйпов фермерлар, авыл җирлеге башлыгы, югары түрәләр фикере белән дә таныша. Шул исәптән, күтәрелгән проблемага автор тарафыннан төрле яклап якын килү сизелә. Соңыннан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов белән бу темага әңгәмә кора. Министр фермер хуҗалыкларындагы хәлләрне бөтенләй башкача тасвирлый. Шулай итеп, Р.Латыйпов рәсми белдерүләрдән аермалы буларак, укучыларга ташламалы кредит алу һәм кулланунын авыл кешеләренә файдасы аз икәнен күрсәтә.

Мәгълүмат туплау – журналист-тикшерүче эшчәнлегендә гаять катлаулы, тик шул ук вакытта аның иҗат йөзенең үзенчәлеген ачарга мөмкинлек бирә торган этап. Рәмис Латыйповның

язмаларыннан күренгәнчә, тикшерү барышында аңа бик күп кешеләр белән аралашырга, әңгәмә корырга туры килә. Чөнки бары туры һәм дәлилләргә таянып язылган язма гына укучылар өчен кызыклы булачак. Ә моңа ирешү өчен әңгәмәдәшеңнең күңеленә үтеп керүне, аңардан мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат алуны максат итеп кую кирәк. Ә кешенең күңеленә йогынтыны журналист аның психологик үзенчәлекләрен ачыклаганда гына ирешә ала. Рәмис Латыйпов бу нисбәттән нечкә психолог. Бер очрашуда ул «Халык белән сөйләшер алдыннан аларны мораль яктан әзерлим, ышанычын яуларга тырышам, чөнки мөһим мәгълүматны алыр өчен һәрчак эшлекле аралашу гына җитми», – дип белдергән иде. Аралашуның башка төрләрен дә куллануны кирәк дип саный журналист-тикшерүче. Аның материалларына җанлы һәм ирекле диалоглар хас. Ул импровизацияләнгән әңгәмәләр оештыру остасы. Шул рәвешле ул эмоциональ яктан бай булган мәгълүмат алуга ирешә. Эмоцияләр, билгеле булганча, шәхеснең аерым бер проблемага карата мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итә. Әңгәмәдәшләре белән рәсми зат буларак кына кызыксынып калмыйча, аларны шәхес буларак та ачуга ирешер өчен, үзе дә шәхси яктан ачылырга тырышу – бу журналистның төп үзенчәлеге дип санап була. Шунысы әһәмиятле, тикшерү объекты нинди характерда булганлыктан, автор, урысча әйткәндә, «расклад» куллана, ягъни гади укучыга аңлашылып бетмәгән төшенчәләрне һәм законнан өземтәләрне китереп, язма телен гадиләштерә. Бу укучыларның мәсьәләгә төшенүе өчен мөһим, дип белдерә автор.

Тагын бер үзенчәлеккә игътибар итәргә кирәк – журналистның үткен, сатирик теле, образлы фикер йөртә алуы. Язмаларының баш исемнәре дә, бүлекчәләренең исемнәре дә моңа дәлил булып тора. Мәсәлән: «Казна хисабына туй, каз җитмәсә, күркә суй», «Куй симерсә – койрыгын күтәрә, кеше симерсә – борынын күтәрә», «Түрәнең сүзе – сүз, ни әйтсә, шул түз», «Кырык хуҗага бер ишәк», «Берәү эшли хисап, икәү яза хисап, ун начальник шул хисаптан чыгаралар сыйфат», «Берәү карый тамаша, берәү урлый алаша», «Түбәнең асты тайгак, түрәнеке – каймак» һ.б. Чынлап та, Р.Латыйповның язмаларында баш исем һәм бүлекчәләр исеме текстның иң мөһим компоненты булып хезмәт итә һәм, кагыйдә буларак, хисси тәэсир итү функциясен башкара. Р.Латыйповның тикшеренүләрендә баш исемнең тескты

оештыруда актив катнашуын әйттек. Мисалга, «Алып мәргән синдромы» язмасын карыйк. Тикшеренү конкрет фактларга, рәсми документларга, ягъни мантыйкый дәлилләү чараларына бай булса да, анда образлы тел чаралары актив кулланылган. Батулланың «Алып Мәргән» әкиятендә бер кызыклы күренеш сурәтләнә. Алып Мәргән халыкның канын суырган аждаһаны җиңеп, аны куып җибәрә. Ә патша Алып Мәргәнне аждаһа урынына гаскәр башлыгы итеп куя. «Яңа влач»ка килгән Алып Мәргән халыкны тагын да ныграк изә башлый, чөнки гади халыктан чыккан кеше буларак, ул инде ничек таларга икәнлеген яхшырак белә. Балык Бистәсе районында, яңа җитәкчелек килгәч, халыкның хәле тагы да мөшкелләнүен автор әлеге күренеш аша бәян итә. Бу алым язманы тагы да кызыклы итә. Шулай итеп, мантыйкый дәлилләрнең психологик дәлилләр эченә «төреп» бирелүе – Рәмис Латыйповның тикшеренүләрендәге текстны оештырудагы, автор йөзен билгеләүче үзенчәлекләренең тагы берсе.

Журналист-тикшерүче Эльвира Фатыйховага да үзенең материаллары аша бәхәсле ситуацияләрне хәл итәргә туры килә. Аның да язмалары шулай ук кызыклы. Эльвира, Рәмис Латыйповтан аермалы буларак, күп кенә материаллары башында әлеге тикшерүенә үткәрегә этәргән фактларга тәгаенләп тукталуны кирәк дип таба. Баштан ук шуны искәртеп үтү мөһим: әгәр Латыйпов еш кына сәяси калыптагы мәсьәләргә караган проблемаларны чишсә, Эльвира исә күбрәк социаль темага карган тикшерүләргә алына. Шуңа күрә Латыйповның тикшерүләрендә Татарстан, Россия күләмендәге күп кенә законнардан өзекләр китерелә. Ә Эльвира еш кына редакциягә килгән хат эзеннән йөри. Автор аны укучылары хозурына еш кына язма башында тәкъдим итә.

Эльвира Фатыйхованың 2011 елның 31 санында чыккан «Мактауга лаек директор» язмасын Арча районының Курса Почмак авылының мәгариф учреждениесендә барган башбаштакларга багышланган. Проблеманың чишмә башы 2010 елда уздырылган «Фермалы мәктәп» исеме астында чыккан журналист тикшерүенә барып тоташа. Журналистка Курса Почмак авылы мәктәбе укучылары ата-аналары тарафыннан язылган хат килеп ирешә: анда мәктәп директорының, ферма мөдире вазыйфасыннан азат ителгәннән соң, директор итеп билгеләнүе; аңа кадәр колхоздан

мотор урлап, ике елга шартлы срок алуы; мәктәп янына иске мунча куеп, дуңгыз асравы һәм тагы әллә нинди «изгелекләре» турында язылган була. Ничек ул тикшерү башлый? Беренчедән, мәсьәләнең асылына төшенер өчен ул мәгариф учреждениесенә үзбелдеклелеге белән үтеп керә. Икенчедән, үзенең журналист булуын белдермичә генә һәр очраган укытучыдан директорга булган мөнәсәбәте турында сораштыра башлый. Өченчедән, өлкән сыйныф укучыларыннан директорга мөнәсәбәтләрен аноним формада яздырып ала. Югарыда санап кителгәннәр этика, тәртип нормаларына туры килмәсә дә, бу очракта ул үзен аклый. Чөнки әгәр дә директор, һәр укытучыны үз кабинетына дәшеп китереп, журналист каршында сорау ала башласа, алар психологик басымга буйсынып, дөреслеккә туры килмәгән мәгълүмат бирер иде. Ә журналистның ирекле әңгәмә коруы тикшерүгә ярдәм иткән.

Журналист килеп киткәннән соң әлеге мәктәптә тикшерү үткәрелә, әмма дә ләкин директор үз урында кала һәм күкрәк билгесе белән дә бүләкләнә. Район мәгариф бүлеге идарәсенең югарыда сөйләнгән вакыйгаларны тиешенчә тикшермәве, шушы фактлар билгеле була торып та, мәктәп директорына күкрәк билгесе тапшырылуы, аның әле дә әлеге вазыйфаны биләве халыкта ризасызлык тудыра. Нәтиҗәдә, журналистка Арча районы мәгариф бүлеге мөдире Рина Бәдриева исеменә әлеге мәсьәлә уңай якка хәл ителмәвен ачыклар өчен, журналист соравы юлларга туры килә. Хаты турында онытмасалар да, татарча юлланган хатка урысча җавап кайтаралар. Фатыйхованың башкалардан аерылып торган үзенчәлеге – ул геройларын аларның сөйләме, журналистка булган мөгаләмәсе аша проблемага мөнәсәбәтләрен күрсәтә. Тикшерүче булмаса, бәлки, ул аңа игътибар да итмәс иде, ләкин бу укучыларга аерым нәтиҗәләр ясарга җирлек бирә. Шундый темага язылган язмалардан мисаллар:

– *«Район мәгариф идарәсе җитәкчесе урынбасары Гүзәл Рәисовна миңа нинди дә булса аңлатма бирүдән баш тартты һәм җитәкченең үзен көтәргә кушты. Көттем. Нибары 4 сәгать тә 40 минут көттем. Шул вакыт эчендә Рәмзилә исемле сәркатип кыздан Министрлар кабинетыннан килгән хатны да сорадым. 6-7 тапкыр сорагач, ул башта шул хатның 1нче бите күчермәсен ясап бирде. Тагын 6-7 тапкыр сорагач кына, ниһаять, икенче битен дә тапты».*

*–«Әлмәт районы мәгариф бүлеге җитәкчесе Нажия Хәйдәрованы көтеп җиткерсәм дә, ул бик үк яхшы кәеф белән әйләнеп кайтмау сәбәпле, әңгәмә уңышлы барып чыкты, дип мактана алмыйм. Аның башы да авырта, җитмәсә, башкарма комитетта киңәшмә буласы ди...»*

*– «Мәгариф бүлеге җитәкчесе Бишмунча мәктәбе буенча конкрет саннар сораткач, телефон трубкасының теге ягыннан: «Шундый мәгълүматны газетага бирәбезмени?» – дигән җавап ишетелде.*

Китерелгән мисаллардан шундый нәтиҗәгә киләбез: журналистның иҗади үзенчәлеген аның язу манерасыннан, мәгълүматны бирүдәге методлардан, темадан, авторның чынбарлыкны ничек кабул итүеннән һәм автор үзенә үзе сайлаган рольгә бәйле. Шуңа таянып, авторның иҗади йөзе барлыкка килә.

***Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр***

Журналист тикшерүе эше белән шөгыльләнгән журналистлар арасында анкета үткәрегез. Сорашу өчен түбәндәге сорауларны кулланырга мөмкин. Аларга үзегезнекеләрне дә өсти аласыз:

1. Практик журналист булып эшләү вакытыгыз?
2. Журналистның хокук һәм бурычларын беләсезме? Нинди хокук һәм бурычларыгызны беләсез?
3. Журналист тикшерүе хокукыннан файдаланып материал язганыгыз бармы?
4. Гадәттән тыш хәлләр зонасында булганыгыз бармы?
5. Тәнкыйди характердагы материал язуны редактор белән килешү таләп ителәме?
6 Урта һәм югары баскычтагы түрәләр белән очрашуны озак дәгъвалап йөргән очраклар булдымы?
7. Язган материалны үзгәртергә яки номердан алырга югарыдан таләп иткәннәре бармы?
8. Критик материал чыкканчы ук яки басылгач куркытканнары бармы?
9. Теге яки бу материал өчен җаваплылыкка тартканнары бармы?
10. Үз хокукларыгызны яклап, суд органнарына мөрәҗәгать иткәнегез булдымы?
11. Журналист эшчәнлегенә кагылышлы соңгы ике елда

чыккан нинди законнарны беләсез?

12. Закон ярдәмендә журналист дәрәҗәсен, абруен күтәреп булуына ышанасызмы?

13. Эшегездә куркыныч янаганы бармы?

## *АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК. ПРАКТИКУМ. МАТБУГАТТА БАСЫЛГАН ЯЗМАЛАР. УКУ ҺӘМ ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН*

Әлеге текстлар журналист тикшерүе язмаларына анализ ясау өчен мисаллар булып тора. Биредә матбугатта чыккан берничә эш тәкъдим ителде. Алар ярдәмендә журналист тикшерүе язмасына анализ үрнәген күрсәтеп була. Материалларда нинди проблема күтәрелгән, журналистлар аларны тикшерү алымнарын кулланып, ни дәрәҗәдә башкарып чыкканнар? Бу сорауларга текстларны уку барышында җавап эзләячәкбез.

Текстлар «Акчарлак», «Ватаным Татарстан», «Безнең гәҗит» газеталарыннан алынды. Журналист тикшерүе материалларын өйрәнү барышында без газеталарның төпләнмәләреннән текстларны эзләп табабыз, анализлыйбыз, сорауларга җавап бирәбез. Төрле дәрәҗәдә язылган язмалар бар. Кайсыдыр язмалар тикшерүне азакка кадәр башкарып чыккан, кайсындадыр проблеманың чишелеш юллары күрсәтелгән. Һәрхәлдә, журналистлар тикшерү алымнарын кулланып материаллар эшләгәннәр, аларда журналист тикшерүе жанрының үсеш мөмкинлекләре күзаллана.

***1нче текст.***

***«Казан уртасында сукбайларча яшәдек»***

Беренче сөйләшүебездә үк ул миңа: «Газетага исемемне яза күрмә, бөтен авыл кычкырып көләчәк», – диде. Шундый шарт белән генә соңгы бер ел эчендә күргәннәрен сөйләргә ризалашты. Аны Буа районының бер авылында яшәүче Шамил абый дип атыйк. Казанда тораклы булам дип хыяллана-хыяллана муеннан кредитка чумган ул.

**Арзанлы сыр – капкында!**

– Бер ел элек улым армиядән кайтты да Казанга китеп эшкә урнашты, – дип сөйли башлады Шамил абый. – Фатир «снимать» итү кесәсенә шактый суга, моны күреп безнең эч пошты, шуңа күрә малайга ярдәм итәргә булдык. Тулай торактан бер бүлмә булса да алыйк, үз почмагында яшәр, диештек хатын белән. Интернеттан эзлибез – тулай торактагы кечкенә генә бүлмәләр дә миллион сумга якын тора, кыйбатсынабыз. Ул кадәр акча күргән кешеләр дә түгел. Шуннан соң арада бер арзанлысы килеп чыкты, Казанның

Вознесенье бистәсендә урнашкан. Ике катлы йортның мансардында 25 квадрат метрлы бүлмәне нибары 750 мең сумга тәкъдим итәләр. Кызыксынып китеп, барып карадык, хуҗа белән сөйләштек. Элекке тегү фабрикасы бинасы икән бу, аны шулай бүлмәләргә бүлеп, сатарга керешкәннәр. Тик монда бер зур «ләкин» бар иде: йортның икенче каты да, безгә тиешле мансарды да ярымҗимерек хәлдә, бүлмәләре бүленмәгән, ремонтлыйсы да ремонтлыйсы әле. Газы, уты да юк. Шикләнеп басып торуыбызны күрепме, йортның хуҗасы Наталья Галкина безне тынычландырырга тотынды: имеш, бу ремонтны төгәлләүнең бер кыенлыгы юк, бары тик акчалары гына җитеп бетми икән. Менә без алдан ук бүлмә хакының яртысын түләп куйсак, аларга ремонтны төгәлләп чыгарга шул җитәчәк, ди. Биредә, ягъни Боковая урамы, 9 йортта тарттырылган түшәм, җылытылган идәннәр булачак, душ белән бәдрәфе дә һәр бүлмәдә аерым ясалачак, кыскасы, улыбыз рәхәттә ятачак, имеш. Сатучы хатынның теле телгә йокмый инде, без, авыл кешеләре, авызны ачып тыңлап тордык. Аннан болар белән килешүләр төзеп, тиенләп җыйган акчаларыбызны Натальяга илтеп бирдек, өстәп, 400 мең сум кредит та алырга туры килде. Хәзер дә шуны түләп ятыш менә, ай саен 10 мең сумны банкка илтеп бирәбез... Иптәш Галкина булачак торакта ремонт ике атна эчендә – 2018нең Яңа елына төгәлләнә дип антлар эчсә дә, мондагы эшнең иге-чиге булмый. Бераз күз-колак булырмын дип, Шамил абый Буадан ук күчеп килеп, шушы тирәдә эшкә урнаша. Эш мәсьәләсе белән дә аңа шул ук Наталья Владимировна булыша, биредә кар көрәргә куша, хезмәт хакын 10 мең сум дип килешәләр.

**«Казан уртасында сукбайларча яшәдек»**

– Галкина мине Грачиная, 35 адресы буенча урнашкан бер бинага вакытлыча яшәргә урнаштырды. Минем белән тагын 6-7 гаилә яшәде анда. Минем кебек үк алданучылар, ремонт төгәлләнгәнен көтеп ятучылар иде алар. Коточкыч шартларда, сукбайларча тордык. Монда хәтта газ да юк иде. Кышның салкын көннәре бит. Катып үлмәс өчен кичтән барып газны ялгыйбыз да, иртән иртүк йөгерә-йөгерә барып аерабыз. Чөнки тотылырга ярамый, газ законлы рәвештә кермәгән. Казан уртасында шундый тормыш гөрли менә! Анда яшәүчеләрнең язмышлары ничек төгәлләнгәндер, белмим, 1-2 ай каравылда торганнан соң кире туган якларга сыпырттым. Аллага шөкер, эшләгән айларым өчен

акчасын ала алдым хет, – ди Шамил абый.

Шамил абыйның Боковая, 9 адресы буенча бүлмәсен рәсмиләштереп бетерәсе калган иде бит әле. Торак төзелеп бетмәсә дә, кәгазь эшен төгәлләмичә булмый, акчаның яртысы түләнгән килеш ич. Тик монысы да шома гына тәгәрәми. Ике як та сату-алу килешүе төзергә дип нотариуска баргач, тагын ыгы-зыгы килеп чыга. Шамил абый әйтүенчә, нотариус янына аның (Шамил абыйның) бертуган апасы килеп керә дә: «Аферистлар бит болар!» – ди, Галкинага төртеп күрсәтеп. Имеш, шушы мизгелдә Шамил абыйның да күзләре ачыла һәм төзелгән килешүне юкка чыгарырга булалар, бүлмәне алудан баш тарталар. Әмма, югарыда телгә алуыбызча, Галкинага алдан тапшырылган 370 мең сум бар бит. Менә анысын Шамил абыйга кайтарырга атлыгып тормыйлар. Инде бер ел узса да, Шамил абый һаман шул сумма турында хыялланып яши. Вәгъдә «ашап» туйгач, судка да мөрәҗәгать итә. Суд исә Шамил абый файдасына карар чыгара, «Акчаны түләргә!» – дип бармак яный Галкинага. Наталья Владимировна, күрәсең, моның ишегә ияләнеп, каешланып беткән алыпсатар инде. Акча һаман хуҗасына әйләнеп кайтмагач, суд приставлары да эшкә җигелә. Тик соңгылары, гадәттәгечә, көчсез, Галкинадан бер тиен дә ала алмыйлар. Аптырагач-йөдәгәч, Шамил абый «Акчарлак» редакциясенең телефон номерын җыя...

**«Ул бездән хатынын яшерде»**

Мин, үз чиратымда, икенче як – Наталья Галкина белән элемтәгә кердем. Ул исә гаебен танырга ашыкмады, тыныч кына үз версиясен тезеп китте.

– Әйе, мин – Боковая урамындагы йортның хуҗасы. Узган ел андагы бүлмәне сатарга куйган идек, клиентны риэлтор аша таптым, – диде Наталья Владимировна.

– Дөресен әйткәндә, кем икәнен алдан ук белгән булсам, бу кеше белән бөтенләй бәйләнмәс идем. Эшләр сатып-алуга барып җиткәч, аның апасы нотариус янында: «Әгәр Шамилнең психиатрия хастаханәдә дәваланучы хатыны булса, бу очракта сату-алу килешүе төзү мөмкинме?» – дип сорап куйды. Без бу сорауны ишетүгә аптыраштык. Кеше тикмәгә генә шулай дими бит инде. Билгеле, көчемсез милек алганда тормыш иптәшенең нотариус тарафыннан расланган, рәсми рөхсәте сорала. Аннан башка берничек тә килешүне төзеп булмый. Әгәр ир яки хатын үз

акылында булмаса, эшләр тагын да катлаулана, кәгазь матавыгы да шактый арта.

Шамил, күрәсең, шул кәгазь боткасыннан җиңел генә качып, хатыны турындагы мәгълүматны яшереп калырга уйлаган. Нотариуста менә шушы сер капчыкны тишеп чыкты. Нотариус: «Мондый очракта мин сезгә сату-алу килешүе төзи алмыйм, хатыныгызның рөхсәтен алып килегез», – дип барыбызны да борып чыгарды. Аннан инде тегеләр «бүлмәне алмыйбыз» дип кирегә сукалый башладылар һәм юлларыбыз аерылды.

– Сез Шамил абыйның паспортына күз салгансыздыр бит? Анда тормыш иптәше турында мәгълүмат юк идемени? – дип кызыксынам.

– Юк иде шул. Күрәсең, ул 45 яше тулгач паспортын алыштырган да, анда өйләнгән булуы турында мәгълүматны яңадан тутыртып тормаган. Паспортының ул бите чип-чиста иде. Шуңа күрә без аны-моны уйламадык та, шикләнмәдек тә. Шамилнең ике баласы бар икәнен генә беләидем. Миңа ул: «Казанда улым белән тулай торакта яшим, барыр җирем юк», – дип сөйләде. Авылда өе бар икәнен дә әйтмәде. Эшкә урнаштыруымны сорады, аңа кулымнан килгәнчә ярдәм иттем, хезмәт хакы да түләп тордым. Әйтәм бит, әлеге хәл килеп чыгасын алдан чамаласам, янына якын да килмәс идем. Алардан күпме сүз ишеттем!

– Шамил абыйның 370 мең сум акчасын нишләп һаман кайтармыйсыз? Аңа тагын күпме көтәсе?

– Ул биргән акчалар ремонт эшләренә кереп киткән иде инде, шуңа күрә вакытында түли алмадым. Менә хәзер ул бүлмәгә яңа сатып алучы таптык. Эшләр 14 декабрьдә төгәлләнергә тиеш, шуннан соң Шамилнең банктагы исәп-хисап счетына 370 мең сумны күчерәчәкмен. Кулына тоттырырга шикләнәм, аннан тагын «алмадым» дип әйтер, кешене белеп бетермәссең...

– Боковая урамындагы ул бүлмәне ремонтлап бетердегезме соң? Шамил абыйның акчалары төзекләндерү эшләренә китте дисез бит.

– Юк, ремонтланмаган әле ул. Бүлмә сатылмагач, ремонтын да туктатып тордык. Яңа сатып алучы акчасына эшләп бетерергә иде исәп, – диде Наталья Галкина.

Фатир алганда нәрсәгә игътибар итәргә? Газета басмага әзерләнгән вакытта язма геройларымның номерларын кабат

җыйдым. Бу вакытта 14 декабрь көне дә сызгырып узып киткән, инде ике як та уртак тел тапкан булырга тиеш иде кебек. Ләкин Шамил абый мине сөендерергә ашыкмады.

– Акча һаман юк, теге хатын вәгъдә ашатуын дәвам итә. Минем 370 меңне үз кесәсенә тыкканга 12 декабрьдә төгәл бер ел булды, суд карары нигезендә, бу суммага көн саен процентлар да өстәлә бара. Хәзер мин шалтыратканда телефонын да алмый башлады, шуңа чит-ят номерлардан гына шалтыратам аңа. Ә хатыннан теге рөхсәт кәгазен алуга килгәндә, мин андый документ кирәк икәнен белмәдем, әйтүче дә булмады. Ярый әле вакытында апам бу хакта әйтте, сату-алу килешүе төзергә өлгерми калдык, дип сөендем соңыннан. Барып чыкса, хәзер 750 меңемнән дә колак каккан булыр идем, теге бүлмәне дә үземә ремонтларга туры килер иде. Ә анда миллион сумың да җитмәс! Арзанлы торакка кызыгып, аферист кулына эләктем, хәзер нишләргә дә аптыраган, – дип көрсенде Шамил абый. Наталья Галкина исә өметләндерүен дәвам итте:

– Бүлмәне сатып алучы бар, менә фәлән документка заказ биреп кайттым әле. Хәзер эшне тиз-тиз генә төгәллибез дә Шамилгә булган бурычларны кайтарам, – диде ул. Кыскасы, әлегә миңа да вәгъдә ашаталар. Шулай да, бу ситуацияне контрольдән ычкындырмаска, Галкинаны аптыратучылар исемлеген тулыландырырга исәп. Ә Шамил абыйга нинди киңәш бирергә дә белмәссең, инде закон ягыннан бөтен инстанцияләрне үтәргә өлгергән ул: суд юлын да таптаган, суд приставларына да барган. Хәзер кышкы суыкларда, бурычлы Галкинаны ныклы контрольгә алуларын сорап, җитәкчеләргә хатлар сырлап утырса гына инде. Бәлки, газета укучылар арасында тагын Наталья Галкина корбаннары бардыр? Халык әйтмешли, бердәмлектә – көч бит. Андыйлар Шамил абый белән бергә эш итсә, бәлки проблема тизрәк хәл ителер. Башка укучыларыбыз да милек сатып алганда икеләтә сак булсын иде. Бу өлкәне аңлап бетермәгән, шикләнгән очракта риэлтор ялларга, барлык документларны энә күзеннән үткәрә белгән белгеч табарга кирәк. Булачак фатир берәрсенең мирасы түгелме, моңарчы башка берәүгә сатылмаганмы, хуҗалар арасында психик авырулар юкмы, балигъ булмаган балаларны кайда пропискага кертергә җыеналар – мондый эштә сораулар күп булырга мөмкин. Ә иң яхшысы – документлары чиста, бәхәсле

урыннары булмаган торакка гына алынырга. Алыш-биреш банк аша үтсә, ягъни фатир ипотекага алынса, тагын да яхшы. Димәк, документларны банк юристлары да ныклап тикшерәчәк дигән сүз. Эшләгән акчаларыбыз бәрәкәтле, йортларыбыз имин булсын!

Лилия Заһидуллина.

***2нче текст.***

***«Пропискадан төшәргә җыенасызмы?»***

Ләйсәнне гаепләү генә җиңел, аның хәлләрен исерек ир белән тормыш иткән хатыннар гына аңлый торгандыр. Юньле ирдән хатын китми. Аннан, читтәге туганнар өйдәге афәтнең тирәнлеген тоеп та бетерә алмыйдыр. Ләкин, миңа калса, каенана йортыннан чыгып китеп ялгышкан ул. Унҗиде ел гомер кичергән бит алар. Акылы, сабырлыгы җитмәгәнме, Люция әйтмешли, йорт турында Наҗия апа исән вакытта ук уйларга кирәк иде. Бәргәләнүенең сәбәбен дә аңлыйм: бар көчен, булган акчасын, яшьлеген шул йортка сарыф иткән бит. Шунда балалар алып кайткан. Ә хәзер, әйтерсең лә, ул боларны төшендә генә күргән, кәкре казык та калмаган. Ничектер гаделсезлек килеп чыга бит!

Туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр турында язарга яратмыйм. Чакыралар шул... Үзләре булмаса, алар өчен чын күңелдән борчылучылар табыла. Ә бит кайвакыт әлеге хәлләргә ачыклык кертү, үпкәләрне оныту, җан тынычлыгы алу өчен ике якның утырып сөйләшүе, аңлашуы да җитә. Ләкин, ни аяныч, адәм баласын үпкә, мин-минлек харап итә. Сезгә бәян итәсе тарих та шулайрак булып чыкты. Аның ике герое вафат инде, урыннары оҗмахта булсын. Ләкин монда бер гаепсез балалар бар. Редакциягә шалтыратучы: «Балаларны әтиләре йортыннан мәхрүм иттеләр, урамга куып чыгардылар. Алар бит шунда туган, шунда үскән, ул – аларның туган йорты, туган нигезе», – дигән иде. Сүз Апас районының Чүри Бураш авылында яшәгән Зарифуллиннар гаиләсе турында бара. Яшәгән дип шуңа әйтәм, ул йорт хәзер буш инде, читтәге балалары кайтып-китеп кенә йөри...

Ләйсән матур, ипле гаиләдә туып-үсә. Ике кыз, тырыш, балаларын чын күңелдән яратучы ата-ана. Хәер, кем яратмый инде йөрәк парәсен? Кыскасы, Ләйсән балачагын бәхетле итеп сурәтләде. «Бик бай булмасак та, әти-әни барысын да бирергә тырышты, кешедән ким-хур итмәделәр», – ди. Ләкин кыз кешенең

тизрәк кияүгә чыгасы, бәхетле буласы, балалар алып кайтасы килә. Мәктәпне тәмамлагач, СПТУга укырга керә ул. Ике ел очрашып йөргәннән соң, 21 яшендә, яраткан егете Илсур Зарифуллинга кияүгә чыга.

– Мин килен булып төшкәндә каенатa мәрхүм, ә каенана Нажия пенсиядә иде, – ди Ләйсән. – Илсурлар биш бала, төпчекләре – Апаста, калганнары – Мәскәүдә. Барысы да гаиләле иде. Бер елдан соң бер абыйлары үлде. Туганнары, килендәшләр белән аралашып яшәдек. Каенана бик усал иде. «Аның белән ничек торасың?» – дип сораучылар да булды. Киленне яратмыйлар инде... Ләкин алар минем әти-әнине санга сукмады, үзләрен өстен куйдылар. Югыйсә, төшеп калган кешеләр түгел, әнием почта җитәкчесе булып эшләде. Илсурларның йорт-җирләре дә безнекеннән артык түгел иде.

Ире белән 16 ел гомер кичерә алар. Илсур салгаларга яратса да, хуҗалыкны алып бара. Ләйсән әйтүенчә, йорт-җирләрен дә яңарталар, алай гына да түгел, яңаны салалар. Иң мөһиме: ике бала алып кайталар.

– Үземнең әни һәрвакыт: «Кешечә яшәгез», – диде. Башта гараж, аннан бура алып, мунча салдык. Йорт төзегәндә ссуданы әни алды, ләкин ул каенана исемендә иде, акчаны да әни түләде, түләү турындагы квитанцияләре бар. Каенана нәрсә генә эшләсәк тә, каршы килде, ссуда алуга да теш-тырнагы белән каршы иде. Өйгә яңа әйбер кайтса да, тавыш чыкты. «Бу нигә кирәк, шуңа барып тәрәлгәнме?» – дип әйтә иде, балаларга да әйбер алдырмады. Мин дә ул вакытта аз акчага эшләдем, кайбер айларда мең ярым сум чыга иде, – ди Ләйсән.

Ләйсәннең тел төбеннән каенанасына үпкә сизелсә дә, башта начар яшәмәгәндер алар. Туганнары кайтып-китеп йөргәндер, каенана оныкларына күз-колак булгандыр. Әбиле балалар да үзләрен бәхетле хис иткәндер. Илсурны да Ләйсән белән икәүләп туры юлга бастырырга тырышып караганнар бит, әнә. Бәлки алар шулай яшәгән дә булыр иде, ләкин гаиләгә бәхетсезлек килә – Илсур үз-үзенә кул сала.

**Упкыннан – фаҗигага / 2013 елның декабрь ае.**

– Ноябрьнең 17сендә отпускага чыктым, бер-ике көн торды микән, Илсур айнымый эчә башлады. Моңа кадәр дә аракысыз

тормады, эчә, аннан айный, берәр ай туктап тора иде, бу юлы бәйдән ычкынгандай кыланды, көнне, төнне белмәде, – ди Ләйсән.

– Улының шул көнгә калуын күрү каенанаңа да җиңел булмагандыр, ул ни диде соң? – дип сорыйм аннан.

– «Үлсәң, еларбыз да туктарбыз», – дип әйтә иде...

– Ә шулкадәр эчәргә акча каян алды соң ул?

– Кем белгән? Аракы бирделәр микән? Элек болай түгел, кайтып ята, икенче көнне торып эшкә китә иде. Икенче кыз тугач, күпкә китә башлады. Фаҗига булыр алдыннан каенана белән икәү аның кайтканын көтәбез, аннан аракысын кайда яшергәнен карап тора идек. Аннары шешәсенең ярты аракысын бушатып, су кушабыз, ә ул аны сизми. Тора-бара гел түгеп бетереп, су салдык, аракы дип эчте. Төнлә чыгып китә, вакытны чамаламый башлады. Аннан, кайтып керә, йоклап ала, аракы сорый. Балалардан да таптырды, «сез яшереп куйгансыз» дип әйтә, әмма беркайчан да кул күтәрми иде. Соңгы вакытта төнге күлмәкләр белән Илсур артыннан чыга башладык, бәйләп куйган да булды. Ә беркөнне олы кызым: «Әти, кая барасың?» – дип кулына ябышкан иде, Илсур аны өскә күтәреп атып бәрде, кызыбыз чак бусагага барып төшмәде, – ди Ләйсән бите буйлап аккан яшьләрен сөртеп.

– Нишләп дәваланырга алып бармадыгыз? Гомумән, дәвалап карадыгызмы? – дип сорыйм аннан.

– Төнге өчтә Казанга – наркодиспансерга да алып чыгып киттек. Табиблар: «Айныйса – айный, айнымаса – юк», – дип кайтарып җибәрделәр. Туганнарына да кирәкми иде инде ул. 9 декабрь көнне тагын шул ук хәл. Стена белән диван арасындагы кечкенә генә аралыкка кереп ятты. Сөйрәп торгыза башлагач: «Күрше абый чакыра», – дип, үлгән абыйның исемен әйтте. Ут чыбыкларын өзеп бетерде, – ди Ләйсән. Бу үтә күңелсез хәлләрнең ахыры шулкадәр аяныч тәмамланыр дип уйламаганнардыр инде, белгән булсалар, туганнары җыелып кайтып, чарасын күрер иделәр. Ә болай, гомер буе эчкән Илсур турында «айныр әле» дип фикер йөрткәннәрдер.

**10 декабрь.** Ләйсән әйтүенчә, акыллы кешене хәтерләтми инде Илсур. Аракы сорый, «бозауны суеп сатам» дип, өйдәгеләрне янә борчуга сала. «Болай яшәп булмый бит инде, китәм», – дип тә карый хатын. Аннан, ишегалдында торган машина ачкычларын яшерә. Ул да булмый, күрше хатыны керә, ә чыгып барышлый

гаражда бауда асылынып торучы Илсурны күреп, кабат өйгә йөгереп керә. Өнсез калган Ләйсән җан биргән ирен баудан кисеп төшерә. Әйтүе генә ансат, менә шуларны кичерергә Ходай язмасын! Әнисе Нажия апа да бар бит әле! Нинди генә булса да, бала бала бит инде ул! Кан саугандыр ана йөрәгенә, үзәкләре өзелгәндер...

**Илсурдан соңгы тормыш**

– Каенана белән 17 ел тордык, төрле вакытлар булгандыр. Әмма Илсурның үлеменнән соң тәмуг башланды. Мин Апаста кибеттә эшли идем. Иртән торып малларны карыйм, балаларны мәктәпкә озатам, аннан, эшкә чыгып китәм. Балалар кайта, ашарга юк. Каенана үзенә генә пешереп ашый. Зур кызым 9 сыйныфта укый иде, мин әзерләп киткәнне җылытып көн күрделәр. Ул аларны «ияртеп килгән балалар» дип атады, «кеше белән йөрисең» дип җанга тиде. Әниләр килеп сөйләшеп тә карады, «исемен әйт, әйдә, йөргән кешесен алып киләбез», диделәр. «Илсурны син үтердең», – дип каһәрләде. Утка, газга да без түләдек. Бу шартларда берәү дә яши алмас иде, балаларны ияртеп, әниләргә кайтып киттем, – ди Ләйсән.

Шушы чыгып китүдән иренең йортына әйләнеп тә карамый ул. Алай гына да түгел, бер елдан соң икенче ир белән никах укытып яши башлый.

– Беркөнне каенана: «Пропискадан төшәргә җыенасызмы?» – дип шалтыратты. «Юк», – дидем. Судлар да төрле сәбәпләр аркасында әллә ничә тапкыр кичектерелде. Соңыннан каенана авырып хастаханәгә кергән, безгә әйтүче булмады. Олы кызым Казанда укый иде, Илсурның Мәскәүдәге абыйсы шалтыраткан. Ике кызым да судка барды. Берсе аңын җуеп егылган. Алар әбиләренә әби итеп карады, куып чыгаргач кына күңелләре катты. Пропискадан төшерделәр, каенана йортны балаларына яздырган. Берсе баш тарткан, ә икесе юк. Гомумән, каенана үлгәч, Илсурның туганнары белән ара өзелде, кияүгә чыгуым да ярамагандыр инде, – ди Ләйсән.

Ләйсән һәм аның дусты сөйләвенчә, пропискадан төшерү дә сәер генә килеп чыккан. Кемнәрдер алар өчен барлык документларны тутырганнар, имзалар белән дә шул ук хәл.

– Анда әтинең дә имзасы тора иде. Ләкин ул беркая да бармаган, бер документка да кул куймаган. Экспертиза ясатырга теләгән идек, ул документларны безгә бирмәделәр, – ди Ләйсән.

– Ә син үзең нинди документларга кул куйдың? – дип сорыйм аннан.

– Мин берни дә белмим. Барысы да тиз килеп чыкты, аңышмыйча да калдым. Балаларны ничек төшергәннәр? Нигә аларны йортсыз калдырдылар? Ул йортта безнең бер өлеш тә юкмыни? – дип өзгәләнә Ләйсән.

**«Балалар турында уйларга иде»**

Алда әйткәнемчә, Илсурның ике туганы Мәскәүдә яши, берсе – Апаста. Мәскәүдәгеләре авылларын сагынган саен кайтып та йөри алмыйлардыр, ара ерак. Апаста яшәүче Люция исә Апас үзәк хастаханәсендә санитарка булып эшли, гаиләсе, торыр җире, өч баласы бар. Барлык сорауларыма да ул җавап бирде.

– Әни Ләйсәнне куып чыгармады! Әни – Хезмәт ветераны, авырый, ай саен өчәр меңлек дару эчә иде. Абый эчсә дә, терлек карады, маллар асрап сатты. Ләйсән моңа кадәр дә кайтып-китеп йөрде. Абый эчкәндә чыгып китте, абый айныгач барып алды, ә әни аны ишеген ачып кертә торды. Әни усал булса да, гадел усал иде. Бу юлы әни, утны өзәбез дигәч, Ләйсәнгә ут өчен түләргә кушкан, шул ярамагандыр инде. Ссуданы да абый үлгәч әни үзе генә түләп бетерде. Пропискадан төшерү турында сүз чыккач, әни: «Балаларны төшермим», – диде. Ә алар судка килгәндә төшеп килгәннәр инде. Ләйсән бер елдан соң кияүгә чыкты, балаларны әни янына китермәде. Әни авырый башлагач, безгә «дарственный» ясады. Илсур исән чакта, август аенда машина алганнар иде, менә шунда Ләйсәннең әнисе ссуда алып бирде. Абыйның җидесе узгач та шул машинаны алып киттеләр, кирәкми ул безгә! Кырыгы узганын да көтмәделәр! Бөтен җиргә дә Ләйсәннең әнисе Гөлсинә кысылды, – ди Люция.

– Илсурның балалары кызганыч, гел өлешсез калалармы? – дим аңа.

– Әни оныкларын күрергә тилмереп ятты, Ләйсән китермәде, бездән аерды. Әни авырганда кодагый китермәгән. Ләйсән үзе турында гына уйлады, балалар хакында түгел. Чыгып китәргә кирәкми иде! Бергә яшәсәләр, мондый хәлләр килеп чыкмас иде. Хәзер үзем генә калдым, аралашыр кешем юк, туганнарым еракта.

Ник ул балалар килми? Бергә-бергә, аралашып яшәр идек. Җитмәсә, ата назыннан да, ана назыннан да мәхрүм калдылар, әниләре яңа ире белән яшәп ята, ә балалар – әбиләрендә. Йортны саткан очракта без ул балаларны өлешсез калдырмаячакбыз, әмма Ләйсәнгә өлеш чыгармаячакбыз. Ләйсән әхлаклы булса, бәлки абый да исән булыр иде. Ирне ир итә белергә дә кирәк! Өй салганда Мәскәүдән абый кайтты, ирем штукатурлады, мунча эшләде, – ди Люция.

**Соңгы сүз**

Люция белән аралашу миндә яхшы тәэсирләр калдырды. Өй өчен тарткалашып йөри торган комсыз кешегә дә охшамаган ул, абыйсының балаларын да ярата. Кызлар, барыгыз әле Люция апагыз янына, утырып сөйләшегез! Бик сагына ул сезне!

Эльмира Флүн.

***3нче текст.***

***Безгә фатир тиешме?***

Бабай белән әби гомер иткән авыл йорты. Шушында җиде бала үскән. Барысы бергә булганда өйнең салкынлыгы да, искелеге дә сизелмәгән. Бүген исә бөтенләй башкача. Йорт та какшаган, бабай да үлеп киткән. Шаулап торган гаиләдән бүген Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылындагы төп нигездә сугыш ветеранының тол хатыны Рәхилә апа Җиһаншина  һәм аның авыру ике улы көн күрә. «Район хакимияте безнең өйне, документларны яңадан карап, 87 яшьлек әбигә фатир бирү мәсьәләсен ачыкласын иде», – дигән борчылып язган хат безне юлга чакырды.

«Сезгә сугыш ветераннарының тол хатыннарына бирелә торган торак мәсьәләсе буенча язам. Без сугышка кадәр үк Бритвин дигән рус авылыннан 1965 елны 600 сумга иске өй  сатып алдык. Кыш көне сүтеп алып кайттык. 1966 елда шул өйне Олы Ачасыр авылында төзеп куйдык. 45 елдан бирле шунда яшибез. өйнең нигезләре, бүрәнәләре черегән. Идән араталары сынган, алар терәү белән терәтелгән. Яз җиткәч, идән астына су төшә. Безнең өй кыш көне бик салкын. Өй бүрәнәләрендә зур-зур ярыклар бик күп. Әни өйдә киенеп кенә йөри, өстеннән калын арка җылысы бер дә төшми, аягында гел киез итек. Өйнең черегәне күренмәсен өчен такта белән тышлап, буяу белән буялган.

Быел, сугыш ветераны толы буларак, без әнигә фатир алыр

өчен документлар җыеп район хакимиятенә җибәргән идек. Килеп карадылар, алгы ягын гына фотога төшерделәр. Шуннан өйнең 34 проценты гына тузган дип язып җибәргәннәр. Имеш, өйнең искелеге күренми. Шулай булмыйни, яраксызга әйләнмәсен дип гел буяп торабыз бит. Эчтән черегән бүрәнәләрне, кыек нигезне генә яңартып булмый...».

Редакциягә хат белән йорт язуларының төп нөхсәләрен дә җибәргәннәр. Халык матбугатны үз яклаучысы буларак таный әле, килеп туган хәлләргә ачыклык кертүне сорый. Бу очракта да йортның тузган булуы бәхәссез. Урам яктан матур булып күренгән өйнең бүрәнәләре, чыннан да, бик «картайган». Идән өрлекләре черегән, хәтта морҗа да ел саен аска таба шуыша икән. Моның шулай икәнлеген үз күзебез белән күреп кайттык. Йорт моңарчы хуҗалар тарафыннан косметик ремонт ясалганга гына рәтле торган. Ике елга бер мәртәбә буяп торган аны Хәбирҗан абый. Шулай булмаса, иске йортны саклап булыр иде микән? «Йортыгыз 1966 елгы, диделәр. Соң ул йортның бүрәнәләрен алып кайткан кешеләр исән. Авыл Советына аңлатманы соңрак кына язып бирдек, без бит ике катлы йортның бүрәнәдән төзелгән икенче катын сүтеп алып кайткан идек. Ул йорт үзе, мөгаен, 50 еллап торгандыр», – дип сөйли Хәбирҗан абый.

Сугыш ветераннары һәм аларның тол хатыннарына закон нигезендә бирелергә тиешле торакның мохтаҗ булган кешенең йорты агачтан булса – 61, кирпечтән салынганы 70 проценты тузган булырга тиеш. Олы Ачасырдагы йортны ничек 34 процент тузган дип билгеләгәннәрдер, шунысы гына шик уята. Әлбәттә, шушы еллар эчендә хуҗалар да тик кенә утырмаганнар: бер як түбәне алыштырганнар, өйне тышлатканнар. Тик тузган бүрәнәләрне алыштырыр өчен өйне яңадан сүтәргә, ягъни өр-яңадан йорт торгызырга кирәк. Бу йортта исә андый эшкә алынучы бер генә сәламәт кеше дә юк. 87 яшьлек Рәхилә апаның үз чирләре дә баштан ашкан. Шушы йортта 32 ел урын өстендә яткан хатыны Наиләне караган Хәбирҗан абый йөрәк белән II төркем инвалид, көненә 4-5 төрле дару эчә. Энесе Наил тумыштан телсез-чукрак. «Мин кинәт үлеп китсәм, авыру энем белән әни бу иске йортта нишләр инде? Әнинең үзенә аерым фатир бирсәләр, бик әйбәт булыр иде», – ди Хәбирҗан абый.

Бүген Ачасырда шушы закон нигендә торак шартларын

яхшыртырга теләгән 18  кеше бар. Тик шуларның берсе Борһан Хөснетдинов кына фатирлы булган. Яшел Үзән районы башлыгы Сергей Батин исә «Җиһаншиннар эше буенча махсус комиссия эшләячәген белдерде. Сүзләр ни дәрәҗәдә гамәлгә ашар, анысын вакыт күрсәтер.  Шунысы кызык:  теге яки бу ветеранның торак шартларын яхшыртырга дип язган гаризаларына килгән җавап хатында ни сәбәрледер комиссиядәге кайбер кешеләр тарафыннан кул да куелмаган. Димәк, бу документлар алар аша үтмәгән, күпчелеге  бу кәгазьләрне күрмәгән дә булып чыга. Мәсәлән, Җиһаншиннар йортын 13 кешедән торган ведомостваара комиссиянең ике кешесе генә  килеп караган. Авыл җирлеге башлыгы Равил Самат улы белдерүенчә, алар ул көнне торакка дәгъва кылучы барлык ветеран йортларында булып чыкканнар. Район башлыгының: «Бу йортларның берсендә дә булмадым, комиссия рәисе буларак кул куйганмын. Тик без законда язылганча эш алып барырга тиешбез», – дигән сүзләре истә чыкмый. Законда язылганча булса, закон буенча эшлик. Комиссия тулы көченә эшләсен, фатир өмет итеп тә кире кагылганнарга аңлатсыннар. Ветераннарның күңелендә икеле-микеле уйлар калмасын. Ә килешмәгән очракта исә судка мөрәҗәгать итәргә була. Гаризаларын кабат суд аша каратучылар күп очракта үз хокукларын яклый да алды, андый мисаллар җитәрлек.

Безгә фатир тиешме дип язган Рәхилә апа Җиһаншинага  ике дә уйламыйча тиеш дип җавап бирер идем. Бүген II төркем инвалид Рәхилә апаның да балачагы, яшьлеге сугыш елларны туры килә. Бөтен җирдә дә, бөтен эштә беренчеләрдән булып эшләгән апа окоп казырга да, урман кисәргә бара. 1914 елгы ире Галимҗан Җиһаншин да ике сугышта катнаша. Беренчесе – Фин сугышы, аннан кайтуга  – Бөек Ватан сугышы. Беренче көннән башлап ахырына кадәр сугышкан, берничә тапкыр каты яраланган. Госпитальдә ятканнан соң, яралы килеш Берлинга кадәр барып җиткән Галимҗан абый. Туган авылына 1946 елны гына кайта ул. Гомере буе, безнең сугышта күргәннәрне аңларлар, барыбызга да олы хөрмәт күрсәтерләр әле, дип хыялланып яшәгән сугыш ветераны 1993 елны вафат була.

Күпме бабайлар ил өчен сугышып, яшьлекләрен юк итеп, аяк-кулсыз кайтты. Сугыш инвалидларының күбесе шуның өчен берәр кадер күрделәрме соң?! Юк бит, юк. Инде фатир мәсьәләсендә

күпме аңлашылмаучанлыклар килеп чыга. Редакциягә теге яки бу мәсьәләне ачыклау өчен көн саен шалтыраталар, хатлар юллыйлар. Кемнеңдер язмышына битараф булмасак иде, җитәкчелек бигрәк тә. Аяныч язмышлы тол хатыннарны да рәнҗетмәсәк иде.

Рәсимә Муллаянова.

P.S. Яшел Үзән хакимияте башлыгы белән сөйләшкәннән, проблемаларны санап күрсәткәннән соң үзгәрешләр шактый күп булды. Районның торак комитетында моннан соң да тәртип булыр дигән өмет зурдан, чөнки Рәхилә әби Җиһаншинага фатир биргәннәр. Сөенечләрен шалтыратып әйткәндә, язманың беренчесе газетада урын алган иде. Ә икенче язма никтер язылмый калган. Югыйсә, журналист эшенең нәтиҗәсен дә күрсәтә белергә тиеш. Гомумән, журналист тикшерүе язмалары вакыт ягыннан да озакка сузылырга, хәтта бер үк темага берничә материал да эшләнергә мөмкин.

***4нче текст.***

***«Кукмарада иске йорттан күченүчеләргә «эт оясы» биргәннәр***

Челтәрсез тәрәзәле, черек түбәле, буяулары кубып беткән ике катлы йорт янына килеп туктадык... Икенче катка илтә торган агач баскычка сөялеп, бер ханым каршы алды:

– Фатирыбыз өстә. Бу җимерек баскычлардан менәргә курыкмасаң, әйдә кер! – диде ул югарыга таба атлап.

Тавышыннан таныдым: бу – Мәрьям апа Исмәгыйлева. Кукмарага Чаллыдан ук килгән. Кунакка, дисәм – артык арттырып җибәрү булыр, сеңлесе янына гына, диик. Кунакка дигәч, тәмле ашап, серләшеп кенә көн үткәрү, соңрак йомшак урынга ятып йоклау күз алдына килә бит. Ә Мәрьям апага бераз башкачарак кунак булырга туры килгән: туңудан калтыранып, сәгать саен кайнар чәй эчәргә, эңгер-менгер башлангач, шәм яктысында утырырга, төнлә күршеләргә кереп кунарга. Чөнки урамда салкын, караңгы да тиз төшә, ә менә иске йортта ут та, газ да юк. Өзгәннәр. Сәбәбе – бу ике катлы агач барак күптән авария хәлендәге торак исемлегенә кертелгән булган. Башка фатирларда яшәүчеләр дәүләттән алмашка бирелгән ипотекалы фатирларга күчкән, кайберләре ипотека түли алмам дип, тузган торагы өчен акча гына алган – әнә шулай таралышып беткәннәр. Хәзер бу өйдә бердәнбер

кеше –Мәрьям апаның бертуган сеңлесе Зоя Филиппова гына яши. Ул да, күршеләреннән үрнәк алып башка урынга күченер иде дә бит. Дәүләттән тапшырылган фатиры «эт оясы» булмаса.

**Күршегә керәп куналар**

Зоя апа Филипповага 62 яшь. Олыгаеп кына кияүгә чыккан, соң гына бала тапкан – 19 яшьлек улы бар, тик аның белән күрешә алмадык (бүген-иртәгә кайтырга тиешле егетнең армиядәге чагына туры килдек). Бараклагы фатир ун ел элек үлгән мәрхүм иреннән калган аңа.

Зоя Филипповадан тыш, бу йортта тагын ташландык мәче балалары һәм күселәр яши. Әле тагын Зоя апаның шиңгән гөлләре бар. Алары – өй эчендәге салкынлыктан шәлперәйгән.

– Сентябрь уртасында, алдан бернәрсә әйтеп кисәтмичә, башта – утыбызны, соңыннан җылылыкны өзделәр. Катлы-катлы тун киеп тә озак утырып булмый монда. Йорт дымлы булгач, үзәк өзгеч суык, эчкә җылы керсен, дип, сәгать саен чәй кайнатам, – ди өй хуҗасы, плитәгә тоташтырылган газ баллонына ишарәләп. Аның әйткәннәрен җөпләгәндәй, авыз ачылган саен бөркелеп пар чыга. Чын дөресен әйткәндә, биредә урамдагыга караганда да суыграк иде.

Йортларының күгәрек каплаган диварларына, җимерелергә торган матчаларына карап торам. Зоя апа сүзен дәвам итә:

– Кайчан гына килерләр дә, безне башка урынга күчерерләр, дип озак көттек. Без генә түгел күршеләр дә шулай зарыкты. Көтәргә сабырлыгы җитмичә үзлегеннән күченүчеләр дә, бакыйлыкка китүчеләр дә булды, кыскасы, берничә гаилә генә яшәп калган идек инде. Быел җәй көне хакимияттән килеп, ниндидер документларга кул куйдырдылар, фатир ачкычы бирәбез диделәр. И сөендем! Яңа фатирга күчәбез бит, Аллага шөкер, дим. Белгән булсаммы!

Татар акылы төштән соң, дигәндәй, яңа торакка риза булып, документка кул куя-куюын да, әмма башта фатирны барып күрми Зоя Филиппова. Кабул итеп алу-тапшыру актына имзасын төшергәннән соң гына ачкыч алып, дус кызын да ияртеп, яшәячәк яңа урынны карап кайтырга була. Тик ишекне ачып кергәч, баскан урынында катып кала ул.

– Кычкырып җибәрдем, мин әйтәм: «Мин монда яши алмыйм!» – дим!

– Нигә алай дидегез?

– Эт оясы бит ул! Сез аны күрсәгез! Менә тагын йөрәгем авырта башлады..

Зоя апаның шушы фатир аркасында башланган өянәге кабат кузгалмасын, дип борчылып, күрәсең, апасы Мәрьям ханым сүзне дәвам итте:

– Фатирны барып карады да, сеңлем шунда ук миңа шалтыратты. Апа, монда бер бүлмәле фатир бирделәр, әмма диван тыксаң – телевизор сыймый, телевизор тыксаң – шкафка урын юк. Аптырагач, күршеләргә кереп киттем – аларны фатирлары бер бүлмәле. Менә дигән – бөтен нәрсә сыйган. Сеңлемә шалтыратам: «Сыймый инде сыймый ди? Түзмәдем килдем. Килеп караса-ам! Фатирның мәйданы 27,8 квадрат метр. Ул шундый проект белән эшләнгән: зал бүлмәсе өчпочмак кебек. Бер башына ятак куйсаң – очлаеп киткән өлешенә бернәрсә дә сыймый. Армиядән кайткан улы белән бер короватьта йоклыйсы булыр микән инде сеңлемнең? Диванны аш бүлмәсенә чыгарыр идең – анда да өстәл куйгач, башка урын юк. Юыну бүлмәсенә керсәң, анда урын бар, әмма урта бер җиренә унитаз ясап куйганнар, шуның аркасында өстәмә ятак анда да кермәячәк. Кыскасы, бер-беребезгә карап, аптырап тордык та, борылып кайтып киттек.

**Күз яше түгеп күченәләр?**

Бу сөйләгәннәргә ышанасы да килмәде. Яңа фатирга үзем кереп карарга булдым. Әйткәннәре рас икән. Белмим, нинди оста ясаган план-проект белән эшләгәндер, әмма биредә бердән артык кешегә яшәү авыр булачак. Әңгәмәдәшләрем аңлата: иске баракта күршеләрендә генә психик авырулы малае белән бер ана торган. Күченү өчен аларга да шушындый «эт оясы» биргәннәр. «Ничек яшәрмен?!» – дип елый икән, бичара.

– Халык күз яшьләрен түгеп күченә монда. Гаиләле кешегә яши торган түгел бу! – ди Зоя ханым.

Хуҗабикәнең ризасызлыгы моның белән генә бетми. Барактагы фатирларының гомуми мәйданы документлар буенча 47 квадрат метрдан артык. Ә аңа алмашка 27 квадрат метрлы фатир биреләчәк. Торак кодексы нигезендә, авария хәлендәге йорттан күчергән вакытта, дәүләтнең хуҗа кешегә элеккеге фатирыннан да бәләкәйрәк булган урын бирергә хакы юк. Яңа торак мәйданы йә артыграк, йә элеккегесе белән тигез булырга тиеш. Шулай булгач,

Кукмара хакимиятендәгеләрнең халыкка аңлаешсыз проект белән ясалган «эт ояларына кучерүе зур ризасызлык тудырган да инде. Зоя ханым катып үлгән очракта да, иске фатирыннан китәргә җыенмавын белдерде. «Безгә тиешле зурлыктагысын бирсеннәр» диде ул.

**Эшләгән кеше урамда калмас**

Аның бу фикерләрен җиткерү өчен, Кукмара районы хакимияте башлыгы урынбасары Равия ханым Кәримуллина янына бардык. Беренче соравыбыз шундый булды: «Ни өчен Зоя Филиппова авария хәлендәге торактан күченүдән баш тарта?» Җитәкче бу сорауны кабатлап үземә биргәч, хакимиятнең ике тапкыр диярлек кимрәк мәйданлы фатирлар өләшеп, Филиппованың күңелен җәрәхәтләүләре турында сөйләдем.

– Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел! – диде урынбасар. – Без 2010 елда ук бу торакка инвентаризация уздырдык. Монда яңа йортлар салынганчы, Казанга бирелгә фатирларның техник паспортларын җибәрдек. Шуннан башка безгә монда яңа йортлар салмаслар иде.

Җитәкчегә кулымдагы документларны күрсәтеп, Филипповаларның иске фатирлары 47 квадрат метрдан артыграк булуын раслaдым. «Дөрес язмаганнар... Димәк безнекеләр карап бетермәгән», – диде ул, күрәсең, Казанга җибәрелгән документларны күз уңында тотып. Әмма барыбер ахыргача өзеп: «Без кимрәк мәйдандагы фатир биргәнбез икән шул», – дип әйтмәде.

– Мин апаның борчылуын аңлыйм, малай кайтса, ничек итеп яшәрбез инде, ди ул. Белмим инде, шул дәрәҗәдә...

– Равия Абдулловна, мин сезнең кебек үк фатирга әйбер сыямый, дигәннәренә ышанмаган идем. Анда армиядән кайткан малай да яшәсен дисәң, чынлап та ятакны кая урнаштырырга белми аптырамалы. Юыну бүлмәсенә дә куярга җай юк хәтта...

– Юыну бүлмәсенә караватт куймыйлар инде!

– Иң зур бүлмәсе шул бит, Равия ханым, нишләтәсең... Армиядән кайткан малай урамда калмагае әле...

Җитәкче уйга калды. Әмма җавабын тапты:

– Урамда калмас. Үз көнен үзе күрә ала инде, төзелеш оешмаларында эшли башласа, соципотека алу мөмкинлеге бар, торакны арендалап тору дигән әйбер бар, эш яшендәге кеше бүген

берничек тә урамда калмый.

Хакимиятнең документларны ныклап карап бетермичә, ашык-пошык кына йорт төзеттерүе аркасында нишләп кемдер ипотекалар алырга, фатирны яллап торырга тиеш ди әле? Кызык кына. Зуррак мәйдандагы фатир бирергә мөмкинлек юкмы соң?» – дим.

– Кукмарада хәзерге вакытта буш торак юк. Булса, без бирер идек. Мин кемгәдер үз фатирымны бирә алмыйм бит инде! Ул апа документка кул куйган, фатирга риза булган, димәк. Хәзер нинди ризасызлыклар була ала? Шулай да бу мәсьәлә буенча берәр әмәлен табарбыз. Җае гына чыксын...

Башлык урынбасар яныннан әнә шундый җаваплар алып чыгып китсәм дә, эшне ахырга кадәр җиткерү өчен район прокуратурасына бардым. Прокурор Ришат Шакиров булган хәлләрне ишетүгә тикшерү башлап җибәрде. Гадәттә, мондый тикшерүләр бер ай дәвам итә. «Зоя Филипповага торак тапшырылган чакта закон бозылганмы?» – дигән сорау кызыксындырды. Прокурор белән элемтәдә торып, эшнең барышы турында белешкәндә шул мәгълүм булды: чынлап та, яңа бирелгән фатирның мәйданы беренчел торакныкыннан күпкә кимрәк. Әмма барактагы 47 квадрат метр эченә өй эче генә түгел, чолан мәйданы да кергән. Закон нигезендә ул да яши торган мәйдан дип аталамы, әллә юкмы – шуны тикшерү барды.

– Без сез киткәч тә Зоя Филлиппованың барактагы фатирын барып карадык. Аның төп дәгъвасы шундый иде – ни өчен миңа кечерәк фатир бирделәр? Без тикшерү башлагач, район башкарма комитетыннан тиешле документларны соратып алдык, тиз арада эшкә керештек, чөнки кеше ризасызлык белдереп, салкын өйдә яши иде. Авария хәлендәге торак программасы буенча эш итүче кешене чакыртып, аңа да Филиппованың зарын җиткердек. Һәм бу эш төгәлләнергә өлгермәде – җирле хакимият җитәкчеләре бу мәсьәләне уңай якка хәл итте дә куйды! Шушы көннәрдә генә Зоя ханымга зуррак мәйданлы фатир бирәчәкләрен әйттеләр. Бу уңайдан сезнең редакциянең куйган хезмәте дә игътибарга лаек.

Кукмара районы прокурорыннан ишеткән яңалык безне бик сөендерде. Кемгәдер ярдәм итә алуыбыз – безнең дә шатлык. Әмма бу шатлыклы вакыйгада Кукмара районы прокуратурасының үз өлеше дә шактый зур. Халык зарын минуты-секунды белән тикшерергә алынган җитәкчеләр бик аз бездә.

P.S. Язманы тәмамлап килгән мәлдә телефон шалтырады. Элемтәнең икенче ягында безгә мөрәҗәгатть иткән кеше – Зоя Филиппованың апасы Мәрьям ханым иде.

– Сез киткәч берничә атна салкында яшәдек, сеңлемнең улы шул ук салкын өйгә кайтты. Анда йоклап булмый бит, шуңа күрә сеңлем белән күршеләрдә яшәсәк, ул иптәш малайларына йөрде. Инде тәмам арып, йончып беткән идек – хакимияттәгеләр чакырып алып, фатир ачкычы тапшырдылар. Бу юлы «эт оясы»ннан түгел, зур мәйданлысын. Монысының аш бүлмәсе дә зур, коридоры да киң. Сөенечебез эчкә сыймый. Рәхмәт, «Безнең гәҗит»кә, ярый әле килдегез. Сез килмәсәгез безнең проблеманы җитәкчелеккә кем чыгарыр иде? Сез булмасагыз, нишләр идек!?

Ә шулай да Кукмарада төзелгән «эт оялар»ы вакыйгалары барыбер тәмамланмаган кебек. Зоя апаны булмаса, бирегә икенче кешене кертәчәкләр.

Хәтерлисезме, былтыр Казанга Русия вице-премьеры Игорь Шувалов килгәч, аңа яңа төзелгән йорттан 20 квадрат метрлы бер бүлмәле фатирларны күрсәткәннәр иде. «Миңа бу фатирлар көлке тоела, ләкин кеше сатып ала бит», – дигән фикерен белдергән иде ул. Быел Шуваловны Кукмарага чакырырга кирәк. Тагын бер кәефен күтәреп китсен өчен...

Айгөл Закирова.

***Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр***

1. Журналист тикшерүе материалында нинди проблема күтәрелгән?
2. Журналист нинди алымнар куллана?
3. Әңгәмә барышында нинди сораулар куела (ачык, ябык сораулар)?
4. Күзәтү алымы кулланып, журналист нинди мәгълүмат туплый?
5. Текстларда документлар белән эшләү алымнары ни дәрәҗәдә чагыла?
6. Журналист газетада басылган тикшерү текстында ничек аларны тәкъдим итә ?(Шул урыннарны билгеләп китегез).
7. Тагын нинди алымнар кулланырга була? Гомумән, тикшерү жанрында нинди методлар бар, шуларны искә төшереп үтегез әле?

8. Әлеге язмада проблема чишелгәнме, язманың нәтиҗәсе нинди?
9. Ачык калган сораулар бармы? Нинди сорауларга җавап табылмаган?
10. Язмалардагы тел-стиль чараларын табыгыз. Журналист текст әзерләгәндә тәэсир итү өчен нинди тел чараларын куллана? Текста фикерне көчәйтүгә, проблеманы чишүгә тәэсир иткән сүзләрне эзләп табыгыз һәм аларны аңлатып үтегез.

## *ЙОМГАК УРЫНЫНА*

Журналист тикшерүе белән шөгыльләнгән каләм иясе төрле проблемалар белән башка хезмәттәшләренә караганда ешрак очраша. Журналист тикшерүе тормышның хокукый ягын гына түгел, әхлакый мәсьәләләрне хәл итәргә алына.

Журналистка еш кына четерекле мәсьәләләрне чишәргә, кешеләр һәм җитәкчеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыкларга туры килә. Әлеге шартларда журналист тикшерүе үзенә күрә бер билгеле урынны алып тора. Ләкин күп кенә жанрларның (мәсәлән, кыска хәбәрнең) журналистикада кулланылышын гасырлар буена күзәтеп килсәк, «журналист тикшерүе» термин буларак соңгы вакытта гына барлыкка килде. Бу яшь жанрның төгәл чикләре һәм тикшерү алымнарының үзенчәлекләре чагыштырмача күптән түгел генә формалашкан. Аны фәнни яктан тикшерүчеләр дә өйрәнүнең башлангыч стадиясендә. Журналистика тарихында мисаллар шактый булса да, Россия матбугатында «Журналист тикшерүе» дигән рубрика астында материаллар XX гасырның 90нчы елларында гына күпләп күренә башлады.

Бу жанрда эшләүче журналистлар да күп очракта кагыйдә һәм методлар гына түгел, ә тоемлау һәм «шулай булырга тиеш» дигән хискә буйсынып та эш иттеләр. Журналист тикшерүе методы белән эшләнгән материаллар укучыда зур кызыксыну уятса да, журналистлар өчен шактый гына кыенлыклар да китерә әлеге язмалар. Күп очракта аларны юридик яктан яклаучы да, тиешле булган мәгълүматны бирергә атлыгып торучы да юк. Әмма законнарны, бурыч-хокукларны яхшы белү күп кенә кыенлыклардан котылырга ярдәм итә.

Журналист ул – мәгълүматны җыючы, эшкәртүче һәм даими рәвештә интернет, газета, радио, телевидение аша аны таратучы гына түгел. Халыкны оператив рәвештә мәгълүмат белән тәэмин итү, җәмгыятьтәге социаль, икътисади сорауларга җавап эзләү, сәясәттәге хәлләрне яктырту – болар барысы да журналист җилкәсенә төшә. Журналист тикшерүләренең асыл сыйфатларыннан берсе шулдыр: ул тирән эчтәлекле итеп, үтемле формаларда, өйрәнеп-тикшереп аңлаешлы, ачык тел белән язган, ягъни югары осталыкка ия булган язмалар җыелмасы да. Ә осталык

мәсьәләсе журналистика алдында торган бүгенге бурычларны уңышлы хәл итүгә турыдан-туры бәйле. Журналист сүз белән эш итә, аның коралы – сүз. Тик ул катлаулы, үзенчәлекле корал. Ышанычлы, оста эш итү өчен аны җентекләп өйрәнү таләп ителә. Әйткән сүзең, фикерең укучыга барып җитсен, аны ышандырсын өчен – журналистмы син, язучымы, сәясәтчеме, юристмы, әллә инде сәүдәгәрме – шул фикереңне кеше ышанырлык итеп исбатлый белергә тиешсең. Иҗади эшчәнлекнең барлык төрләре дәлилләүнең сыналган һәм нәтиҗәле ысулларына ия. Хәзерге заманда, кешегә төрледән-төрле мәгълүмат ташкыны агылып торган вакытта, шул ташкын астында күмелеп калмау, вакыйга һәм фактларга дөрес бәя бирү, үз кыйблаңны югалтмау гаять мөһим. Болар барысы да журналист тикшерүче өчен әһәмиятле шартлар булып тора.

# ТЕМАЛАРНЫ ҮЗЛӘШТЕРҮ БАРЫШЫНДА КУЛЛАНЫРГА МӨМКИН БУЛГАН ӘДӘБИЯТ


### *Закон актлары һәм кодекслар*

Гражданский кодекс РФ // КонсультантПлюс. URL: http://www.consultant.ru/document/cons_doc_LAW_5142/

Декларация принципов поведения журналиста Международной Федерации Журналистов // Общественная коллегия по жалобам на прессу. URL: https://www.presscouncil.ru/index.php/teoriya-i-praktika/dokumenty/754-

Закон РФ «О СМИ» // КонсультантПлюс. URL: http://www.consultant.ru/document/cons_doc_LAW_1511/

Кодекс профессиональной этики российского журналиста // Электронный фонд правовой и нормативно-технической информации. URL: http://docs.cntd.ru/document/901854413

Московская хартия журналистов. Декларация // Общественная коллегия по жалобам на прессу. URL: https://www.presscouncil.ru/index.php/teoriya-i-praktika/dokumenty/758-moskovskaya-khartiya

Положение о принципах и системе общественного контроля за соблюдением журналистами положений кодекса профессиональной этики российского журналиста // URL: http://evartist.narod.ru/text10/14.htm#%D0%B7_06

Уголовный кодекс РФ // КонсультантПлюс. URL: http://www.consultant.ru/document/cons_doc_LAW_10699/

### *Хезмәтләр*

Абожина Н.К. Журналистское расследование на телеэкране: опыт и проблемы. // Вестник Санкт-Петербургского университета № 4, 2007. С. 231−235.

Арапова Г.Ю., Кузеванова С.И., Ледовских М.А. Освещение частной жизни в СМИ. 2-е изд., испр. и доп. Воронеж: Элист, 2010. 114 с. (Справочная серия. Юристу и руководителю СМИ). ISBN 978-5-87172-036-3.

Амиров К.Ф. Русско-татарский юридический словарь. К.: Тат. кит. нэшр., 1996. 103 с.

Әмиров К.Ф. Хокук саклау хезмәтендә эш кәгазьләре: өйрәнү-гамәли кулланма. Казан: Мәгариф, 1997. 111 б.

Быков В.В., Воинов А.Е., Дзялошинский И.М. и др. Журналист в поисках информации. Сборник материалов для работников СМИ и будущих журналистов. М.: Галерия, 2004. 180 с.

Галиева Р.М. Журналист тикшерүе. Татар журналистикасында тикшерүләр үткәрү тәҗрибәсе (Расследовательская журналистика. Опыт работы в татароязычных СМИ) // Татарская журналистика: становление и развитие: сборник научных статей.  Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. С. 253-258.
Гарифуллин В.З. Журналист эшчәнлегенең нигезләре. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2009. 148 б.
Гарифуллин В.З. Журналист осталыгы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2004. 175 б.
Гарифуллин В.З. Үткен каләм, үткер күз. К.: Тат. кит. нәшр., 1995. 46 б.
Заика Н.К. Правовые основы средств массовой информации. Учебное пособие. СПб.: ИВЭСЭП, Знание, 2005. 72 с. ISBN: 5-7320-0795-4
Зайни Р.Л. Свобода слова и ответственность журналиста (по материалам студенческих исследований в рамках изучения курса «Правовые основы журналистики») // Информационное поле современной России: практики и эффекты: Сборник статей XIII Международной научно-практической конференции (20-22 октября 2016 г.) / под ред. Р.П.Баканова. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. С.188-192.
Зәйни Р.Л. Журналистның һөнәри этикасы (программа, методик күрсәтмәләр, лекцияләр): Укыту-методик кулланмасы. Казан: Казан университеты, 2014. 48 б.
Зәйни Р.Л. Журналистиканың хокукый нигезләре: Уку ярдәмлеге. Казан, Казан университеты, 2011.  120 б.
Зверева Н.В. Школа регионального тележурналиста: Учебное пособие для студентов вузов. М.: Аспект Пресс, 2004. 320 с.
Золотухин А.А. Расследовательская журналистика. Воронеж: факультет журналистики ВГУ. 2016. 144 с.
Константинов А.Д. Журналистское расследование: история метода и современная практика /Агентство журналистских расследований (АЖУР); СПб.: «Издательский Дом «Нева»; М.: «ОЛМА-ПРЕСС», 2010. 704 с.
Криминальная хроника и судебный репортаж. Авт. сост. Г.Ю. Арапова, С.И. Кузеванова, М.А. Ледовских. М.: Элиткомстар, 2007. 128 с. (Справочная серия. Юристу и руководителю СМИ).
Корконосенко С.Г. Основы творческой деятельности журналиста.

М.: Знание, 2000. 272 с.
Лазутина Г.В., Распопова С.С. Жанры журналистского творчества: учеб. пособие для студентов вузов. М.: Аспект-Пресс, 2011. 320 с.
Мукусев В.В. Черная папка. История одного журналистского расследования. М.: РА Арсис-Дизайн, 2011. 184 с.
Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. 144 б.
Ковалев-Случевский К.П. Тележурналистика XXI века. М.: Грифон, 2012. 126 с.
Рихтер А.Г. Правовые основы журналистики [Текст]: учебник. Изд. 3-е, испр. и доп. [Б. м.]: Издательские решения, 2016. 493, [5] с.: цв. ил., портр.; 21 см.; ISBN 978-5-4483-1224-3
Рихтер А. Г. Правовые основы журналистики. Хрестоматия. Допущено Учебно-методическим объединением по классическому университетскому образованию в качестве учебного пособия для студентов высших учебных заведений, обучающихся по направлению подготовки ВПО 030600 «Журналистика» и специальности 030601 «Журналистика» для ГОС-2 и направлению подготовки ВПО 031300 «Журналистика» для ФГОС. М.: Изд-во Моск. ун-та, 2011. 348 с.
Рихтер А. Г. Правовые основы интернет-журналистики: Учебник. М.: Изд-во ИКАР, 2014. 488 с.
Тертычный А.А. Жанры периодической печати. М.: Аспект Пресс, 2006. 320 с.
Тертычный А.А. Расследовательская журналистика. М.: Аспект-Пресс, 2002. 384 с.
Тертычный А.А. Аналитическая журналистика. М.: Аспект-Пресс, 2010. 352 с.
Станько А.И. Журналистские расследования. Ростов-на-Дону. 1997. 320 с.
Ульбашев А. Х. Правовые основы журналистики. Общий курс медиарегулирования. 2-е изд., испр. и доп. Учебник для бакалавриата и магистратуры. М.:Издательство Юрайт, 2019. 189 с.
Федотов М.А. Правовые основы журналистики: М.: Владос», 2009. 432 с.
Шум Ю. Журналисткое расследование: Методич. рекомендации. М.: Барс, 2000. 80 с.

Подписано в печать 14.05.2019. Формат 60х84 1/16.
Бумага офсетная. Печать ризографическая.
Усл. печ. л. 7,5. Тираж 100. Заказ № 1405/3.

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии «Вестфалика» (ИП Колесов В.Н.)
420111, г. Казань, ул. Московская, 22. Тел.: 292-98-92
e-mail: westfalika@inbox.ru